**С. Г. ИСМӘГЫЙЛОВА, Ф. М. САБИРОВА**

# ТӘРБИЯ ХӘЗИНӘЛӘРЕ

Казан (Идел буе) федераль университеты Алабуга институтының Гыйльми советы карары белән басыла (беркетмә № ?? 2025ел)

Рецензентлар:
Мухаметшин А.Г. – педагогика фәннәре докторы, Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты профессоры;

Габидуллина Ф.И. - филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университетының Алабуга институты доценты.

С. Г. Исмәгыйлова, Ф. М. Сабирова.
Тәрбия хәзинәләре: монография. Яңадан эшләнгән, тулыландырылган 2 нче басма. – Алабуга: ......... 2025. – 140 б.

Хезмәттә халык педагогикасынының асылын тәшкил иткән мәсьәләләр, аларның эчтәлеге, төрләре ачыклана. Гасырлар дәвамында җыелып, тупланып килгән һәм алдагы буыннарга тапшырылган педагогик тәҗрибәдә чагылган традицияләр, аларның тәрбия процессында кулланылыш үзенчәлекләре күрсәтелә. Шулай ук табигать фәннәрен укытканда халык авыз иҗаты үрнәкләреннән файдалану юллары, формалары, алымнары һәм дәрес эшкәртмәләре бирелә.

Хезмәт укытучы-тәрбиячеләргә, студентларга, ата-аналарга тәкъдим ителә.

# КЕРЕШ
# МИЛЛӘТ ЗЫЯЛЫЛАРЫ ТӘРБИЯЛӘҮ ЮЛЫНДА

Бер заман чыгар идек без
Кырга дуст-ишләр илә;
Анда уенлар, көлүләр,
Сикерүләр бар иде.
Һай, гомерләр... үтте, китте...
Кая китте ул заман!
Кайда ул шәп һае-һулар!
Гөфтегүләр бар иде...

Дәрдемәнд

Җәмгыятьтәге яңа иҗтимагый-социаль, мәдәни шартларда, Дәрдемәнд югарыда китерелгән «Үткән көннәр» шигырендә кисәткәнчә, «Үткән- киткән» заманнарда халкыбыз тормышын бизәп торган рухи хәзинәләребезне торгызу, милли традицияләребезне барлау һәм кайтару, халык җырларын, биюләрен өйрәнү, яшьләрдә үз милләте белән горурлану, башка милләт вәкилләренә карата хөрмәт хисләре тәрбияләү һәр тип уку-тәрбия йортлары – ясле-бакчалардан башлап югары уку йортларына кадәр – алдында гаять мөһим бурыч булып тора.

Тулаем алганда, милли мәгариф «гаилә тәрбиясе», «мәктәпкәчә тәрбия», «башлангыч белем һәм тәрбия», «тулы булмаган урта белем һәм тәрбия», «гомуми урта белем һәм тәрбия» буыннарыннан торган бөтен бер системаны тәшкил итә. Аның һәр буыны, халкыбызның милли традицияләренә нигезләнеп, һәр баланың интеллектуаль үсеше, шәхес булып, милләт зыялысы булып формалашуы, һөнәр-кәсеп үзләштерүе өчен кирәк булган бөтен шартларны булдыруны бурыч итеп куя. Нәкъ әнә шуларны истә тотып, укыту-тәрбия эшчәнлегенең төп принциплары билгеләнә. Әлеге принциплар укыту-тәрбия процессын халыкның дәүләтчеллеген ныгыту,

яшьләрдә милли үзаң формалаштыру, аларның мөстәкыйль тормышка ныклы хәзерлеген һәм милләт зыялылары буларак җитлегүен тәэмин итү идеалларыннан чыгып билгеләнәләр.

Алар түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1. Туган телдә уку, укыту, тәрбияләү, укыту-тәрбия мәсьәләләрен заман таләп иткән югарылыкта хәл итү; белем һәм тәрбия бирүне берөзлексез, даими рәвештә туган телдә алып бару, башка телләрне туган тел җирлегендә өйрәнү.

2. Белем һәм милли тәрбия бирүне бердәм процесс итеп алып бару.

3. Уку-тәрбия йортларында, гаиләләрдә һәм балалар тормыш-яшәеше барган башка урыннарда этник мохитне булдыру һәм саклау; шул ук вакытта җирле шартларны (шәһәр җире, халыкның яшәеш, көнкүреш үзенчәлекләре, географик, экологик, икътисади шартлар, сәяси атмосфера, промышленность, авыл хуҗалыгы, коммерция учреждениеләре һ. б.) исәпкә алу.

4. Һәр баланың ата-ананың, бигрәк тә укытучыларның милләтнең киләчәге, терәге булуы, милләтнең хәстәрендә һәм кайгыртуында торуы.

5. Укыту-тәрбия эшенең, башлыча, төрки, шәрыкъ һәм Ислам дөньясына йөз тотуы, рус һәм Көнбатыш мәгърифәтенең казанышларын өйрәнү һәм файдалану.

6. Гыйлемне, китап сүзен изгеләштерү, гыйлем эстәүгә, алган белем һәм күнекмәләрне тормышта иҗади файдалануга, мөстәкыйль рәвештә даими үзбаш аң-белем үстерүгә, фән, мәдәният яңалыкларыннан хәбәрдар булуга  омтылыш мохите хөкем сөрү; бүгенге җиңел юл белән мал-мөлкәт җыю мөмкинлегенә юллар ачылып. белемнәрнең, зыялылыкның кыйммәте төшкән көннәрдә моның авыру икътисад тудырган вакытлы күренеш икәнлегенә, югары класслы хезмәткә, димәк, белемле. хәзерлекле белгечләргә ихтыяҗ булачагына (бу – икътисадның тайпылышсыз кануны) инану һәм инандыру.

7. Уку планына кергән һәр предмет буенча дәресләрдә һәм класстан тыш эшләрдә балаларны һәрдаим теге яки бу фәнне үстерүгә (физика, химия, география, биология һ. б.) татар галимнәре керткән ачышлар, казанышлар, боларның халык хуҗалыгында тоткан урыны һәм дөньякүләм әһәмияте турындагы мәгълүматлар белән таныштыру.

8. Укытыла торган предметлар арасында максатка юнәлтелгән (гуманитар, ягъни җәмгыять, милли тел һәм әдәбият тарихын, милли рухи мирас һәм традицияләргә нигезләнеп, укытыла торган предметлардан булган белем-тәгълиматны гомумкешелек мәдәнияты һәм акыл эшчәнлеге нигезләре буларак тәкъдим итү) үзара бәйләнеш.

9. Һәркемнең һәрвакыт һәм һәр кайда татарча камил һәм аһәңле сөйләме; һәр фәннән дә ана телебезне тәрәккый иттерүче, яшь күңелләрдә аның илаһи матурлыгын, аһәңен, сыгылмалы киң мөмкинлекләрен тоючы һәм ача белүче мөгаллимнәр укыту; рус теленнән башка да кимендә ике-өч телдә (шуларның берсе төрек яки гарәп теле) телдән һәм язма аралашу осталыгы.

Күренгәнчә, укыту-тәрбия гамәлләрен югарыда күрсәтелгән принципларга таянып тормышка ашыру тулысы белән халыкның рухи кыйммәтләренә нигезләнүне күздә тота, һәм мөгаллимгә, күп төрле чыганакларны өйрәнеп, үз милләтенең тарихи үсешен, гасырлар дәвамында формалашкан уңай традицияләрен анык итеп күз алдына китерергә, аларның нәрсәләрдән торганын билгеләп куярга, халыкның яшь буынга белем һәм тәрбия бирү тәҗрибәсен тәртипкә салырга кирәк була.

Мисал өчен берничә традицияне генә санап китик.

1. Хезмәт сөю, хезмәт кешесен олылау, балаларны хезмәттә тәрбияләү. Безнең халык бала тәрбияләү хакында махсус хезмәтләр, нинди да булса педагогик алымнар турында укып тормаса да, сабыр холыклы, тактлы булу сәбәпле, балаларда хезмәткә җитди мөнәсәбәт, һәр эшне җиренә җиткереп башкарырга омтылыш тәрбияли алган.

2. Халыкта борын-борыннан Туган ил, туган җир, туган телгә мәхәббәт һәм сак караш, туганнарга, кардәш-ыруга, күрше-күләнгә хөрмәт һәм кайгыртучанлык яшәп килгән, нәсел тамырларын буыннан-буынга биреп, нәсел шәҗәрәсен тезү гадәти күренеш булган. Балада шулар нигезендә туганлык мөнәсәбәтләре формалашкан, ул аралашып үскән.

3. Халкыбыз буыннан-буынга ана сөте белән күчә килгән һәм күчәчәк иң мөкатдәс мирасыбыз туган телебезне тудырган. Тел җуймау – милләтебезнең өстә ярылып яткан бөек сыйфаты.

4. Гаиләдә ата-ана, әби-бабайны, өлкәннәрне зурлау, алар сүзен дөрес, үтәлергә тиешле, тәҗрибәле, күпне күргән кеше сүзе дип кабул итү, ата-анага җан өргән, үстергән-тәрбияләгән, кеше иткәне өчен гаять рәхмәтле булу, изгелеккә изгелек белән җавап бирү беркем өчен да гаҗәби хәл булмаган.

5. Баланы тәртипле, тыйнак, гадел, кешелекле, тугрылыклы итеп тәрбияләү һәм бу максатка ирешүдә тиешле тәрбия чараларын файдалану, ата-ананың, гаиләдәге өлкәннәрнең шул сыйфатларга ия булуы.

6. Белемгә, гыйлемгә, мәгърифәткә омтылыш, «бишектән алып ләхеткә кадәр белем эстәү»не идеал итү, тәгълим-тәрбия эшен кешене гомерлек юлдашы дип карау.

7. Башка милләт халыклары белән дустына тыгыз аралашып яшәү, аларның тормышын, мәдәниятен, әдәбиятын, мәгърифәтен өйрәнү һәм шул юл белән үз зиһененңне, тәҗрибәңне баету.

8. Татар халкы – әдип халык, моңлы, җыр-биюне, уен-көлкене яратучы шук, җор халык. Халык авыз иҗаты һәм андагы гаять күп жанрлар, шуларның күбесенең балаларга адреслануы – моңа ачык мисал.

9. Нечкә зәвыклы безнең халык. Нәфислек, матурлык, чисталык-пакълекне ярата ул. Тормыш кирәк-яракларын куллану, бүлмәләрне җиһазлау, йорт-җирне тоту рәвеше, кием-салым, төрле нәфислек һөнәрләре (читекче, кәләпүшче, чигүче, бәйләү-туку һ. б.)

– шуның матур күрсәткече.

10. Тормыш шартларына тиз җайлаша, мул һәм җитешле итеп яшәргә омтыла ул. Безнең халыкның исәп-хисап итәргә хирыслыгы, сәүдә эшләре, сатучылык белән шөгыльләнүе һәм моны гаҗәеп оста, отышлы итеп башкаруы, аерата зиһенле, акыллы, тырыш булуы, иренмәве кешеләр, чит илләр белән аралашып яшәргә яратуы белән аңлатыла.

11. Инануларда тотрыклылык, динне сатмау. Гасырларга сузылган христианлаштыру сәясәтенә, Совет власте елларында руслаштыру тенденцияләренә, диннең дәүләттән, мәктәптән аерылуына карамастан, халыкның Исламга, Коръәнгә булган хөрмәте, ышанычы кимемәде, дингә ышанучылар бетмәде. Бердән, Исламның оештыру, рухи тәэсире көчле булса, икенчедән, халыкта да аңа тугрылык зәгыйфь түгел иде.

12. Кунакчыллык, ачык йөзле булу – татар халкының иң күркәм сыйфатларыннан берсе.

Халыкның һәръяклап үскән шәхес тәрбияләргә омтылышын чагылдырган һәм шуңа ирешү юлында туган традицияләр болар. Аларның һәммәсе хакында тәфсилле аңлатмалар, мисаллар һәм мәгълүматлар җыйнау өчен мөгаллимгә чыганаклар җитәрлек. Болар – билгесез даһиләребез иҗат иткән мәкаль һәм әйтемнәр, табышмаклар һәм такмазалар, әкият һәм риваятьләр, мазак һәм маҗаралы хикәяләр, җырлар һәм дастаннар... Аннары безнең халык – борын-борыннан китаби халык. Әби-бабаларыбыз, зыялы затларыбыз, шәкертләребез дөньяны танып беләүләрен, тәҗрибәләрен, идеалларын, уй-хисләрен, теләк-омтылышларын ташка, күнгә, агач кайрысына, кәгазьгә язып, аларны кулдан-кулга, буыннан-буынга, күчереп, мирас итеп калдырган. Яңа буыннар аны баеткан, камилләштергән. Бүгенге көндә дә бигрәк тә авыл җирендә, әби-бабайлар белән бергәләп яшәгән гаиләләрдә балаларны халкыбызның күркәм традицияләренә нигезләнеп тәрбияләүче ата-аналар аз түгел. Бусы да өйрәнү өчен мөгаллимгә бик мөһим

чыганак.

Кыска гына итеп булса да уку йорты, мөгаллимат алдында торган максат һәм бурычларны, милли традицияләребезне югарыда бәян ителгәнчә аныклап куюның бик отышлы ягы бар; тәрбиячеләр булсын, мөгаллимнәр булсын, югары уку йорты галимнәре булсын өйрәтү, укыту, тәрбия эшләрен халыкчанлык рухында оештыруның нәрсәләрдән торырга тиешлеген анык күз алдына китерә алалар. Бу – бер. Икенчедән, тәгълим-тәрбия эшендә халык акылын зиһенен, зәвыгын, тормыш-көнкүреш һәм тәрбия тәҗрибәсен, аң белем туплау ысулларын чагылдырган уникаль чыганак булып халык авыз иҗаты әсәрләре торганлыгына, барлык уку дисциплиналары буенча да аларга урын бирелергә тиешлеккә шик калмый. Аннары халыкның элек-электән белемгә омтылуын, гасырлар буена иҗтимагый, шәхси тормышның, табигать дөньясының төрле өлкәләренә кагылышлы мәгълүматлар туплавын, тикшереп, һаман күзәтеп, төгәлли-киңәйтә, аларны буыннан-буынга тапшыра баруын да онытырга ярамый. Фәнни тәгълиматларның чишмә башы күп очракта – халык тәҗрибәсе. Бу якның да укыту, өйрәтү, тәрбия процессында сабыйлар һәм укучы яшьләр аңына һәм күңеленә җиткерелә һәм сендерелә баруы фарыз.

Халык туплаган мәгълүматларның эчтәлеге киң һәм күптөрле. Бу – туган җирнең табигате һәм табигый байлыклары үсемлекләре һәм хайваннар дөньясы турындагы белешмәләр. Математика, астрономия, медицина, тарих өлкәсендә җыйналган белемнәр иксез-чиксез. Тормышны җитешле һәм бөтен итеп алып барыр өчен, үзеннән-үзе табигать күренешләренең серенә төшенүне таләп иткән. Дөрес, аларны фәнни тәгълиматлар белән бер үлчәүгә кую дөрес булмас иде. Чөнки тупланган-җыйналган мәгълүматларның, фән булу өчен, махсус өйрәнелүе, максатлы тикшерелүе, практикада сыналуы, кирәк. Шулай булса да, халык хәзинәсе халыкныкы булып саналырга хаклы. Бу – хакыйкать һәм ул яшьләргә ирешергә тиеш.

Максатка сабыйлык елларыннан ук ирешә башлаганың хәерле,

һәм моңа, бәхеткә каршы, кирәкле юнәлеше дә бирелгән. Балалар бакчасы өчен тезелгән программаларга күз салыйк[1] Аның төзелү принцибы ук кызыклы: балаларны группадан-группага (елдан-елга) билгеле бер юнәлештә үстерү мөмкинлекләрен күздә тоту. Мәсәлән, һәр группада (нәниләрдән алып, өлкәннәренә кадәр) тирә-юнь, туган як, табигать, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы, ел фасыллары, хезмәт һәм профессияләр, шәхес һәм характер сыйфатлары, бакча һ. б. белән таныштыру, шул процесста балаларның сөйләмен, сөйләмдә авазлар культурасын үстерү, билгеле инде, кешелек сыйфатларын камилләштерә бару, шәхес формалаштыру алга сөрелә, яшь үзенчәлекләренә туры килеп торган әдәбият исемлеге тәкъдим ителә.

Программада материалның болай урнаштырылуы балаларның үсеш процессын исәптә тотуны да (нәрсә үзләштергән, нинди нигезгә таянып алга барырга, нәрсәгә ирешергә), балаларның гомуми үсеш дәрәҗәсен анык күзаллап, алдагы эшләрне конкрет итеп планлаштыруны да җиңеләйтә. Иң әһәмиятлесе: күрсәтелгән юнәлешләрдә балалар фольклорыннан файдаланырга, халык тудырган бала-чага уеннары сайлауга һәм өйрәнүгә, бу эшнең эзлекле системасын күзаллауга юл ачыла. С.Г. Исмәгыйлованың «Туган тел – очар канат», «Гөлбакчада туган тел» исемле беренчесе дүрт яшьлекләр, икенчесе биш яшьлекләр белән эшләү өчен төзелгән методик кулланмалары нәкъ шул принципка корылуы куаныч өстенә куаныч. Әйтик, уртанчылар группасында тәрбияләнүче балалар ел әйләнәсендә табигатьтә булып тора торган үзгәрешләр турындагы белемнәрен, күзаллауларын киңәйтеп, күзәтүләрен дәвам итәләр. Мәсәлән, көз көнендә көннәр салкыная, салкын яңгыр сибәли; көннәр кыскара; һава болытлы, җилле; чәчәк-үләннәр саргая, шиңә, кибә, чери, коела; кошлар җылы якка оча һ. б. Шул ук вакытта көзгә кагылышлы мәкаль һәм әйтемнәр («Көзге көн бала кебек, әле көлә, әле елый»), табышмаклар, сынамышлар («Сентябрь аяз булса, көн салкын булыр», «Агач яфрак коймый, кар яумый») китерелә,

[1] Татар балалар бакчалары өчен программа. (Фәнни редакторы Ф. Ю. Юсупов). – Казан: Татар., кит. нәшр., 1990.

аларның әһәмиятенә, асылына төшенелә. Башка ел фасылларына карата да балалар зиһене яңадан-яңа үрнәкләр белән беррәттән халык авыз иҗаты әсәрләре ярдәмендә фәнни белемнәрнең нигезләре белән танышалар, табигать күренешләренә хас үзенчәлекләрне төшенәләр. Бу алар өчен мәктәптә (гимназиядә, колледжда һ. б.) укуны җиңеләйтә. I—IV сыйныфларда укучыларыбыз халкыбызга хас пакълекне, гаделлекне, җорлык һәм зирәклекне, кече күңеллелек һәм башка сыйфатларны да халык мәкальләре һәм әйтемнәре, әкиятләре, җырлары аша танып беләләр.

V нче сыйныфтан тел һәм әдәбият дәресләренә үрнәк итеп алынган халык авыз иҗаты әсәрләренең жанр үзенчәлеге үк эстетик тәэсир көченә ия булу сәләте укучыларга ачыла бара: кыска, аһәңле, тирән һәм зирәк мәгънәле, эчке ритмлы, колакка һәм күңелгә ятышлы нәфис яңгырашлы. Аларда гыйбрәтле фикер, хезмәт халкының кешелекле карашлары, рухи дөньясы, әхлагы, гореф-гадәтләре...

Җиде йортның телен бел, җиде төрле белем бел.

Коега төкермә, суын эчәсең булыр.

Атаңны башыңда тот, анаңны учыңда тот.

Өлкән сыйныфларга күчә барган саен, халык дастаннары һәм легендалары, шулай ук әдәби әсәрләр тукымасына кергән этник бизәкләр халыкның тормыш-көнкүреш, яшәеш үзенчәлекләрен, буыннар арасындагы соклангыч мөнәсәбәтләрне ачып бирәләр.

Башка уку предметлары буенча да үз эчтәлегенә ятып торган хәзинәләр бар. География, мәсәлән, халкыбыз яшәгән төбәкләрне һәм андагы табигать дөньясын, файдалы казылмаларны һәм алар арасында халык һөнәрчелегендә файдаланыла торганнары, борынгы бабаларыбызның дөнья гизәргә һәвәслеген, сату итү юлларын һәм бу юнәлештә ачышларын, физика – халыкның табигатьнең бөек күзәтүчесе, дусты булуын, күп табигать күренешләренә талантлы аңлатмаларын, аннан оста файдалануын ачып салыр.

Биология укытучысы өчен кадерле хәзинә – халык аңында

гасырлар буена формалашкан һәм хәтеренә сеңгән төрле үсемлекләрнең табиби серләре, үсемлекләрнең халык ачкан дәвалау сыйфатлары һәм шуннан файдалану ысуллары, шуларга бәйле легендалар, риваятьләр, әкиятләр, табышмаклар, гореф- гадәтләр, йолалар. Мисалга халыкның поэтик иҗатында иң актив кулланылган каен образын гына алыйк. Дәрестә аның турында «Каенчылар семьялыгыннан. Шома ак кайрылы, биеклеге 20 метрга кадәр җитә торган, яфрагын коючан агач...» диеп, аның биологик сыйфатларына гына игътибар итсәк, балаларның хисләр культурасы формалашуына зур зарар килер иде. Каен бит ул матурлык, Туган ил, туган яклар символы, алар турында сагыш, аларга мәхәббәт хисләре, нәфислек, тугрылык, сагыну хисләрен гәүдәләндергән чын мәгънәсендәге зур поэтик образ.

Яшел шәл ябына каен,
Сандугачлы яз җитсә...
Шәлен болгап озатып калган
Сердәш каеным истә.
Кеше йөрәге таш түгел,
Эреми буламыни,
Ак каеннар каршы алса,
Күңелең туламыни?
Ак каеннарның бөресен
Итәгеңә төяп йөрерсең.
Төшләрендә безне күрерсең дә
Өннәрендә елап йөрерсең.

Йөзең нурлы, тулы айдай,
Буен зифа каендай һ. б.

Ә тормыш тәҗрибәсе, күзәтүчәнлек нәтиҗәләре...

Кәкре каенга терәткән.

Каен агачы тал булмас, каен суы бал булмас.

Ялгыз каенга терәлеп, карт каен кырык ел яшәгән.

Каен суы мул акса, җәй яңгырлы килер.

Ак каен өлгергән орлыкларын чәчә башласа, уракка таш.

Каен агачы хуҗалыкта гомер-гомергә бик тә белеп файдаланыла, дару буларак кулланыла. Халык медицинасында яшь каен яфракларыннан киң файдаланалар. Яфрак төнәтмәләрен тирләткеч һәм сидек кудыргыч чара сыйфатында кулланалар, пешекләп, ревматизмнан һәм полиартритлардан компресслар ясыйлар, каен яфракларыннан һәм бөреләреннән ясалган төнәтмәләр, кайнатмалар чәчне үстерә. Агачыннан һәм кайрысыннан дегет алалар һәм аннан да төрле тире авыруларына дәва буларак файдаланалар һ. б.

Музыка һәм җыр, сынлы сәнгать һәм графика дәресләрен зур җаваплылык белән, халык җырлары, җырлы-биюле уеннары, һөнәрчелек үрнәкләре һәм милли бизәнү әйберләре, милли җиһазлар белән баетып оештыру максатка ярашлы.

Дәресләрнең дәвамы булган класстан тыш вакытта, халык педагогикасына нигезләнеп, халык традицияләрен күздә тотып, күп төрле эшләр үткәрү – фарыз:

– укучылар, ата-аналар җыелышлары, конференцияләре, бала тәрбиясе тәҗрибәсе белән уртаклашу;

– «Табигать билгеләре һәм сынамышлар», «Халык экологиясе һәм табигать», «Яшел табиблар», «Урман аптекасы», «Халык медицинасы һәм ботаника» кебек темаларга КВНнар;

– «Уйнагыз, гармуннар!», «Бас, кызым Әпипә». «Уйныйк та көлик әле!», «Озын чәчле сылу», «Кичке тамаша», «Кызым, сиңа әйтәм, киленем, син тыңла!» (сүзләрнең күп мәгънәлелеге), «Егетләр килә сафта» (көрәш, көч сынау ярышлары, хәрәкәтле уеннар) кебек күңелле кичәләр;

– «Аулак өй», «Каз өмәсе», «Киндер тукый кызлар», «Ачык сандык янында», «Мәдрәсәләрдә китап киштәсе» (бает, мөнәҗәтләр әйтеш) кебек уен-ярышлар;

«Ипи-тоз, якты йөз» (татар халык ашлары), «Казан сөлгссе» (кул эшләре), «Балта остасы» конкурслары;

– «Аклык – пакълек», «Әдәп төбе – матур гадәт», «Тел – күңелең көзгесе», «Белем – йөрәккә куәт», «Җиде йортның телен бел, җиде төрле белем бел», «Күркәмлек — холыкта», «Ана — шафкать диңгезе», «Ата аркасы — кала капкасы» темаларына диспутлар, түгәрәк өстәл артында сөйләшүләр;

– «Татар халкының педагогик фикерләре», «Халык җәүһәрләре», «Оста кул» түгәрәкләре эше;

– табышмак, әкият, бәет, мәкаль һәм әйтем, җыр кичәләре;

– Нәүрүз, Нардуган, Сабантуй, раштуа, карга боткасы кебек традицион бәйрәмнәр;

– гаилә шәҗәрәләреннән торган, өлкән буын истәлекләре урнаштырылган альбомнар, стена газеталары, күргәзмәләр җиһазлау һ. б.

Югарыда сүз гомуми планда, барлык тип уку йортларына һәм өйрәнелә торган байтак предметларга кагылышлы рәвештә барды. Әлбәттә, һәр предмет мөгаллиме билгеләнгән юнәлештә укыту-тәрбия эшләрен оештыру, алып бару өчен җентекләп эшләнгән методик ярдәмлекләргә мохтаҗ. Киләчәктә алар барлыкка килер әле. Без бу хезмәтебез белән табигать фәннәрен өйрәнү барышында фольклор әсәрләреннән файдалану буенча кайбер тәкъдимнәр кертеп, тыйнак кына, тар гына сукмак башын салып куярга җөрьәт итәбез.

Әйе, математика – төгәл фән. Анда саннар, үлчәүләр... Шул ягы белән әһәмиятле дә ул. Безнең халыкны исәпсез-санаусыз яши итеп күз алдына китерү мөмкин түгел. Аның сәүдәгәрлек осталыгы дөньяга бил геле. Шул факт нәкъ менә конкрет, төгәл факт булып, V нче сыйныфтан ук өйрәнелә башлый. Бу — дәресләрдә фольклорның

рациональ ягын ача башлауга, нибары VII нче сыйныфтан гына өйрәнелә торган физика курсына да табигый кереп китүгә хәзерләүдә иң кулай вакыт. Кулланмага арифметика дәресләрен кертү шуның белән аңлатыла. Ул бүлеккә, халык мәкаленнән алып, «Идел суы илле батман» дигән исем бирелде.

Физика – авторның белгечлеге, шуңа күрә бу фәнгә кагылышлы бүлек үзенең тулылыгы, төрлелеге, метод һәм алымнарның да чарланганлыгы белән аерылып тора. Халык җырлары, биюләр дә дәрес материалы була алуын ачыклау да әллә ни авырлык тудырмады. Шуның өчен физика өйрәнүгә багышланган бүлекне «Җырлы-биюле физика» дип исемләү кулайрак кебек тоелды.

Ай, Кояш, йолдызлар – халык авыз иҗатында иң яратып кулланыла торган образлар. Матурлык, гүзәллек символлары алар: кызларыбызның йөзләре айга, кояшка, күзләре йолдызларга тиңләнә бит. Туган як, аны сагыну, моңлану, өметләнү һәм башка күп төрле хис-кичерешләрне поэтик югарылыкка күтәреп гәүдәләндерәләр алар. Ничек инде күк җисемнәрен өйрәнүче астрономия фәнен өйрәнүгә кагылышлы бүлекне «Ай булмаса, йолдыз бар...» дип исемләмисең?!

Шунысы бар: «табигать фәннәре» – киң мәгънәле төшенчә. Ул физика, астрономия белән генә чикләнми. Химия, биология, география һ. б. Болары да шул ук табигать фәннәре рәтенә керәләр һәм аларны укытучы мөгаллимнәр дә үз тәҗрибәләрендә без кызыксынган өлкәдә ниндидер ачышлар ясагандыр. Һәрхәлдә «Мәгариф» журналында басылып чыккан материаллар шуны күрсәтә. Тупланган материалларыгыз, тәҗрибәләрегез белән уртаклашсагыз иде! Монда Алабуга педагогия институты каршында эшләүче «Укыту методларына укыту мәктәбе» дигән фәнни-җитештерү ширкәте конкрет ярдәм күрсәтә ала.

# 1 БҮЛЕК
# ХАЛЫК ПЕДАГОГИКАСЫ: ӘҢГӘМӘЛӘР

## 1.1. БУЫННАР, ЗАМАНАЛАР ЧЫЛБЫРЫ ӨЗЕЛМӘСӘ, КИЛӘЧӘККӘ ӨМЕТ БАР

Бүгенге көндә республикабызда һәм башка төбәкләрдә татар мәктәп-гимназияләрен саклап калу, яшь буынны халкыбызның рухи һәм мадәни хәзинәләре нигезендә тәрбияләү җитди бурычка әверелде. Укыту-тәрбия эшен камилләштерү максаты белән халык педагогикасы хәзинәләреннән файдалану кирәклеге дә көн тәртибенә килеп басты. Чөнки яшь буында милли үзаң формалаштыру һәм шуның аша үз туган телен, халкын сөюче, аның объектив тарихын өйрәнергә омтылучы, үз милләтенең мәнфәгатьләре өчен янып-көеп йөрергә сәләтле шәхес тәрбияләүне халык педагогикасыннан башка күз алдына китерүе да кыен. Димәк, яшь буынны тәрбияләүдә гаять зур роль уйнаган гореф-гадәтләрне, традицияләрне кабат торгызу-яңарту чоры килеп җитте, һәм һәр укытучы, ата-ана, тәрбиячеләр бу процесска зур өлеш кертә ала.

Нәрсә соң ул халык педагогикасы?

“Педагогика” дигәне һәркемгә аңлашыла булыр. Грек теленнән алынган бу сүз (paidagogols) яшь буынга белем һәм тәрбия бирүне аңлата. Халык педагогикасын, димәк, яшь буынга белем һәм тәрбия бирү фәне дип аңларга кирәк. Ләкин, кисәтеп үтик, ул үзенчәлекле фән.

Фән, билгеле булганча, халык тәҗрибәсенә һәм күзәтү-нәтиҗәләргә таянып, шәхесләр-галимнәр тарафыннан туа. Аларның исем-фамилияләре билгеле, ачышлары, теорияләре, кануннары мәгълүм. Ул гына да түгел, ул ачыш-теорияләр күп очракта галим исемен йөртә. Ә халык педагогикасында? Монда эш башкачарак...

Һәр халыкның шул исәптән татар халкының да иң изге,

һәрвакыт нык ымсындырып торган хыялы – һәрьяктан камил шәхес тәрбияләү.

Тарихи үсеш дәвамында халыкның хәтер сандыгына бала тәрбияләү белән бәйләнешле карашлары, фикерләре һәм ысуллары тупланып килгән, һәм бу гаҗәеп рухи хәзинә, өзлексез камилләшә барып, буыннан-буынга тапшырылган. Яңа буын үз чиратында халык меңәр ел туплаган гореф-гадәтләрне, йолаларны санлап, телен-динен хөрмәтләп яшәгән. Олыга – олы дип, кечегә – кече дип караган. Картайган ата-анасын тәрбия кылуны, тудырган баласын багып үстерүне изге бурычы итеп санаган, бәндәнең рәнҗеш-каргышыннан, ананың бәддогасыннан уттан курыккан кебек курыккан. Хак хаклый белгән безнең халык: Аллаһе хакын, ата-ана хакын, күрше хакын, тол-ятимнәр, ярлы-ябагайлар хакын, милләт хакын...

Шул рәвешле, халыкта тәрбия алымнары, әхлак нормалары, караш һәм мөнәсәбәтләр, йолалар барлыкка килгән. Әнә шул буыннан буынга күчеп килгән тәрбия процессын оештыру ысулларын, нәтиҗәле алымнар, гомуми кабул ителгән һәм гадәткә кергән таләпләр, тәрбия эше белән бәйле гореф-гадәтләр, белем, күнекмәләр, карашлар, бәяләр системасын халык педагогикасы дип йөртәләр дә инде. Кайберәүләр аны, кыска гына итеп, этнопедагогика дип әйтә. Болай атау төгәлрәк, исеме җисемгә якынрак тора кебек. Этно(с) – грекча ethnos – халыкның материаль һәм рухи культурасы, мәдәни-тарихи мөнәсәбәтләре, тормыш-көнкүреш, әхлак, зәвык үзенчәлекләре дигәнне аңлата. Халык педагогикасының нигезенә дә һәр халыкның үзенә генә хас тәрбия алымнары, гореф-гадәтләре, йолалары, тормыш-көнкүрешен оештыру, үз-үзен тоту рәвеше, әхлак нормалары, милли үзенчәлекләре салынган. Болар бар да буыннан буынга күчеп, милли традицияләргә әверелгән. Күренгәнчә, халык педагогикасына – этнопедагогикага – буыннар күчеше хас. Ул халыкның бала тәрбияләү тәҗрибәсен туплавы һәм шуның белән милләтебезнең

көчен, акылын, зирәклеген, зәвыгын, мәдәниятен, хис-омтылышларын, яшәү үзенчәлеген, мөнәсәбәтләрен чагылдыруы белән кыйммәт. Монда шуны да, искәртеп үтик: “бала тәрбияләү” дигәнне киң мәгънәдә, аң-белем бирү дип тә, тәрбия кылу дип та, ягъни тәгълим-тәрбия дип аңларга кирәк. “Тәгълим-тәрбия” (яисә “тәгълим вә тәрбия”) дигән парлы атамада һәм белем бирү (тәгълим – белемгә өйрәтү, гыйлемле итү) һәм тәрбия итү максаты бергә кушылып, бер бөтен категория сыйфатында каралган. (Госманов М. Тәрбия максаты – кешелеклелек // Мәгариф. – 1990. - №2.- Б. 9.). Без инде хәзер бу зур, киң һәм тирән эчтәлекле процессны тагын да кыска итеп, “тәрбия” сүзе белән генә атарга күнеккәнбез.

Халык педагогикасының мәгълүматлар туплау чыганаклары гаять күп төрле. Иң беренче чиратта болар – билгесез даһиларыбыз иҗат иткән мәкаль һәм әйтемнәр, табышмаклар һәм такмазалар, әкият һәм риваятьләр, мәзәк һәм маҗаралы хикәяләр, җырлар һәм дастаннар... Аннары безнең халык – борын-борыннан китаби халык. Әби-бабаларыбыз, зыялы затларыбыз, шәкертләребез дөньяны танып белүләрен, тәҗрибәләрен, идеалларын, уй-хисләрен, теләк-омтылышларын ташка, күнгә, агач кайрысына, кәгазьгә язып, аларны кулдан-кулга, буыннан буынга күчереп, мирас итеп калдырган. Яңа буыннар аны баеткан, камилләштергән. Бүгенге көндә дә, бигрәк тә авыл җирендә, әби-бабайлар белән бергәләп яшәгән гаиләләрдә балаларны халкыбызның күркәм традицияләренә нигезләнеп тәрбияләүче ата-аналар аз түгел. Бусы да халык педагогикасы өчен мөһим чыганак.

Чал тарихлы бай әдәбиятыбызда һәм гыйльми хезмәтләрдә дә халкыбызга хас педагогик талант соклангыч, җанлы дәлил итеп теркәлеп калган.

Берничә генә мисал.

*Галимҗан Барудиның* (1857-1921) 1910 елда Казанда басылып чыккан “Мәгарифе Исламия” исемле хезмәте мөселманнарның көндәлек тормышта үз-үзләрен тоту (балалар белән мөнәсәбәте дә)

нормаларына аңлатмалардан тора. Гомумән, аның китаплары һәм аның тарафыннан чыгарылган “Әл-дин вә Әл-әдәп” журналы (1906-1917 еллар) тәрбия мәсьәләләренә, кешенең рухи үсешенә кагылышлы материалларга бай.

Күп кенә тарихи, әдәби һәм педагогик хезмәтләрнең авторы, Көнчыгыш мәдәниятен өйрәнүче галимнәрнең күренекле вәкиле *Ризаэтдин Фәхретдин* (1858-1936), балаларны тугач та тәрбияли башларга кирәк, дигән фикердә нык торып, иң әүвәл ананы тәрбияләүгә зур әһәмият бирә һәм алар өчен “Тәрбияле хатын”, “Тәрбияле ана” дигән хезмәтләрен яза. Өлкән яшьтәге балалар өчен “Шәкертләр әдәбе”, кече яшьтәге балалар өчен “Тәрбияле бала”, барысы өчен дә “Гаилә” хезмәтләрендә дә әдип-галим-педагогның халыкның тәрбия тәҗрибәсен тирәннән белүе, аны нигезләп гомумиләштерүе һәм ихлас күңелдән пропагандаларга омтылуы нык сиздерә. 1908 елның гыйнвареннан башлап, ун ел буена айга ике мәртәбә чыгып килгән “Шура” журналында (Риза Фәхретдинов – аның баш мөхәррире), башка бүлекләр белән беррәттән, “Тәрбия һәм тәгълим” бүлеге да булып, анда даими рәвештә бай мәгълүматлар, акыл, киңәш, фикер, үрнәкләр бирелеп барыла.

Әдип, журналист, галим, педагог *Фатыйх Кәрими* (1870-1937) “Әзһәр әхлак” (“Чын әхлак”) “Мәктәпкәчә тәрбия”, “Иҗтимагый тәрбия” исемле һәм башка педагогик хезмәтләрендә, “Җиһангир мәхдүмнең авыл мәдрәсәсендә укуы”, “Бер шәкерт илә бер студент”, “Салих бабайның өйләнүе”, “Мирза кызы Фатыйма” кебек педагогик юнәлешле хикәяләрендә халыкның гыйлем, уку яратуын, балаларын ничек булса да укытырга омтылып торуларын, мәктәп-мәдрәсәләрдә әдәп-әхлак тәрбиясе да бирелергә тиешлеген, гади авыл картларының башкаларга, бигрәк тә бала-чагага көчле тәрбияви йогынтысын ышанычлы итеп һәм җанлы картиналарда ачып бирә.

Халыкның тәгълим-тәрбия тәҗрибәсендә уңай традицияләрнең тууында, ныгуында мәктәп-мәдрәсәләребезнең роленә аерым тукталып китәргә кирәк. Ятлый-ятлый өйрәнелә торган “Нәсихәт-

әссәлихин” китабы шәкертләребезне изге эшләргә өндәп торган. “Рәһбәр сыйбьян” (авторы – Зәбири Хәбиб-эр-Рахман), “Уку китабы яхуд вә вазаиф әфтәл” (Назыйм Гали), “Тәрбия китабы" (К. Насыйри), “Сабыйларга мәгълүмат” (Хәнафия Әшрәф), “Малайлар һәм кызлардан ялкаулыкны җибәрү”, “Сабый вә сабыялар өчен мәргуб булган хикәяләр вә мәкальләр һәм олугларны тәрбия өчен гыйбрәтләр” (Таиб Яхин) кебек XIX йөзнең ахырында – XX йөз башларында басылып чыккан гаять күп сандагы уку китаплары сабый чактан ук тормышта көн дә кирәк була торган әдәп-әхлак нормаларын балаларның күңелләренә, рухларына сеңдергәннәр. Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф”ы, Мәхмүд Болгариның Нәһҗел фарадис”ы, Мөхәммәдьярның “Төхфәи мәрдан”ы һәм “Нуры содур”ы, Мәүла Колый хикмәтләре, Утыз Имәни бәяннары һ.б., – дәреслек-китаплар – йөзләгән буынны илгә, милләткә тугрылыклы булу, хезмәт, матурлык сөю, игелекле, кыю, батыр булу, сәламәт, зирәк, сәләтле булырга омтылу, киләчәгең турында да уйлап-кайгыртып яшәү рухында, яктылык идеалларында тәрбияләгәннәр. Мәдрәсә тәмамлагач, мөгаллим, хәлфә, мөдәррис, мулла, хәзрәт үз белгәнен халыкка җиткергән. Укымышлы кешеләргә, китап сүзенә хөрмәт һәм ышаныч белән карый торган безнең татар акыллы киңәшләрне зиһен һәм күңел төбенә сендереп куйган, файдалысын һәм хуш килгәнен, бигрәк тә көндәлек тормышка яраклысын көнкүрешендә гамәлгә керткән.

Безнең мәктәп-мәдрәсәләребез, дәреслекләребез сәхифәләрендә исләр китеп сокланырлык бер нәрсә бар. Ул да булса – дәреслекләрнең үк халык педагогикасы белән сугарылган булуы. Мәсәлән, әдәбият дәреслекләренең иң беренче бите мәктәпкә, аннан алга таба битләре анага, атага, мөгаллим-хәлфәләргә, якыннарга багышлана. Шуларга ялганып, тормыш мәшәкатьләре, мал-туар, тереклек дөньясының изгелеге, әдәп-әхлак сыйфатларына кагылышлы мәкаләләр, хикәяләр, шигъри әсәрләр китә. Ата – ул, хәлфә – шәкерт, галим – хәлфә әңгәмәләре рәвешендә бирелгән

материаллар тәрбия итү ысулларын да үз эченә ала. Алар шәкертләрнең танып белү сәләтен үстерү ягыннан да, тәрбия итү чарасы буларак та әһәмиятле.

Кыз балалар өчен махсус төзелгән кыйраәт китаплары кызлык намусын саклау, ана булуга җаваплы караш, бала тәрбияләүдәге нечкәлекләр кебек мөһим мәсьәләләр күтәрүе белән әһәмиятле.

Халкыбызның рухи байлыгының төп өлешен тәшкил иткән Ислам динен, аның халык педагогикасына көчле йогынтысын әйтми үтү, кем әйтмешли, зур гөнаһ булыр иде. Ислам дине тәгълиматы, Коръән, аның аерым сүрәләре, аятьләре, бай эчтәлеге, бәян ителгән гыйбрәтле язмышлар – болар барысы дә безнең әби-бабаларыбыз өчен кайгылы һәм хәсрәтле вакытларында юатучы, яхшыны яманнан аерырга өйрәтүче, тән һәм рух сәламәтлеген тәрбияләүче, аң-белемгә юл күрсәтүче булган. Кешенең барлыкка килүен, Җир йөзенда яшәү сәбәпләрен аңлаткан, тормышның мәгънәсен танып белергә ярдәм иткән. Коръәннең киңәш-нәсәпләре (Фәхретдин Р. Ислам дине – нинди дин? // Мирас. – 1991. - № 1; 1992.- №№ 1, 2, 3, 4. Үтәбай-Кәрими Р. Тарихыбыз һәм мәдәниятебездә Ислам // Мәгариф. – 1990. - № 10; Коръән турында // Мәгариф.- 1991.- № 1) тормыш, тереклек итү toткасы ролен үтәгән. Революцияга кадәр Коръән барлык мәктәп-мәдрәсәләрдә укытыла. Мөселман дәүләтләрендә ул хәзер дә мәктәп-мәдрәсәләрдә һәм институт-университетларда төп уку предметларының берсе булып исәпләнә.

Халык педагогикасы әнә шул югарыда күрсәтелгән (күрсәтелмәгәннәре иксез-чиксез), халык педагогикасына азык биреп торучы этнография, фольклористика, социология, педагогика фәннәренә караган хезмәтләр генә дә күпме!) чыганакларны өйрәнеп, халыкның тәгълим-тәрбия тәҗрибәсенә кагылышлы мәгълүматларны, карашларны, фикерләрне, мөнәсәбәтләрне тикшерә, системага сала, закончалыкларын ача, принципларын билгели һәм җыйнап, гомумиләштереп, фәнни нигезләп бәян итә. Бу яклап, ягъни татар халык педагогикасын фән дәрәҗәсенә күтәрү

җәһәтеннән, профессор Я. И. Ханбиков керткән хезмәтләр (Ханбиков Я. И. Из истории педагогической мыели.- Казань: Таткнигоиздат, 1967; История педагогики татарского народа. - Казань: Таткнигоиздат, 1975 һ.б.) мактауга лаек. Бу олы галимнең шәкертләре дә бер-бер артлы тирән эчтәлекле хезмәтләр бастырып чыгардылар (Ханбиков Я. И., Галиев Ә. Х. Татарские народные традиции эстетического воспитания. Учен. зап. КГПИ, вып. 105, сб. 2, 1972; Татарские народные игры и праздники. - Казань: Таткнигоиздат, 1975.; Раимова С. И. К вопросу использования татарских народных традиций в эстетическом воспитәнии. Учен. зап. КГПИ, вып. 105, сб. 2, 1972), "Мәгариф" журналы соңгы вакытта саннан санга берсеннән-берсе кызыклы материаллар биреп куандыра. (Аеруча Ф. Баттал, Х. Батчаева, , М. Госманов, И. Сункишева, Р. Шагаев, 3. Хәбибуллина мәкаләләре игътибарга лаек). Татарстан укытучылар белемен күтәрү институтының педагогика кафедрасында "Халык педагогикасы" лабораториясе оештырылу бу мөһим мәсьәләнең киң планда тикшерелүенә, башка милләтләрдәге кебек калын-калын китаплар барлыкка киләчәгенә өмет тудыра.

Шул рәвешчә, халык педагогикасы, башка фәннәрдән аермалы буларак, – фәнни тәгълимат та, ягъни теория дә, шул ук вакытта буыннан-буынга тупланган, һәр яңа буын тарафыннан камилләштерелгән һәм бастылган тәҗрибә дә. Шуның өчен аның өйрәну объекты да үзенчәлекле: халыкнын тәгьлим-тәрбия традицияләре.

Теория буларак, халык педагогикасы алдында шактый катлаулы бурычлар тора:

– әби-бабаларыбыз, акыл ияләребезнең, эти-әниләребезнең ул һәм кызларын тәгълим-тәрбия итү гамәлләрен тарихыбызның буеннан-буена өйрәнү һәм системага салу;

– бала-чагага, яшьләргә бирелгән үгет-нәсихәтләрнең, кисәтү, җәзалау һәм хуплауларның эчтәлеген, характерын барлау һәм аларга

бүгенге көннең актуаль проблемалары күзлегеннән чыгып бәя бирү;

– тәгълим-тәрбия эшендә нәрсәнең яхшы, нәрсәнең яман дип саналуын ачыклау һәм шуңа анализ бирү;

– яман гадәтләрдән, кыңгыр сыйфатлардан арындыру (перевоспитание) өчен нинди чаралар кулланылганын барлау;

– дингә, дин әһәлләренә, туганлык мәсьәләләренә карата яшьләрнең мөнәсәбәтен формалаштыру үзенчәлеген билгеләү һ.б.

Кыска гына итеп әйткәндә, халык педагогикасы үзенең теоретик аспектында – халыкның тәгълим-тәрбия традицияләренең эчтәлеген, төзелешен, үзенчәлекләрен бәян итү һәм боларны бүгенге көндә киң пропагандалау бурычларын үтәп, буыннар, заманалар чылбырын өзмәү хакына берөзлексез баеп, үсеп, камилләшеп торырга тиешле фән.

Тәҗрибә тупламы буларак исә, халык педагогикасы зур, бай, гыйбрәтле тәгълим-тәрбия традицияләрен иңләп ала.

1. Иң беренче чиратта – хезмәт сөю, хезмәт кешесен олылау, балаларны хезмәттә тәрбияләү. Безнең халык бала тәрбияләү хакында махсус хезмәтләр, нинди дә булса педагогик алымнар турында укып тормаса да, сабыр холыклы, тактлы булу сәбәпле, балаларда хезмәткә җитди мөнәсәбәт, һәр эшне тырышып, җиренә җиткереп башкарырга омтылыш тәрбияли алган.

2. Халыкта борын-борыннан Туган ил, туган җир, тугаи телгә мәхәббәт һәм сак караш, туганнарга, кардәш-ыруга, күрше-күләнгә хөрмәт һәм кайгыртучанлык күрсәтү яшәп килгән, нәсел тамырларын буыннан буынга биреп, нәсел шәҗәрәсен төзу гәдәти күренеш булган. Балада шулар нигезендщ туганлык мөнәсәбәтләре формалашкан, ул аралашып үскән.

3. Гаиләдә ата-ана, әби-бабаны, өлкәннәрне зурлау, алар сүзен дөрес, үтәлергә тиешле, тәҗрибәле, күпне күргән кеше сүзе дип кабул итү, ата-анага җан өргән, үстергән-тәрбияләгән, кеше иткәне өчен гаять рәхмәтле булу, изгелеккә изгелек белән җавап бирү беркем өчен дә гаҗәби хәл булмаган.

4. Баланы тәртипле, тыйнак, гадел, кешелекле, тугрылыклы итеп тәрбияләү һәм бу максатка ирешүдә тиешле тәрбия чараларын файдалану, ата-ананың, гаиләдәге өлкәннәрнең шул сыйфатларга ия булуы.

5. Белемгә, гыйлемгә, мәгърифәткә омтылыш, “бишектән алып ләхеткә кадәр белем өстәү”не идеал итү, тәгълим-тәрбия эшен кешенең гомерлек юлдашы дип карау.

6. Башка милләт халыклары белән дустанә тыгыз аралашып яшәү, аларның тормышын, мәдәниятен, әдәбиятын, мәгърифәтен өйрәнү һәм шул рәвешле үз зиһененңне, тәҗрибәңне баету.

7. Татар халкы – әдип халык, моңлы, җыр-биюне, уен-көлкене яратучы шук, җор халык. Халык авыз иҗаты һәм андагы гаять күп жанрлар, шуларның күбесенең балаларга адреслануы – моңа ачык мисал.

8. Нечкә-зәвыклы безнең халык. Нәфислек, матурлык, чисталык-пакьлекне ярата ул. Тормыш кирәк-яракларын куллану, бүлмәләрне җиһазлау, йорт-җирне тоту рәвеше; кием-салым, төрле нәфислек һөнәрләре (читекче, кәләпүшче, чигүче, бәйләү-туку һ.б.) – шуның матур күрсәткече.

9. Тормыш шартларына тиз җайлаша, мул һәм җитешле итеп яшәргә омтыла ул. Безнең халыкның исәп-хисап итәргә хирыслыгы, сәүдә эшләре, сатучылык белән шөгыльләнүе һәм моны гаҗәеп оста, отышлы итеп башкаруы, аерата зиһенле, акыллы, тырыш булуы, иренмәве кешеләр, чит илләр белән аралашып яшәргә яратуы белән аңлатыла.

10. Инануларда тотрыклылык, динне сатмау. Гасырларга сузылган христианлаштыру сәясәтенә, Совет хакимияте елларында руслаштыру тенденцияләренә, диннең дәүләттән, мәктәптән аерылуына карамастан, халыкның Исламга, Коръәнгә булган хөрмәте, ышанычы кимемәде, дингә ышанучылар бетмәде. Беренчедән, Исламның оештыру, рухи тәэсире көчле булса, икенчедән, халыкта да аңа тугрылык зәгыйфь түгел иде.

11. “Кунакчыллык, ачык йөзле булу – татар халкының иң күркәм сыйфатларыннан берсе. Кунак өй бусагасыннан атлап керүгә, күптән килгән гадәт буенча, хуҗалар, бөтен эшләрен ташлап, аңа хөрмәт күрсәтә башлыйлар: урынның түрен бирү, кулдан юындыру, яңа, чиста сөлге тәкъдим итү, азыкның иң тәмлеләре белән генә сыйлау, урын-җирне йомшак, чиста итү, кунакның күңелен күрергә тырышу һ.б. Үзенә күрә күнаклы өй “законнары” да барлыкка килгән: “Кунак килсә, ит пешә, ит пешмәсә, бит пешә”, “Күнакны аяк өсте торып сыйла”... Кунак өчен дә кагыйдәләр бар: “Сыйлаганның суын эч”, “Кунак булсаң, тыйнак бул”, “Кунак – хуҗаның ишәге” һ.б. Балалар боларның барысын да күреп-ишетеп үсәләр, үзләре дә кунак-кунак уйныйлар, кунакта үз-үзләрен матур тотарга күнегеп үсәләр.

Халыкның һәрьяклап үскән шәхес тәрбияләргә омтылышын чагылдырган һәм шуңа ирешү юлында туган традицияләр болар.

Халкыбызның педагогик хәзинәсе күп гасырлардан килә. Борынгы Болгар дәүләте чорларында ук яшьләргә белем бирә торган уку йортлары булган. Татар халкы үз язмышының иң авыр шартларында, әйтик, XVI-XIX йөзләрдә патша самодержавиесенең мәрхәмәтсез эзәрлекләве елларында да, үзенең мәктәп-мәдрәсәләрен, укыту-тәрбия һөнәрләрен саклап кала алган. Мәгърифәтчелек хәрәкәте колач җәеп, халкыбыз арасында аң-белем таралгач, аның педагогик фикере һәм күнекмәләре тагын да байый, камилләшә барган. Октябрь революциясенә кадәр үк халкыбыз Россиядә иң алдынгы урыннарның берсен алган, күп санлы педагоглар, әдипләр, галимнәр, мәдәният, җәмәгать эшлеклеләре үстергән, бу һичшиксез мактауга, горурлануга лаек нәтиҗә.

Халык педагогикасын өйрәнү, ул гына да түгел, аны торгызу, яңарту мәсьәләсенең актуальлеге нәрсә белән аңлатыла соң?

Җәмгыятебез, халкыбыз үсеш, үзгәреш чорын кичерә, ыгы-зыгылы, шау-шулы борчулы заманда яши. Бу процесс байтак кына ямьсез күренешләрне өскә калкытып чыгарды. Яхшы ният белән

башланган эшләрнең дә очы ябык тыкрыкка (тупикка) килеп терәлгән очраклары аз булмады. Бу хәлгә китергән сәбәпләр һәркемгә мәгълүм. Болар – дистәләгән елларга сузылган команда-административ системасы; этисе өстеннән донос белән йөргән Павлик Морозовны идеаллаштырган Сталин педагогикасы; мәктәпләрдә, училище һәм югары уку йортларында ялган тарих үзләштерү; ялган тәрбия эшләре; әдәбият дәреслекләрен “революцион көрәш байрагы” астында сугышу, үтерү, асу, ату картиналары, театр сәхнәләрен һәм кино сәнгатен ятак мәсьәләләре, тотнаксызлык, әдәпсезлек, рәхимсезлек үрнәкләре белән шыплап тутыру һ.б., һ.б. Нәкъ менә шулар шәфкатьлелек, әдәплелек, олыны олылау, кечене кече итеп күрү дефицитын китереп чыгарды. “Бер телле җәмгыять” дип аһ орган Сталин-Брежнев-Суслов хакимияте сабыйларыбызны туган теленнән мәхрүм итте, һәм кешелек үз телен белмәгән, милләтен милләт дип танымаган, аның язмышы өчен һичнинди җаваплылык хисе тоймаган, изге туфрагыннан аерылган, халкының тәгълим-тәрбия тәҗрибәсеннән һич хәбәре булмаган маңкортлар катламын тудырды. Рәхимсезлек, талау, кеше үтерү, хәтта ата-ана канын агызу, алдашу гадәти күренеш булып китте.

Бу хәлләрдән чыгу юлларын интенсив эзләү башланды. Шунда үткәнгә, педагог халык туплаган тәҗрибәбезгә мөрәҗәгать итү зарурилыгы, бу рухи хәзинәне бүгенге ата-анага, мәктәпкә яңадан кайтаруга мохтаҗлык гаять зур булуы ачыкланды.

Халыкның тәгълим-тәрбия традицияләренә багышланган җитди хезмәтләр иҗат ителер әле дигән өметтә калабыз.

## 1.2. АЛТЫДАГЫ – АЛТМЫШКА

*Саф әле күңелең синең, һичбер бозык уй кермәгән,*
*Пакь телең дә һич яраусыз сүзләр әйтеп күрмәгән.*
*Пакь җаның һәм пакь тәнең – барлык вөҗүдең пакь синең;*
*Син фәрештә валчыгысың, йөзләрең ап-ак синең!..*

*(Г. Тукай. “Таян аллага”)*

Туганда сабый әнә шундый саф була. Ата-анасына, милләтенә, иленә таяныч булып үссен өчен, дөньяга килүе белән аны тәрбияләү, мөмкинлегенә күрә акылын-фигылен, зиһенен үстерү башлана.

Баланың тууыннан алып, беренче адымнарын атлап киткәнгә кадәр, хәтта туганчы ук әле, халыкның балага биргән тәгълим-тәрбиясе нидән гыйбарәт булган соң?

Борын-борыннан ук билгеле: тәрбия бала тугач та башлана, һәм баланың киләчәктә үз-үзен тотышындагы, яшәвендәге чатаклыклар (көйсезлек, тискәрелек, үзсүзлелек, тотанаксызлык, эзлексезлек, елаклык, кирәгеннән артык иркәлек, сүз күтәрмәү, сүзендә тормау, хыянәтчеллек һ.б.) – начар тәрбия нәтиҗәсе. Шул ук вакытта гаиләдә бала туу – гаять зур шатлык булып саналган. Бу уңайдан бик матур гореф-гадәтләр формалашкан: бәбәй кабул итү һәм бу эштә иң актив шәхес кендек әбисенә зур хөрмәт, ышану һәм бүләкләү; бәбәй туе, балага иксез-чиксез өметләр баглап, бәхетләр теләп тирән эчке эчтәлекле һәм матур яңгырашлы, җисемгә һәм милли рухка ятып торган исем кушу; имезү, юындыру, кәефен, ашавын, йокысын яхшыртуның бөтен чараларын күрү, һәр җирдә чисталык, изге теләкләр, ягымлы сүзләр, якты йөз; сәламәтлеге ныгыганчы ананы карау, ана һәм яңа туган бала өчен мунча ягу, кулдан килгән бөтен ярдәмне күрсәтү, бәбәй туган йортка атналар буе кеше аягы өзелми. Күрше-күлән, туган-тумача һәм дус-ишләр ананың һәм яшь бәбинең

хәлен белергә килә, аларны күчтәнәче белән сыйлый, кулыннан килгән ярдәмен күрсәтә.

Баланың беренче көненнән ук туплый башлаган хәзинәсе – туган теле. Әни. Әти. Бабай. Әби. Мәми. Ипи. Сөт. Чәй. Аш. “Әлли-бәлли” – йокларга вакыт җиткән. “Тәтәй” – димәк, матур, кирәкле нәрсә! Гөл – нинди матурлык! Матурлыкка, яхшылыкка, начарлыкка сабый авазлар белән бәя бирә. Ярамаган күренешләр булса – елый. Боларның барысының да бала өчен үз-үзен саклау, тормышта ориентлашу чарасы икәнлеген гаиләдәгеләр белә һәм балага карата зур саклык, сабырлык, зирәклек күрсәтелә. Өйдә бер-береңә карата дорфалыкка, тупаслыкка юл куелмый. Киресенчә, балада уңай эмоцияләр булдыру чаралары күрелә: ягымлы йөз, ягымлы тавыш, иркә сүзләр, вакытында ашату, кулда имезү, җылы куенга, кулга алып юату. Монда ананың ягымлы тавыш белән әйтелгән ана теләкләре, сабый белән аңа гына хас һәм шул ук вакытта башкалар да аңлап торган сүз-серләр. Ана сөте белән кергән туган тел аша сабыйда газиз әнкәсенә, әтисенә, әби һәм бабасына, туганнарына, туган туфрагына, чишмә һәм урманнарга, кош-кортларга, гомумән, тереклек дөньясына мәхәббәт, аны белергә, төшенергә омтылу хисләрә дә тәрбияләнә.

Дистәләгән, йөзләгән елларга сузылган карагруһчыл тел сәясәте милләтебезне телдән аерырга маташты һәм күпмедер дәрәҗәдә үз дигәненә иреште. Байтак кына ул һәм кызларыбыз туган тел, ана теле дигән олуг нигъмәттән мәхрүм калып, “газизлек”, “якынлык” төшенчәләренең нәрсә икәнлеген онытканнан-оныта барып үстеләр, авызлары ата-бабалары ишетмәгән ямьсез сүзләр белән тулды, йөзләреннән нур качты, күзләргә әллә ниткән тонык томан төште, ата-анага кул күтәрү, әһ тә итми кан агызу гадәти күренешкә әйләнә башлады. Туган телеңне югалту милли үзаңыңны, горурлыгыңны, халкыңның әхлак чишмәләрен югалту һәм аның урынына җимерелеп таркалган рухи ихтыяҗларга тап булу дигән сүз бит ул. Ана теле аша үзләштерелгән идеяләр, белем, күнекмәләр,

башка телләр белән чагыштырганда, һәм күңел хәтеренә, һәм акыл-зиһен хәтеренә көчлерәк сеңәләр. Чөнки ана теле – тою, сизү, йөрәк теле, рухи тамыр һәм, димәк, аннан – рухи тамырдан, йөрәк теленнән – зиһен, акыл эшчәнлегенә, дөньяны танып белүгә юл кыскарак. Ана сөте белән кергән тою, сизү, рухи тел булганга да аны ана теле дип йөртәләр дә. Башка телдә, ягъни чит телдә, зиһен телендә фикер, акыл эшчәнлеге өстенлек итә. Ул тумыштан килгән, ягъни ходай биргән хәзинә түгел, ә “килмешәк” хәзинә, эшләп, көч куеп табылган хәзинә, һәм ул һичничек тә ана сөте белән сеңдерелгән кыйммәтләрне алыштыра алмый. Бала аңына ана теленнән алданрак барып урнашкан яки аны кысрыклап чыгарган телне тел гыйлемендә агрессор тел дип атау бик төгәл, чөнки ул чын мәгънәсендә сабыйны иң газиз, иң кадерле байлыгыннан аера, якты дөньяга илтәчәк туры юлына кара һәм шыксыз киртә корып куя. Тиз-тиз “милли мәктәп”кә әверелдерелгән татар мәктәпләрендә укучыларның танып-белү активлыгы, фикер эшчәнлеге зәгыйфьләнү, иҗади мөмкинлекләре саегуы моның шулай икәнлеген бик ачык күрсәтте.

Безнең әби-бабаларыбыз, тел һәм әдәбият гыйлемнәрен белмәсәләр дә, бала сөйләмендә чит-ят сүзләр буталып йөргәнен яратмаган, татарның татар белән саф татарча сөйләшүен таләп иткән. Халык өчен бу, гомумән, катгый кагыйдә булган. Татар зыялылары заманында үзара һәм үз “салоннарында” төрек, гарәп-фарсы телендә сөйләшкәннәр. Бу хәл укымышлылыкның мөһим күрсәткече булып саналса да, халык өчен ят нәрсә булган. Мәдрәсәдә син чит телләр өйрәнәсең икән, рәхим ит, белемеңне арттыр, зиһенеңне үстер, галим бул. Бер тел – бер ачкыч, ике тел – ике ачкыч. Йөргән җирендә юллар такыр булуга сәбәп булыр. Рус телен дә өйрәнү кирәк – иңгә-ин, яшибез үзләре белән. Ләкин өеңдә, кардәш-ыру, күрше-күлән, авылдашларың белән үз телеңдә сөйләш, үз ана телеңдә хәлеңнән килгән кадәр милләтеңә хезмәт ит, аны алга әйдә. Югыйсә син адәм түгел. Менә нинди язылмаган кануннарын гамәлгә керткән халык үзенең укымышлы ул һәм кызлары яшәешенә. Үз баласының нинди

шартларда зиһенле, белемгә хирыс, гаилә җанлы, кешелекле, мәгърифәтле булып үсәсен үз тәҗрибәсендә, үз җилкәсе һәм йөрәге аша ачыклаган халык.

Туган тел дәрьясына нарасый ничек чума алган соң?

Иң беренче чиратта, әлбәттә, дөньяның ин гүзәл, ин мәрхәмәтле кешесе – ана аша. Беренче сүзләр: “әни”, “әннә”, “мәммә”. Алга таба да кояштай балкып торган ана сүзләре: “бәбкәм”, “иркәм”, “гөлкәем”, “айгынам”, “йолдызым”, “батырым” (ир балага), “күгәрченем”, “күз нурым”...

*Әлли-бәлли бәүкәем,*
*Җан йөрәгем, нәнкәем,*
*Рәхәт кенә тынычлап,*
*Йоклап китәр бәбкәем.*

Дүрт юлда дүрт яратып-назлап эндәшү.

Әби яки башка кеше караса да баланы тынычландыру ана исеменнән алып барыла:

*Әлли-бәлли күз нурым,*
*Сандугачым, былбылым,*
*Әниең кайткач, тук булырсың,*
*Сабыр итеп тор, улым.*

Ана әйтә икән, ана кайтачак икән, бу инде шатлык: бала елмая, кулларын чәбәкли, изрәп йокыга китә.

Тора-бара танып-белү офыгы киңәя: әти, әби, бабай, апа, абый. Бала, гадәттә, үз якыннарына елмая, читләргә карашы кырыс була. Тагын ата-ана ярдәмгә килә: “Бу – апа, Мәдинә апа, күрше апа ул, тәти апа”. Елмаю, димәк, күрше апаны үзенә якын итеп кабул итү. Предметлар шулай, сүзләре-атамалары белән парлашып, бала зиһененә сеңә тора.

Туган телгә, иксез-чиксез дөнья киңлегенә алып керә торган бәя биреп бетермәслек әһәмиятле чыганак – бишек җырлары. Бишек җырларының төп вазифасы – бишек тирбәтү һәм баланы тынычландыру, йоклату. Еш кына бишек җырлары баланы кулда тоткан килеш тә башкарылалар. Аларның иҗатчылары – әниләр, әбиләр, бала караучы үсмерләр, шагыйрьләр. Мәсәлән, Дәрдмәнд, Тукай иҗат иткән бишек җырлары. Ә җырлау инде (сүзсез генә көйләү) ягъни башкару – монысы караучы эше: әни, бабай, әби, әти, гаиләдәге кыз яки ир бала. Бишек җырлары аша сабый тәүге мәртәбә матурлык, ананың йөрәк җылысы, ата-ана мәхәббәте, үз халкының рухы, аһәңле теле белән, туган йорт, туган тел, туган туфрак, агай-эне, чишмә суы кебек төшенчәләр белән очраша; һәрьяклап ярдәмгә мохтаҗ һәм әлегә бик тә зәгыйфь сабый бишек җырларының сүзләреннән һәм көеннән үзенә тәм һәм ямь, тәненә һәм җанына ләззәтләнү һәм ял таба, рухи тәҗрибә туплый; бишек янында иң саф хисләре, кайгы-шатлыклары, уй-хыяллары белән уртаклашкан әнисенең хәленә кергәндәй, аның теләкләрен аңлагандай була. Бишек җырларыннан ук ул үз халкының мәгърифәт яратуын, һәркемнең үз баласын укытырга тырышуын сиземләп үсә:

*Әлли-бәлли итәр бу,*
*Йокыларга китәр бу,*
*Бәү-бәү итеп, күз йомып,*
*Изрәп кенә китәр бу.*

*Алма кебек тәгәрәп,*
*Үсеп буйга җитәр бу,*
*Абыйлары артыннан*
*Казаннарга китәр бу.*

*Казаннарда укыгач,*
*Галим булып китәр бу.*

Кыз бала чибәр, зифа буйлы, акыллы булып үссен дә йөз кеше арасыннан бер генә кешегә насыйп булсын, ир бала батыр, кыю, якыннарына таяныч булып буй җиткерсен дип теләүләр исә халыкның биләүдә чактан ук балада әхлаклылык сыйфатлары, җаваплылык хисләре тәрбияли башлавы дип аңлашыла.

Бала үскән саен, тәрбия чараларының да саны арта, төрләре үзгәрә. Такмак һәм такмазалар әйтеп уяту, үчти-үчти сикертү, тез һәм аяклар өстендә сикертү, тәпи йөрергә, биергә өйрәтү, мунча кертү, юындыру, үс-үс итү, телен ачтыру, хәрәкәтләндерү, киерелдерү, сузылдыру – һәммәсе сабыйларны физик яктан чыныктыра, рухи яктан баета. Сөйләм ритмы белән хәрәкәт ритмы тәңгәл килү (бишек җыры кебек озын җырлар җырланмый), иң матур өметләр белән сугарылган теләкләр, шатлыклы-куанычлы һәм аһәңле тавыш, шат-шаян йөз бәбиләрнең гармоник үсүе өчен иң уңай шартлар тудыра.

Мисал өчен баланы коендырганда әйтелә торган юаткычны китерик.

*Суы сарыксын,*
*Үзе калыксын,*
*Тигез канатлы булсын,*
*Озын гомерле булсын,*
*Бәхетле, тәүфыйклы булсын,*
*Игелекле, шәфкатьле булсын.*

Бишек җырлары, юаткычлар, мавыктыргычлар балаларны үз поэзияләрен булдырырга, җырлы-биюле, такмаклы-такмазалы (эндәшләр, әйтенүләр, үртәвечләр, алдавычлар, иярмешләр, әйтешләр, санамышлар, тел көрмәкләндергечләр, шобага әйтешләр һ.б.) уеннарда рәхәтләнеп катнашырга һәм камил табигатьле шәхес булып үсәргә, өлгерлеккә, зирәклеккә, яхшы хәтерлелеккә, тиз арада уйлап табучанлыкка, гаделлеккә, матурлык дөньясына сукмак еалып

куя.

Бала чакта гаҗәеп кызыклы, тылсымлы, гыйбрәтле тормыш дәреслеге бар. Бу – әкиятләр. Аларга халыкның педагогик мәдәнияте, милли үзаңы, әхлак сыйфатлары, күңел матурлыгы, нәфис зәвыгы тупланган. Һәр әкиятнең ачык сизелеп торган тәрбияви максаты бар. Аларның һәрберсе гыйбрәтле, үгет-нәсихәтле, нинди дә булса әхлакый хакыйкатьне үткәрә, халык педагогикасының туу һәм камилләшү шартларын гәүдәләндерә. Образлы һәм шул ук вакытта иң нәниләргә дә аңлаешлы тел белән халык хезмәткә, тырышлыкка, күңел сафлыгына дан җырлый, югары әхлак сыйфатларын калку итеп күз алдына китереп бастыра, гаделлек һәм зирәклекне җиңүче итеп калдыра, ялкауларны, рәхимсезләрне, комсызларны, әдәпсезләрне көлке һәм мескен хәлләргә куя.

Халык педагогикасын тудыруда башлангыч омтылышларның берсе буларак, әкиятләр дә үзенчәлекле яклары белән аерылып торалар. Иң беренче чиратта бу – халыкчанлык, халыкка хас әхлак сыйфатларын гәүдәләндерү: туган илгә мәхәббәт һәм аны яклауга хәзерлек, явызлык белән аяусыз көрәш, хезмәт сөю һәм төрле һөнәрләрдә осталык, гаделлек, дус-ишләргә һәм вәгъдәгә тугрылык, иҗади активлык, табигатьне зурлау һәм аңа теләктәшлек, аның серләренә төшенергә омтылу, хайваннар дөньясын яхшы белү... Болар барысы да халыкның характерын, психологиясен, тормыш позицияләрен чагылдыра.

Әкиятләрдәге хыялый дөнья, оста уйлап чыгарулар балаларның иҗади фикерләвен үстерә. Тыңлаганда, сөйләгәндә, үз әкиятләрен тудырганда бала хыяллана, уйлап таба, үз дөньясына якын образлар тудыра һәм, әлбәттә, өлкәннәр кебек ук намуслыкны, хезмәт сөюне, тырышлыкны, гаделлекне җиңүче итә.

Әкиятләр балаларда хисләр культурасы тәрбияләве белән дә игътибарны җәлеп итә: күңеллелек, соклану, шатлык, көлү, ягымлылык һәм мөлаемлык, шул ук вакытта кайгыру, кызгану,

курку, нәфрәтләнү. Яхшылык, изгелек хакыйкатькә, гаделлеккә синоним булып йөри, чөнки, халык бәяләвенчә, изгелек һәм якынлык кына акылга сыя, ә явызлык – юләрлек.

Әкиятләрнең тәрбияви йогынтысы балалар белән генә чикләнми. Алар өлкәннәргә дә тәэсир итә. Бу җәһәттән К. Д. Ушинскийның сүзләре кызыклы: “Халык әкиятләре аша бала бөеклек һәм поэзия белән сугарыла. Халык балаларга үзенең татлы хыяллары турында сөйли һәм бу хыялларның һич югы яртысына үзе дә ышана”. (Ушинский К. Д. Избр. пед. соч. М.: Учпедгиз. -1954. - С. 57).

Әкиятләр, гадәттә, йокы алдыннан, димәк, төнлә сөйләнә. Бу – гаҗәеп отышлы традиция. Ул хәтта буыннарның рухи якынлыгы символына әверелеп китә: өлкәннәр кечерәкләргә аңлаешлы формаларда үзләренең еллар буе туплаган, гасырлар дәвамында бөртекләп җыелган әхлакый һәм рухи кыйммәтләрен тапшыралар. Әкият гаиләне бергә оештыру, үзара дус итү, өлкәннәр һәм яшьләрнең үзара рухи якынлыгын тәэмин итү чарасына әверелеп китә. Әкият сөйләнгән гаиләләрдә кешеләр үзара дус, бер-берсенә терәк-таяныч булып, иңгә-иң яшиләр. Бер дә юкка гына күренекле әдипләребез, педагогларыбыз гаиләдә әкиятләргә зур урын бирергә, аларны күпләп сөйләргә тәкъдим итмиләрдер. “Бүгенге цивилизацияле фән-техника дәверендә, – дип кисәтә Ч. Айтматов, – әкиятләргә вакыт та юк сыман, ләкин бу әкиятне тормыш-көнкүрештән кирәкмәгән әйбер кебек чыгарып ташларга мөмкин дигән сүз түгел. Бу безнең тарафтан җибәрелгән мәгьнәсезлек һәм хәтта кешелексезлек булыр иде. Үткәннең тәҗрибәсеннән йөз чөерергә ярамый. Әкият – кешелек тәҗрибәсе ул. Без әкиятләрне борынгы төзелеш сәнгате истәлекләрен саклаган кебек үк сакларга тиешбез”. (Айтматов Ч. Чыпалак // Пионерская правда. - 1970, 10 марта).

Халык педагогикасында әкиятләр белән беррәттән дастаннар, легендалар, кыйссалар, бәетләр дә зур тәрбияви вазифа башкаралар,

чөнки алар үткәнне генә түгел, бүгенгене һәм киләчәкне дә күрергә ярдәм итәләр. Татар халык авыз иҗаты азатлык өчен көрәш, тормыш-көнкүреш, гореф-гадәтләр, педагогик культураны чагылдырган эпосларга гаять бай. Алар бар да халык педагогикасының нигезен тәшкил итәләр, гаиләләрдә тормыш дәреслеге вазифасын үтәрлек тәрбияви көчкә ия булып торалар.

Үсеп килүче яшь буынга тәгълим-тәрбия биргәндә халык мәкаль һәм әйтемнәрдән файдаланган. Мәкаль һәм әйтемнәрнең тәрбияви эчтәлеге поэтика белән тыгыз бәйләнештә торуы тормышның һәр очрагын матур һәм яңгырашлы итеп аңлатып бирергә мөмкинлек бирә. Чөнки мәкаль һәм әйтемнәрдә сүзләр үзара тыгыз бәйләнгән, ритмик төзек урнашкан. Мәгънәви параллельләр, риторик сорау һәм өндәүләр, аваз ияртемнәре, гипербола, троплар һәм башка сәнгати чараларда еш кына педагогик интуиция һәм максатка юнәлгәнлек белән сугарылган тәгълим-тәрбия принциплары ярылып ята. Алар, гадәттә, афористик формада килеп, гыйбрәтле эчтәлекле булалар, халыкның уй-омтылышларын, иҗтимагый тормышка, тәрбия мәсьәләләренә мөнәсәбәтен белдерәләр. Алар халыкның тормыш-көнкүреш, тәгълим-тәрбия тәҗрибәсе, җәмгыятьнең рухи ихтыяҗлары нәтиҗәсендә, миллионлаган кешеләрнең акылы белән туганнар, буыннар яшәешендә тикшерелгәннәр, сайланганнар һәм чарланганнар. Шуның өчен дә безнең мәкаль һәм әйтемнәребез – уникаль, кабатланмас, кадерле кыйммәтләр.

Мәкаль һәм әйтемнәр кыска, аз сүзле һәм тирән мәгънәле, үгет-нәсихәтле, тиз хәтердә калалар һәм, ритмлы, мелодикалы булганга, җиңел әйтеләләр. Еш кына алар тормыш девизы ролен үтиләр. Күбесе әхлак нормаларына әверелеп киткән.

*Баланы бала арасында якласаң, әләкче булыр.*
*Баланың кулыннан пычак алсаң, алмашына таяк бир.*
*Баланы эшкә өйрәт, эшен бетерергә өйрәт.*

*Бала үлгәнгә салынса, син аны күрмәгәнгә салын.*
*Җидесендә ни булса, җитмешендә шул булыр.*
*Сабыйга ат та ат, таяк та ат.*
*Сабый хөкеме – уен.*
*Теше чыккан балага чәйнәп биргән аш булмас.*
*Тәрбиясез бала хайван булып үсәр.*
*Ачы белән төзәтәләр, татлы белән бозалар.*
*Сабый елый-елый үсәр.*

Бала үстергәндә көн дә истә торырга тиешле кагыйдәләр болар.

Табышмаклар иҗат итеп тә халык тәрбияви максатларны күздә тоткан. Табышмакларның төгәллеге, ятышлы ритмикасы һәм бертөрле аһәң белән әйтелгән предмет, күренеш яки абстракт төшенчәнең иң төп үзлеген, сыйфатын күрсәтеп, шулар аша объектның асылын, исемен эзләп табу бурычы куелу, җавапның тиз арада табылырга тиешлеге, икедән дә ким булмаган катнашучылар күздә тотылу балаларда зирәклек, тапкырлык, логик фикерләү сәләтен үстерә, сөйләмне камилләштерә. Поэтик яктан гаҗәеп матур төзелгән бу әсәрләр – балалар өчен эстетик ләззәт чыганагы. Берничә мисал.

*Урманда урынсыз, кырда койрыксыз. (Җил)*
*Кара мыеклы җизнәм сагындырып килгән. (Яз)*
*Борынсыз чыпчык боз тишә. (Тамчы)*
*Күктән килде, җиргә китте. (Яңгыр)*
*Ак ашъяулык таптык, җир өстенә яптык. (Кар)*
*Агач үгез, оч мөгез. (Сәнәк)*
*Суда туды, җирдә үлде. (Балык)*
*Әлем-әлем әлем күк*
*Бөгәрләнгән мәче күк,*
*Аны кеше тоталмый,*
*Тәпиләрен куралмый. (Керпе)*

Өч-дүрт яшьлек балалар да һич тотлыкмыйча бик яратып әйтә торган мондый табышмакларны иксез-чиксез санда иҗат иткән халкыбыз.

Югарыда санап киткән чаралардан тыш тәрбия, белем һәм күнекмәләрне балага әти-әни, әби-бабай һәм башка өлкәннәр (абый, апа, җиңги, җизни һ.б.) тарафыннан турыдан-туры гаиләдә, көндәлек эш, йорт мәшәкатьләре барышында күрсәтмәләр аша бирү дә гадәти күренеш булган.

Әйтик, бала үзен табын янында ничек тотарга тиеш? Моңа өйрәтү турыдан-туры табын хәстәре вакытында кыска-кыска күрсәтмәләр төсендә барган.

- *Кызым (улым), әти-әнидән алда табын янына килеп утырма.*

- *Әти-әнидән алда кашык тотып ашка сузылма.*

- *Табын янында борыныңны тартма, чөмереп ашама.*

- *Аш алдыннан, аштан соң кулыңны ю, авызыңны чайка.*

- *Ипи валчыкларын коеп ашама, ипинең рәнҗеше төшәр.*

- *Ипи өстенә әйбер куйма, ипидән өстен нәрсә юк.*

- *Ипекәйнең валчыгы да бездән олы, коеп ашама.*

- *Ипи валчыгыңны җый, йорттан бәрәкәт очмасын.*

- *Ашны күрсәң, кадер тот, дусны күрсәң, гадел тот.*

- *Сыныгыңны ашап бетер, бәхетеңне калдырасың бит.*

- *Яманнан ярты кашык аш калыр.*

- *Ит иткә, шулпасы биткә.*

- *Чүлмәктән ашама, кешеләр арасында сүзең үтмәс.*

- *Пычак белән ашама, кешегә пычак булып кадалырсың.*

- *Як-ягыңа күп каранма, ризыксыз калырсың (ашыңны җен ашап китәр).*

- *Ашыгып ашама, ашаганың тәнеңә йокмас.*

- *Чәеңне чөмереп эчмә, ямьсез булып үсәрсең.*

- *Ашаганда киерелмә, үсми калырсың.*

*- Ашка рәхмәт әйт.*

*- Кеше пешергән ашны кашык тыгып болгатма.*

*- Тавышлы табыннан фәрештә качар.*

*- Күп ашасаң, бал да ачы була.*

*- Вакытында туя бел, кашыгыңны куя бел.*

*- Өстәлне кәгазь белән сөртмә, тавыш чыгар.*

Менә бала әтисе, әнисе, я булмаса әбисе я бабасы белән урам буйлап бара. Анда да күрсәтмәләр:

*- Олыларга үзең башлап сәлам бир.*

*- Өлкәннәргә юл бир.*

*- Алдыңны-артыңны карап йөр, эт килеп тешләмәсен (каз таламасын; корт килеп чакмасын; абынып егылырлык булмасын һ.б.).*

*- Сызгырып барма, янгын чыгар.*

*- Коега төкермә, суын эчәсең булыр.*

*- Юлдан ерак уйна.*

*- Урам үләнен йолкыма, үлән йолку фәрештә канатын сындыру бит ул.*

Урманда, кырда:

*- Урман үстер, ачлык күрмәссең.*

*- Урманга шырпы белән бармыйлар.*

*- Агач үлеме балтадан.*

*- Корт баскан черек ботакны кисмә.*

*- Суга төкермә, үзең төшәрсең.*

*- Яшь агачны сындырма, яшь гомерең өзелер.*

*- Җимешен аша, ботагын сындырма.*

*- Урманга кергәнче чыгар юлыңны кара.*

*- Агачның тамырына балта чабып, киләчәгеңне караңгылама.*

*- Агачның тамырына балта чапканчы, киләчәгеңне уйла.*

*- Яшь үләндә арык мал да уйнаклый.*

*- Җимеш ашыйсың килсә, чәчәген өзмә.*

*- Кошларны рәнҗетмә, каргарлар.*

*- Кошларга таш атма, күзең сукыраер.*

*- Бер дә юкка үлән йолкып йөрсәң, кулың корыр.*

*- Сыерчыкларга оя яса, эшең уңар.*

*- Баканы үтермә, кайгыдан башың чыкмас.*

*- Кош йомыркаларын ватма, күз яшеңне түгәрсең.*

*- Хайваннарны кыерсытма, үзеңә килер.*

Яки менә бала кунакта:

*- Ашарга өйрәнмичә ашка барма.*

*- Алдыңа куйган ашны хурлама.*

*- Алдыңа куйганны тавышсыз-тынсыз аша.*

*- Кунак теләгәнен түгел, күргәнен ашар.*

*- Ишек ачык булса да, сорап кер.*

*- Кунак туймаса да рәхмәт әйтер.*

*- Әдәпле кунак китәр вакытын үзе белер.*

*- Өч көн кунак бул, өч көннән соң ерак бул.*

*- Кунакның беренче көне – алтын, икенче көне – көмеш, өченче көне – бакыр, дүртенче көне – такыр.*

Мондый кисәтүләр бик тә тирән мәгънәгә ия. Мәсәлән, “Урманга шырпы белән бармыйлар” диелә икән, өеңнән чыкканда ук урманга карата яхшы нияттә булып юлга чыгарга кирәк, шырпы алып, учак яндырып йөрергә чамалыйсың икән, янгын чыгуы, үзеңә генә түгел, йөзләгән кешеләргә зарар килүе бар, никадар агач (ягулык, төзү материалы, иң мөһиме – матурлык, муллык), җиләк-җимеш, тирә-юньдәге чәчүлек җирләре әрәм булачак – менә шулар күздә тотыла. Шулай булгач, югарыда әйтелгән кисәтү – балада

урманга, табигатькә карата сак мөнәсәбәт тәрбияләү чарасы ул.

Тәрбия белән бергә янәшә бер тоташ агым булып балага тәгълим бирү процессы, ягъни “зиһен сабагы” да бар. Ата-ана үз баласына (әби – баба – оныгына) кышкы озын кичләрдә гарәп алфавиты өйрәткән. Гадәттә бу, эшләр бетеп, йокларга яткач, бөтен йорт-җиргә тынычлык иңгәч үткәрелгән. Әти, әни, әби яки бабай сәкегә (сәндерәгә) тезелеп яткан балаларга “әлеп”, “би”, “ти”, “си”, “җим”, “хи”, “дал”, “зәл”... дип кабатлаткан. Айлар буе кабатлый торгач, 3-4 яшьлек бала да алфавитны яттан әйтә алырлык дәрәҗәгә җиткән. Моннан соң инде догалардан, сүрәләрдән өзекләр ятлау китә. Хәтер, зиһен үсә, тел шомара, колак һәм күңел мелодика, моң нюансларын тоярга күнегә.

Гаилә мәктәбеннән инде бала мәктәп-мәдрәсәгә юл тота.

Бөтен игътибарны яшь балага туплау, тәрбия эшләрен аның туган минутыннан ук башлау һәм иң отышлы, нәни бала табигатенә иң яраклы чаралардан талантлы, комплексны итеп, баланың һәрьяклап гармоник үсүен тәэмин итәрлеген генә сайлап файдалану халык педагогикасының зирәклеге, кыйммәте турында сөйли.

## 1.3. КӨН – ЭШЛӘРГӘ, ТӨН – ЙОКЛАРГА!

Хезмәттә яшәү – халыкның төп халәте. Хезмәт сөюче яшьләр тәрбияләү – иң мөһим максат. Хезмәтка хәзерләү – беренче чираттагы бурыч. Кешелекнең педагогик культурасы – хезмәт ияләренең педагогикасы ул. Хезмәт – гомумән, халыкның тормышы. Шуның өчен дә хезмәт тәрбиясе халык педагогикасының йөрәген тәшкил итә, аның кан йөрешенә җан биреп тора, дисәң дә хакыйкатькә хилафлык итү булмас. Чөнки халыкның алдынгы традицияләре: пакьлеге, әхлакый сафлыгы, гаделлеге, кешелеклелеге, сабырлыгы, зирәклеге, матурлык идеаллары – барысы да хезмәт даирәсенә урнашкан. Үз башлангычын һәм үсешен дә шул даирәдә гамәлгә ашырган. Хезмәттән башка физик тәрбиянең дә, әхлак тәрбиясенең дә, акыл тәрбиясенең дә үткәрелүе мөмкин түгел. Хезмәт – чын һәм киң мәгънәсендә тәгьлим-тәрбия эшләренең башы һәм дәвамы. Хезмәт сөю – бу эшләрнең нәтиҗәсе, яшь буынны тәгьлим-тәрбия итүнең көтелгән йомгагы, әйтергә ярый, җимеше. Менә ни өчен халыкның алдынгы традицияләрен өйрәнү, яшь буынга хезмәт өлкәсеннән тәгьлим-тәрбия тәҗрибәсен өйрәтү дип тә аңлашыла.

Хезмәт сөю һәм хезмәт кешесенә хөрмәт тәрбияләү – халык педагогикасының иң мөһим кануны, һәм ул балаларга сабый чактан ук сендерелгән. “Әтиегез эштән кайта, юынуына җылы су хәзерләп куегыз. Су салып торыгыз”, “Әтиегез кайтуына ишек алдын чистартып куегыз, арып кайткан атаның күңеле булыр”, “Апагыз өй җыештырды, арыгандыр, ял итеп алсын, тавышланмагыз”һ.б. Бала-чагадан уенчыкларын, уен урыннарын тәртиптә тоту таләп итәлә. Әни һәм апалар курчакка кием-салым тегәргә, әти-абыйлар эш-уен кораллары ясарга ярдәм итә. Шуларга хыял-иҗат итү, үз уеннарыңа кирәкле әйберләр ясау аралашып-ялганып китә. Әкренләп балалар уенлы тормыштан зурлар тормышына күчә баралар, һәм курчак

тегеп, уенчык ясап формалашкан күнекмәләр көнкүрештә кулланыла башлый. Дөрес, башта эш кораллары җиңел, матур итеп, өлкәннәр тарафыннан уенчыкларга охшатыбрак эшләнә: кечкенә көянтә-чиләкләр, кечкенә савыт-сабалар, кечкенә балта, пычкы, тырма, сәнәк, көрәк, чалгы һ.б.

Материаль культурабыз истәлекләре арасында күп санда балчыктан ясалган уенчыклар саклана: болар болгар осталарының әйберләре. Аларның бер төрле булулары уенчыкларның күпләп эшкәртелүе, сатылуы һәм балачакның мәгънәле үтүе өчен шул вакытларда ук зур кайгыртучанлык күрсәтелүе турында сөйли.

Яшь буынны хезмәткә хәзерләүнең эчтәлеге халыкның икътисади яшәеше белән билгеләнгән. Татар халкы мал асраган, иген иккән, һөнәрчелек белән шөгыльләнгән, сату иткән, көндәлек тормышын җиренә җиткереп, бөтен итеп алып барырга тырышкан һәм армый-талмый хезмәт иткән. Иртә таңнан караңгы төшкәнче һәркем эштә: әби- бабай, әти-әни, апа-абый, олысы-кечесе. Балалар да өлешсез түгел: үз-үзеңә хезмәт күрсәтү, тавыклар ашату, чебиләр куу, чебеш, каз саклау, кечкенә эне-сеңелләрне карашу, вак-тояк йомышларга йөрү. Зурларның җитди хезмәте дә еш кына алардан башка мөмкин түгел: кадак биреп тору, эчәсе килгәннәргә су тәкъдим итү, әни-әбигә вак йомычка кертү, басуга ризык илтү, аяк киемнәрен, бияләйләрне кибәргә кую, эштән-юлдан кайтканнарның киемнәрен элеп кую һ.б. Үсә төшкәч сәдәп тагу, ямаулык салу, үз әйберләреңне, өстәл, кул тастымалларын юып кую, бәрәңге әрчү, өстәл җыештыру, хәзерләшү... Шул ук вакытта өлкәннәр эшен күзәтү , алар кул астына керү процессы да бара. Бер дә юкка халык мич чыгаручы, тегүче, балта остасы гаиләсендә бала туса, “авылга тагы бер тегүче артты”, “балта остасы туды” дими. Кыз балалар әниләреннән чигәргә, тегәргә, эрләргә, бәйләргә, тукырга өйрәнәләр. Үсеп җиткәч, иптәш кызлар, үзара ярышып, бер-берсеннән уздырып, нәфислек һөнәрләрен камилләштерәләр, соңыннан һөнәрләрен үз балаларына тапшыралар.

Шул рәвешчә, халкыбыз тәҗрибәсендә һәркем үзенчә, индивидуаль башкарган хезмәт иҗтимагый хезмәт тә булып киткән.

Балалар, үсмерләр, яшьләр өчен тагын да гыйбрәтлерәк, эчтәлекле, күңелле, бергәләп эшләргә мөмкин булган хезмәт – өмәләр: каз өмәсе, язларын бер-береңнең өен юышу, авылдашның бурасын күтәрү, ярлы-ябагай, карт-корыларга йорт салышу, такта яру, печән чабу, киндер туку. Эшне күңелле итеп, бер-береңә ярдәм итә-итә башкару, өзлексез уен-көлке, җор сүзләр, мәзәк сөйләшү, эшкә булдыксызларны, ялкауларны үз итеп кенә “чеметтереп” алулар, уңганнарның сүзенә колак салү, киңәшеп эшләү, акыллы һәм булган, тәҗрибәле кешеләргә хөрмәт-ышанычның күзгә бәрелеп торуы – болар бар да шул тирәдә кайнашып, чыр-чу килеп йөргән бала-чагага көчле тәрбияви йогынты ясаган.

Балаларның педагогик хезмәт башкаруы һәм моны зур осталык белән үтәве – үзенә бер тәрбия мәктәбе. Бу хезмәт халкының, гомумән, зур гаиләле халык булуы белән аңлатыла. Элек күп гаиләдә кимендә 4-5 бала үскән. 7-8 һәм аннан да ишлерәк балалы гаиләләр дә гаҗәпләндермәгән. Төпчек баладан калганнары барысы да бәләкәч турында кайтыртуны, аны иркәләүне, күңелен күрүне үзенең бурычы санаган: бишеген тирбәткән, урамга алып чыгып уйнаткан, әни-әби югында ашаткан, эчерткән, юындырган, күңелен ачкан, әкрен генә көйләгән, әкиятләр сөйләгән, уеннар һәм уенчыклар уйлап тапкан. Монда инде кечкенә генә йомычка, таш кисәкләре дә, ком-туфрак өемнәре дә әллә нинди могҗизаи сарайларга, тау-ташларга әверелеп киткән. Тәрбияләү һәм тәрбияләнүче рольләреннән торган уеннар үзләре ни тора! Берәүләр – укытучы (хәлфә, абыстай), а икенчеләре – шәкертләр. Берәүләр – кунакка килгән, икенчеләре – аларны ачык йөз һәм шатлык хисләре белән каршы алырга чыккан хуҗалар. Берәүләр – әти, әни, икенчеләре – тынлаулы, игелекле балалар. Тыңлаусызларга, әлбәттә, тиешле җәзасы да бирелә. Чыны белән зурлар игьтибарын да җәлеп

итәрлек, аларга үзләрен күрсәтеп торган гыйбрәтле процесс бу, шул ук вакытта тулы канлы ижади хезмәт процессы да.

Өлкәннәр белән бергәләп хуҗалык һәм иҗтимагый эшләр башкарылганда яшьләргә үгет-нәсихәт тә бирелеп тора:

- *Хезмәт кешесенә игътибарлы бул.*
- *Бакма авызындагы тешенә, бак кулыңнан килгән эшенә.*
- *Агач җимеше белән, кеше – эше белән.*
- *Хезмәт сөй. Данны эзләүче түгел, эшләүче таба.*
- *Сәламәт буласың килсә, аз аша, макталасың килсә, күп эшлә.*
- *Ашына күрә табагы, эшенә күрә бәһәсе.*
- *Эш сөйгәнне мир сөя.*
- *Тырышкан табар, ташка кадак кагар.*
- *Ялкаулык – хурлык, тырышлык – зурлык.*
- *Ялкау аягүрә йоклар, ятып эшләр.*
- *Ялкау бер эшне ике мәртәбә эшләр.*
- *Кул кушырып утырган ач калган.*
- *Һөнәрләр бел. Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз.*
- *Авыр эшкә беләк бар, кыю эшкә йөрәк бар.*
- *Эшеңне ахырына җиткер.*
- *Башлаган эшне ташлама.*
- *Бүгенге эшне иртәгәгә калдырма һ.б.*

Намуслы тырыш хезмәт макталмаган әкиятләр сирәк. Тырышлык белән өстен чыккан эшчән кызлар һәм егетләр турында әкиятләр сөйләп, өлкәннәр яшь буынны кеше эшчәнлегенең иксез-чиксез даирәләре, мөмкинлекләре белән таныштырганнар, һөнәрчелекнең серләре белән мавыктырганнар, тырыш хезмәтнең нәтиҗәсен күрсәткәннәр, хезмәтнең һәм хезмәт кешесенең кадерен белергә, ялкаулыктан читләшергә өйрәткәннәр.

Башка халыклар кебек үк, татарларның да тормыш-көнкүреш культурасы, рухи төзелеше меңләгән еллар буена иген игү, җир эшкәртү цивилизациясе аша формалашкан. Шул җирлектә

игенчелеккә, мал асраучылыкка, ел фасылларына бәйле йолалар формалашкан. Күп кенә әхлак нормалары, әхлакый күзаллаулар, рухи кыйммәтләр, зәвыклар кешенең җир-анага мөнәсәбәте белән билгеләнгәннәр. “Безнең бабайларның һәр сүзендә, һәр ым-ишарәсендә шигъри бер тирән мәгънә ята. “Язга”, “җәйгә” чыкканнар алар, “көзгә-кышка” кергәннәр. “Көз- кыш“ – вакытның мәшәкатьле, авыр мизгелләренә керү булса, “яз-җәй” исә әнә шул авырлыктан, кышкы бимазалардан чыгу, котылу булып саналган” (Гыйләҗев А. Эзләремне эзләдем // Идел. – 1991. - №№ 10-11. Б. 5 ).

Авыл кешесенең тир түгеп, теше-тырнагы белән җир эшкәртүе, иген игүе, мал асравы, ат каравы, икмәкне игелек культына күтәрүе малтуарны кадерләп тәрбия итүе һәм боларның барысына да милли горурлык билгесе итеп каравы яшь буында хезмәткә һәм хезмәт кешесенә мәхәббәт хисләре үсүгә сәбәп булган. Шул нигездә әхлак нормалары да формалашкан: “Сабанда сайрашмасаң, ындырда ыңгырашырсын”, “Бер язгы көн ел буена туйдыра”, “Иген иккән морадына җиткән”, “Икмәксез алтын тавы башында да үлүең бар”, “Ни чәчсәң, шуны урырсың”, “Басудагы икмәк түгел, келәттәге икмәк” (Урып-җыю чорын вакытында тоеп алырга кирәк, өлгергән орлык коелып бетәргә мөмкин), “Икмәк – ил тоткасы”, “Икмәк – җир һәм кояш баласы”, “Җир җылысын йөрәгең белән той”, “Икмәкне күкрәгеңә терәп кис, йөрәк җылыңны тойсын”, “Ипекәйне әрәм-шәрәм итү – зур гөнаһ”, “Ипекәйне кадерсезлемә, үзең кадерсезлеккә төшәрсең”.

Авыл җирендә ипи салу изге йола булып саналган. Аны мәшәкатьле эш итеп түгел, ә иң кадерле, иң мактаулы, изге бер мөкатдәс йола башкаргандай, бар шартын китереп, җиренә җиткереп, куана-куана салганнар безнең хатын-кызлар. (Мөхәммәт Мәһдиевнең “Бәхилләшү” исемле моңлы повестында икмәк салу эше нәкъ шушы олы, изге мәгънәдә тасвирлана да). Кабарып торган күмәч пешерү, тегермән ташы кадәр итеп ашап туймаслык икмәк пешерү – хатын-кызга фарыз сыйфат саналган. Киленнәргә бәя аның

икмәк пешерә белү-белмәве белән дәлилләнгән. “Ипекәй” /әнкәй, эткәй, әбкәй / дип кадерләп, хөрмәт белән бер төрле дулкынланып әйтү бүгенге өлкән буын кешеләренең кайберләренә хас. Болар инде, һичшиксез, җир-ана кадерен белеп үскән кешеләр булыр.

Гомумән, халык педагогикасы хезмәт тәрбиясе мәсьәләләрендә кешенең көчен һәм мөмкинлекләрен идеаллаштыра, аның акылына, бөтен кыенлыкларны җиңеп чыгачагына ышануына нигезләнә. Шул уңайдан Г. Латыйпның “Сеңеп калган" шигырен китерү урынлы булыр кебек.

*СЕҢЕП КАЛГАН*

*Эшләп аргач, буразнада*
*Черем итеп алганым бар.*
*Көзге яңгыр асларында*
*Ләмгә батып калганым бар.*

*Үзәннәрдә уелып калган*
*Кабатланмас эзләрем бар;*
*Туган җирем, әле сиңа*
*Әйтелмәгән сүзләрем бар.*

*Күкрәгенә терәп эткәм*
*Ипи кисеп биргәне бар;*
*Икмәктән дә зур нәрсә юк,*
*Кадерең бел син, дигәне бар.*

Никадәр газиз, изге хисләрне туплаган бу шигъри юллар! Алар нигезенә салынган халык педагогикасы идеяләре бүген дә көнкүрешебездә яңарса икән!

Шулай итеп, халык тәҗрибәсе балаларда хезмәткә һәм хезмәт кешесенә мәхәббәт хисләре, тырыш хезмәт күнекмәләре тәрбияләүнең киң һәм күпкырлы методикасын тудырган, аны өлкәннәрнең шәхси һәм иҗтимагый эшчәнлегенең барлык яклары белән да тыгыз бәйләнештә караган.

## 1.4. ҖИРНЕҢ НУРЫ – КОЯШ, КЕШЕ НУРЫ – ГЫЙЛЕМ

Халкыбыз элек-электән аң-белемгә, мәгърифәткә омтылып яшәгән, укымышлы кешеләрне зурлаган, укырга яки укыганны тыңларга (укый белмәсә) яраткан, китап сөйгән, китап сүзен хакыйкать сүзенә тиңләгән, балаларның интеллектуаль үсеше өчен зур кайгыртучанлык күрсәткән. Халыкның гыйлем-мәгърифәткә мөнәсәбәте һәм бу өлкәдәге тәгьлим-тәрбия тәҗрибәсе халык авыз иҗаты әсәрләрендә аерата калку гәүдәләнә. Баланың мәдрәсәдә укуына, галим булып китүенә өметләрне чагылдырмаган бишек җырлары бездә юктыр. Ә мәкаль һәм әйтемнәр: “Беләге юан берне егар, белеме булган меңне егар”, “Белемле үлмәс, белемсез көн күрмәс”, “Гыйлемлек – нур, наданлык – хур”, “Укыган ил төзер, укымаган ил бозар”, “Белгәнгә төн дә якты, наданга көн дә караңгы”, “Алтынга омтылган югалган, акылга омтылган юл алган”, “Мең алтын ташың булганчы, бер акыллы башың булсын” һ.б. Боларның һәрберсе халыкның белемгә зур өмет, ышаныч белән каравы, укымышлылыкны әллә нинди байлыклардан да өстен күрүе, наданлыкны хурлыклы сыйфат итеп билгеләвенә дәлил.

Әкият батырлары, гүзәл кызлары халык вәкилләре буларак күзалланалар, катлаулы сорауларга, зирәклекләре аркасында, тапкыр җаваплар табалар. Фикерләүгә сәләтле һәм акыллы булулары аларны гаять кыен һәм четерекле хәлләрдән дә җиңүче булып чыгарга ярдәм итә. “Диюләрне җиңгән”, “Дутай батыр”, “Әйгали

батыр", “Таң батыр”, “Корчаңгы тай” – нәкъ әнә шундый әкиятләргә мисал булып тора. Халык, эшләре тәмам булгач, балалар укытуны максат итеп куйган, мәктәпләр ачкан геройларны да яратып иҗат итә: “Саран һәм юмарт”, “Кара таяк” һ.б. “Таң батыр”, “Аучы һәм кыз”, “Алтын кош” һәм башка әкиятләрдә халык хатын-кызларның зирәклеге, акылы тирәнлеге, үткенлеге турында сөйли.

Табигать күренешләрен күзәтеп, нәтиҗәләр ясау, аларга аңлатма бирергә тырышу да халыкның зирәклеге, гыйлемен яшьләргә, киләчәк буыннарга калдырырга омтылуы һәм аларның акылын үстерүне максат итеп куюы турында сөйли. Кешеләр элек-электән вакытның төгәл исәбен алып барырга, елларның һәм ел фасылларының, аерым айларның, көннәрнең ничек киләсен, аларда һава торышының, көнкүреш, сунарчылык, терлекчелек, игенчелек өчен шартларның нинди буласын, шуңа бәйле рәвештә үзләрен нинди уңыш-шатлыклар яки бәла-казалар көткәнен алдан ук белеп-чамалап торырга, тиешле хәстәрен күрергә тырышканнар. Шулар нәтиҗәсе буларак, төрле календарьлар төзелгән, юрау-сынамышлар, йола-ритуаллар иҗат ителгән, яшь буын аларны үзләштереп үскән, үсә-картая төшкәч, төгәллекләр керткән.

Мәсәлән, җәйләрен:

*Ай очы белән туса, көннәр явымлы булыр.*
*Бер урыннан бер урынга күчеп күк күкрәсә, боз булыр.*
*Йолдыз атылса, җил булыр.*
*Кояш чыккач, кызыллык тиз бетсә, һава бозылыр.*
*Чык тиз кипсә, яңгыр булыр.*

Көзләрен:

*Боз кытыршы булып туңса, иген уңар.*
*Агач яфракны соң койса, ел авыр килер.*

*Көз бик озак торса, ашлык уңмый.*

Кышларын:

*Кояш бик еракта булып күренсә, яңгыр булыр.*

*Кояш тирәсендә нурлар югары чагылса – буран булыр, түбән чагылса – салкын булыр.*

*Кар бүрәнәгә сырышып яуса, җәй яңгырлы килер.*

*Самовар борыны тыгылса, салкын булыр һ.б.*

Вакытның серләренә төшенү һәм кадерен белү, һәр эшне үз вакытында эшләү кирәклегенә басым ясаган иксез-чиксез мәкаль һәм әйтемнәр барлыкка килгән: “Һәр нәрсәнең вакыты бар”, “Вакытлы эш вакытында яхшы”, “Бүгенге эшне иртәгәгә калдырма”, “Вакыт акча түгел, югалтсаң, таба алмассың”... Дистәләгән, йөзләгән еллар буена күзәтүләрдән, тормыш тәҗрибәсеннән сөзеп алынган һәм халык тарафыннан тудырылган тәгълимат болар.

Дару үләннәренең, агач кайрыларының савыктыргыч хасиятләренә төшенгән һәм үзенең медицинасын, шулай ук балалар өчен “өй гигиенасын” тудырганын да исәпкә алсаң, үзеннән-үзе Габдулла Тукайның “...халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул” дип әйткәннәренә “галим ул” дип тә өстисе килә.

Акыл, зиһен, хәтер, белем күзәтү-нәтиҗәләр, көндәлек тәҗрибә аша тупланган мәгълүматлар исәбенә генә баемый һәм үткенләнми. Бигрәк тә китапка зур өметләр баглана. Озын кышкы кичләрне күз алдына китерик. Кырда, бакчада эшләр тәмамланган, йорт тирәсендәге эшләр, өй эшләре – алары инде көндәлек мәшәкатьләр. Кышкы төннәр озын. Хезмат халкы алай озак йокы симертергә яратмаган. Нишли? Кич утыра. Үз гаиләсе белән генә түгел, күрше-күләнен җыеп, я булмаса башка берәүгә барып. Кемгә җыелалар? Керосины булганнарга, өе иркенрәк, күңеле киңрәк булганнарга,

әлбәттә, һәркем эштә. Хатын-кыз җеп эрли, бәйли, чигә, тегә, ямау сала. Ир-ат чабата үрә, итеккә олтан сала, эш коралларын үткенли, кайрый, бау ишә... Лампа яки чыра яктысы төшеп торган өстәл артында шәкерт китап укый. Кыйссамы ул, легенда яки дастанмы, бәет яки мөнәҗәтме – барысы да йотлыгып тыңлыйлар. Һәр кичне тыңлый торгач (башка китап юк), ятлап бетерәләр. Ниләр буласын да белеп торалар, әмма тыңлыйлар. Чөнки тыңлаган саен яңа детальләр ачыла, образлар гаҗәеп, сүзләр тылсымлы, камил поэтика, дулкынландырып, тибрәлдереп торган мелодика сихерле. Балалар да тып-тын. Баштарак, әйтик, аңламыйчарак та торырга мөмкиннәр, өлкәннәрдән шүрләгәнгә генә тынып калганнар. Тора-бара алар да поэзия дөньясына чума. Алар да әсәрнең байтак өлешен ятлап өлгерәләр, урманга-кырга барганда яки урамга чыккач, янәдән бер-берсенә сөйлиләр, укылган буенча фикер-хис уртаклашалар, теге яки бу эпизодка үзләренчә ачыклык кертәләр, геройларның хәл-әхвәлләрен үзләренчә күзаллыйлар. Кич утырган өлкәннәрнең әсәр турында үзара сөйләшуләре, сабыр гына, моңлы гына гәпләшүләре – балалар өчен тормыш-поэзия мәктәбе.

Халкыбызның рухи тормышында гүзәл бер казаныш – үз җилкәсендә мәктәп-мәдрәсәләр тоту, ничек булса да балаларны мәктәп-мәдрәсәләрдә укытырга тырышу. Христианлаштыру афәтләре аркасындамы, ачлык яки башка сәбәпләр беләнме, безнең халык яңа җирләргә күпләп килеп урнашу белән ук мәктәп-мәдрәсә оештырырга тырышкан. Бу аның бай рухи һәм тарихи традициясеннән килә. Бу традиция халкыбызның элек-электән укый-яза белүгә омтылу, аң-белемгә, төрле гыйлемнәргә хөрмәт белән карау кебек күркәм сыйфатларына барып тоташа.

Укыту процессы бездә бик күптәннән, Х гасырда ук, Ислам дине кабул ителеп, мәчетләр һәм алар каршында мәктәп-мәдрәсәләр ачылгач ук башлана. Урта гасыр гарәп галиме Ибне Рустә Болгарның үзендә һәм Сувар шәһәрендә мәчетләр каршында мәдрәсәләр, хәтта авыл җирләрендә дә башлангыч мәктәпләр булуы турында яза.

“Волгарларның, – ди ул, – күпчелеге ислам динен тота, авылларында имамнар һәм мөәзиннәр торган мәчет һәм мәктәпләр бар”. (Известия о хазарах, буртасах, болгарах, мадьярах, славянах и русах Абу-Али Ахмеда бен Омар Ибн-Даста, неизвестного доселе арабского писателя X века, по рукописи Британского музея в первый раз издал, перевел и объяснил Д. А. Хвольсон, профессор С.-Петербургского университета : напечатано по случаю пятидесятилетнего юбилея С.-Петербургского университета. - С.-Петербург : типография Императорской Академии наук, 1869. -XIV, 199 с. С. 23). X-XШ гасырларда Болгар илендә булган сәяхәтчеләр дә болгарларның шәһәрләрендә, зур авылларында мәктәп-мәдрәсәләр булуын, шул чорда яшәгән галимнәрне, кулъязма китапларны искә алып китәләр. Казан ханлыгы чорында да мәктәп-мәдрәсәләр булган, кулъязма китап язу белән шөгыльләнүче профессиональ көтебчеләр яшәгәннәр. (Кәримуллин Ә. Укый-яза белгәнбезме? // Социалистик Татарстан. 1988, 20 июль). Казан ханлыгы Россиягә кушылгач та, гасырлар буена милли изү сәясәте алып барылуга, төрле чикләү һәм эзәрлекләүләргә карамастан, мәктәп-мәдрәсәләр белем учагы, мәдәният үзәге булудан туктамаган. Дәүләттән бер тиен дә алмыйча, крестьяннар үз исәбенә мәктәп-мәдрәсәләр ача, хәлфә-мөгаллимнәр яллый, балаларына ничек булса да аң-белем бирергә тырыша, русчага да өйрәтү хәстәрен күрә.

XIX йөздә татар тормышына капиталистик мөнәсәбәтләр үтеп керү, аерата милли азатлык хәрәкәтенең активлашып китүе, 1905-1907 еллардагы революция тәэсирендә татарлар арасында яңача укыту – җәдитчелек хәрәкәте башланып китә. “Татар тарихында халык күңелен мәктәпләрне яңарту мәсьәләсе кебек борчыган мәсьәлә булмагандыр”, – дип яза Җ. Вәлиди, татар халкының яшь буынга – дөньяви белемнәр биреп, аның аң-белемен үстерергә омтылышын ассызыклап. (Джамалютдин Валидов. Очерки истории образованности и литературы татар (до революции 1917 года). Государственное издательство. Москва-Петроград, 1923, 143 с. С.

46). 1910 ел башында инде Казан губернасындагы мәктәпләрнең 90 процентында яңа ысул белән укытылган. Ул вакытта Казан губернасында 1088 татар мәктәбе һәм мәдрәсә исәпләнгән. (Нафигов Р. И. Формирование и развитие передовой общественной мысли. Казань: Таткнигоиздат. 1964, с. 53). Казанның үзендә 36 мәдрәсә һәм алар каршында 17 мәктәп эшли. Шул 36 мәдрәсәнең 12 се урта, 12 се тулы булмаган югары, 12 се югары типта булган. Югары типтагы мәдрәсәләр, асылда, хәзерге шәрык телләре институтындагы кебек үк гуманитар белем биргән. Андый мәдрәсәләрне тәмамлап чыгучылар кимендә өч тел: борынгы төрки, гарәп, фарсы телләрен, еш кына төрек телен дә белгәннәр. 1913 елда Казанда татар кызлары өчен махсус җиде җәдит мәктәбе булган. Егетләр, кызлар укый торган мәктәп һәм мәдрәсәләр башка регионнарның шәһәр һәм авылларында яшәүче халыкларга да хезмәт итеп килгән. (Мостафин Р. Артта калган надан халык һәм башка идеологик штамплар турында // Татарстан. 1991. - № 7. Б. 4-8.). Күренекле мәдрәсәләрдән Казанда “Мөхәммәдия”, “Мәрҗания”, “Касимия” һ.б. булса, Уфада – “Галия”, “Госмания", “Хәсәния”, Уральскида – “Мотыйгия", Оренбургта – “Хөсәсния”, Троицкида – “Рәсүлия”, Бубида – “Буби” һ.б., һ.б. саналалар. Аларда дин белән бергә дөньяви фәннәр дә укытылган. Мисалга 1910 еллар башында “Мөхәммәдия” мәдрәсәсенең уку планына кертелгән предметларны санап китик: Коръән, Диннең зарурлыгы, хәдис, мәкам (көйләп уку), хифыз (ятлау). Калган 15 предмет тулаем дөньяви: рус теле, фарсы теле, гарәп теле, хисап, география, тарих, табигать белеме, матур язу, рәсем, исәп-хисап (счет), төрки (ягьни татар теле кагыйдәләре), төркичә (ягьни татарча) уку, диктант, изложение, фикъһе (юриспруденция).

Кызлар укый торган Ф.А. Аитова мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты, арифметика, география, тарих, табигать белеме, рәсем, матур язу, рус теле, чигү-тегү эшләре һәм дин сабагы укытыла.

(Мәхмутова А. Беренче татар хатын-кызлар гимназиясе // Совет мәктәбе. 1989. № 10. Б.53.).

Халкыбызның мәгариф тарихына килгәндә, бер факт игьтибарны бик тә җәлеп итә, ул да булса революциягә кадәрге мәктәп-мәдрәсәләрдә укыту процессының, басылып чыккан дәреслекләрнең халык педагогикасы идеяләре белән сугарылган булуы. Мәсәлән, әдәбият дәреслекләренең беренче битләре ук укуны яратырга, мәктәпне, хәлфә-мөгаллимнәрне хөрмәт итәргә, ата-ананы, гаилә әһелләрен олыларга өндәгән үтемле мәкаләләр белән башланып китә. Шакирҗан Ибраһимовның “Рәсемле фәнни кыйраәт” китабын алыйк (Казан, Милләт, 1912). Аның тышлык битен ачуга нәфис чәчәк рәсеме күзгә ташлана. Аннары гади тел белән язылган тирән эчтәлекле мәкалә.

## *МӘКТӘП*

*Инсанга мәктәп никадәр ягымлы, никадәр сөекле бер йорттыр. Адәм баласының иң рәхәт, иң матур көннәре мәктәптә уздырган көннәредер.*

*Адәм баласы, мәктәпкә надан хәлдә кереп, укырга, язарга, адәмнәр белән ничек мөгаләмә кылырга кирәк икәнен аңлап чыгадыр.*

*Мәктәп әллә ничә адәмнең әллә ничә баласын бер-беренә таныштырыр вә бер-беренә дус кылыр. Адәм баласының зиһене артырга, фикере* үсүгә *ярдәм итәр. Төрле нәрсәләрне белдерер. Дин, милләт нәрсә икәнен ачык аңлатыр. Ата-анага, туганга вә башка якын кардәшләренә ничек мөгаләмә кылырга кирәк икәнен күрсәтер.*

*Мәктәп адәм баласын дөнья вә ахирәттә хурлыкка төшерә торган наданлыктан коткарыр. Кайда булса да хөрмәт күрә торган олуг бер дәрәҗәгә ирештерер. Ять вакытта сабак укымаган балаларның зур үскәннән соң хәле начар булачакны күрсәтер...*

Әлеге мәкаләдән соң урнаштырылганында, ул “Бер саилнең мөнәҗәте” дип бирелә, өлкән яшьтәге кеше балаларга үзенең яшь вакытта укымавы, шуның аркасында хәерче көненә төшүе турында сөйли. Аннары “Тырышлык”, “Ата-ана” дигән мәкаләләр китә һ.б.

Нәҗип Думави “Безнең мәктәп” дигән дәреслеген (Оренбург, Хөсәеновлар, 1911) “Ата-ана” дигән мәкалә белән башлауны кирәк таба.

## *АТА-АНА*

*Балалар! Сез яхшы киемнәрегезне киеп, мәктәпкә җыелгансыз. Мәктәпкә килер алдында ата-анагыз һәм, булса, башка җәмәгатьләрегез илә бергә утырып ашаган-эчкәнсез. Тамагыгыз туктыр.*

*Сез уйлап карагыз! Әгәр дә үзегез ач вә ялангач хәлдә урамда калсагыз. ата-анагыз һәм ярдәм итәрлек якыннарыгыз да булмаса, ни хәл итәр вә кайда барыр идегез. Ыжгырып торган салкын җилдән вә эчне борып-борып авырттырып торган ачлыктан ничек котылыр вә ничек итеп берәр чарасын табар идегез. Яхшы уйлап карагыз, балалар, сезгә, ачлык вә ялангачлыктан котылыр өчен, сезнең кулыгызда котылырлык нәрсә юктыр. Җылар идегез, иңрәр идегез, ниһаять, капкадан-капкага йөреп, бер хәерче бала буларак калыр идегез.*

*Уйлап карагыз! Сезне ашаткан, эчерткән вә сезне җылы киемнәр эчендә тәрбия иткән һәм бәхетле булуыгызны теләп ошбу мәктәпкә китергән кешеләр кемнәр? Бик яхшы беләсез ки: ата-аналарыгыз, яки якын туганнарыгыз. Сез үзегезгә яхшылык иткән кешене сөясез, әгәр дә берәр кеше бүләк итеп, берәр нәрсә китерсә, сез аны яратасыз һәм үзенә яхшылык итәргә телисез. Сез, шулай булгач, туган көнегездән алып ошбу вә кыйтга кадәр сезне тәрбия иткән вә үстергән һәм тагы әллә никадәр тәрбия итәчәк булган ата вә аналарыгыз хакында ни уйлыйсыз? Сез, әлбәттә: “Сөябез*

*әниләрне, яратабыз!” диярсез. Ләкин бик яхшы аңлагыз! Ата-ананы сөю фәкать тел белән генә булмыйдыр, бәлки аларга игътибар һәм аларны зурлау илә буладыр.*

Һәр дәреслек диярлек шулай. Һәрберсе үз эченә әдәп, әхлак, тырышлык, кешелеклелек сыйфатлары, тәгълим-тәрбия эшләре турындагы тормышчан, яшүсмер көн дә исендә тотарга тиешле материалларны туплаган.

Гомумән, мәктәп-мадрәсәләрдә укыту-тәрбия эшләренә зур игътибар бирелгән. Вакытында дәреслекләре, хәтта альтернатив дәреслекләр, методик һәм педагогик хезмәтләр дә чыгып торган. (Исмагилова С. Г. Школьные учебники – духовная ценность народа // Советская тюркология. 1990.- № 3. - С. 81-92).

Татар халкынын, горурлыгы булып торган дөньякүләм билгеле галимнәребез Гыйлем Камай, Мәҗит Әлмәтхәммәтовлар, әдипләребез Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдинов, Ф. Кәрими, Г. Исхакый, Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Х. Туфан һ.б., һ.б. – шул татар мәдрәсәләрен тәмамлаган сөекле шәхесләребез инде. Уфадагы данлыклы “Галия” мәдрәсәсен 1906-1916 елларда гына да 1000 гә якын кеше тәмамлый. Шуларнын, 17 се язучы яки журналист була. Алар арасыннан Г. Ибраһимов, М. Гафури, Х. Туфан, Ш. Бабич, З. Ярмәки, И. Башмаков, Ф. Кәрими, Б. Имагулов кебек әдипләрне атап әйтергә мөмкин. Әлеге мәдрәсәдә укыган казах, үзбәк, төркмән шәкертләренең да байтагы язучы буларак танылa. (Иҗбулатов М. Гасырлар аша килгән мәгърифәт нуры // Совет мәктәбе. – 1985. - № 4. – Б. 2.). Иж-Бубидагы кызлар һәм егетләр аерым-аерым укый торган мәдрәсәләр дә бу яктан калышмыйлар. Аларны Җәмал Вәлиди, Шиһап Рамазанов, Садри Җәлал, Габдулла Мостакай, Заһира Байчурина, Нурлыһөда Тактамышева, Гаяз Максудов кебек галим һәм әдипләр тәмамлап чыга. (Максудова З. Иж-Буби мәдрәсәсе // Идел. - 1991. -  № 5. Б. 46.).

Мәктәп-мәдрәсәләрдән тыш хәрби уку йортларында, семинария, гимназия, университетларда укыган татар яшьләренең саны аз түгел. Мәсәлән, Казан укытучылар семинариясен татарлардан 107 кеше тәмамлый. (Чекменова Т. Казан укытучылар семинариясе // Совет мәктәбе. - 1984. - № 9. – Б. 60. ). Татар мәдрәсәләрен тәмамлаучылар Шәрык мәдәниятенә бик табигый кушылып, берегеп китә торган булганнар. Күп кенә татар шәкертләре Сүриядә, Мисырда, Төркиядә белем алуларын дәвам иткән. Мәсәлән, Шәриф Камал Истанбул һәм Каһирә мәдрәсәләрендә укыган. Дәрдмәнд, Фатих Кәрими Истанбул университетын тәмамлаганнар. Россия һәм Шәрыктагы уку йортларыннан тыш, Париж, Женева, Льеж, Лейпциг, Фрайбург, Нью-Йорк, Сан-Франциско, Токио, Вальпараисо универеитетлары һәм колледжларында белем алган татар яшьләренең саны берничә дистәгә җитә. (Рәми И. Мәдрәсәләрдән университетларга // Казан утлары. – 1966. - № 3. Б.136.). Мәсәлән, күренекле татар зыялысы Садри Максуди мәктәп белән мәдрәсәдән тыш Мәскәү һәм Париждагы Сорбонна университетларын тәмамлый. Революциядан соң Франциягә, аннары Төркиягә китеп, Сорбонна һәм Әнкара университеты профсессоры булган, лингвистика һәм хокук буенча берничә капиталь хезмәт бастырган. (Мостафин Р. “Артта калган надан халык” һәм башка идеологик штамплар турында. “Татарстан”, 1991, № 7, 3 б.). Буби мәдрәсәсеннән соң зыялыбыз Гаяз Максудов Бельгиядә Льеж универеитетының физика-математика факультетын төгәлләп, математика фәннәре магистры дәрәҗәсен алган. Революциядән соң ул Казан университетында укыта, Татарстан мәгариф министрлыгы каршындагы Гыйльми Үзәк эшләре белән җитәкчелек итә, математика буенча дәреслекләр төзи. (Максудова З. Иж-Буби мәдрәсәсе. “Идел”, 1991, № 5, 46 б.). Хатын-кызлардан Хөсәен Фәезхановның оныгы Суфия Сыртланова авыл мәктәбен һәм Уфа мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң Женева университетының медицина факультетында белем ала. (Мостафин Р. “Артта калган...”

– Б. 9-10). Дөрес, андый белем югарылыгына күтәрелү югары катлау балаларына гына мөмкин булган. Әмма күп санлы мәктәп-мәдрәсаләрдә аң-белем бирүче мөгаллимнәр арасында Бохарада, Сәмәркандта, Истанбулда, Мисырда, Мәккәдә, Көнбатыш илләрендә да белем алган, татар, рус, гарәп, фарсы, төрек телләрен яхшы белгән укымышлы кешеләр шактый була. Алар дини әдәбият, ислам кануннарыннан да хәбәрдар, Көнчыгыш һәм Көнбатышның прогрессив язучылар иҗатын да билгеле бер дәрәҗәдә үзләштергән булалар. Рус, гарәп, фарсы, төрек, үзбәк, таҗик һ.б. кайбер халыклардагы сүз осталарының әсәрләрен, медицина, табигать дөньясына, тарихка кагылышлы фәнни мәгълүматларны татар тормышына кертүчеләр дә әнә шулар булды. Шуның өстенә аларның күбесе халык арасында үзенең интеллекты, галимлеге, рухи байлыгы, культурасы, кешелеклелеге белән аерылып торган.

Мәктәп-мәдрәсәләрне тәмамлаган шәкертләр исә зур-зур күләмле әдәби әсәрләрне, Коръән кадәр Коръәнне яттан белгәннәр, аларны моңлы, йөрәкләргә үтеп керерлек итеп укый, укыганны күзләрдән яшьләр китерерлек итеп шәрехли, эчтәлекне тормыш белән бәйли, тәрбияви мөмкинлекләрен күңелләрне тетрәндерерлек итеп аңлата алганнар. Аларны бит шундый булырга өйрәткәннәр, укытканнар. Кайда? Мәктәп-мәдрәсәләрдә. Кемнәр? Мөгаллимнәр, мөдәррисләр, хәлфәләр, муллалар, хәзрәтләр. Ничек шулай укыта алганнар? Югары хәзерлекле булганнар...

Ә нәтиҗәләр... Нәтиҗәләр йөзгә кызыллык китерә торган түгел. 35 елдан артык миссионерлык эшчәнлеге белән дан алган Н.И. Ильминскийның мондый сүзләре бар: “Татарларның иң кимендә һәр җиде кешенең берсе грамоталы. Хатын-кыз арасында бу пропорция хәтта югарырак та. Миңа фарсыча, гарәпчә яхшы гына сөйләшкән хатын-кызларны күрергә туры килде”. (Вестник научного общества татароведения. – 1826. - № 5. – С. 124). Казан университетында күп еллар эшләгән һәм махсус рәвештә татар тормыш-көнкүрешен өйрәнгән профессор К.Ф. Фукс фикере да

кызыклы: “Читтән килгән кешегә, һичшиксез, сәер тоелыр, ләкин хак: гомумән алганда Казан татарларыннан да укымышлырак халыкны табуы кыен, хәтта европалылар арасыннан да. Укый-яза белмәгән татарга авылдашлары кимсетеп карый, ул кеше буларак та хөрмәт казанмый. Шуның өчен да һәр ата баласын укырга бирергә тырыша, аның һич югы укырга-язарга өйрәнүен, дин сабагы белүен тели“. (Фуке К. Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях. Казань, Тип. Казанского имп. ун-та, 1844. - С. 113-114). Соңрак чыккан чыганаклардаи С.В. Чичеринның “Положение просвещения у приволжских инородцев" /СПб, 1906/ дигән китабында “Мөселман-татарларның бай әдәбияты бар; алар мөстәкыйль мәктәпләрен шул дәрәҗәдә үстергәннәр ки, укучылар саны ягыннан урысларны узып та китәләр” дигән юллар бар.

Башкача булырга да мөмкин түгел. Халыкка колак салыйк.

БЕЛЕМЛЕ БУЛ:

*Белемсезгә дөнья ләхет.*
*Белемдә көн.*
*Белем – йөрәккә куәт.*
*Беләктән белек көчле.*
*Белем – нур, белмәү – хур.*
*Дөньяда иң зур байлык – белем.*

БЕЛЕМ ЭСТӘ:

*Белемлелекнең чиге юк.*
*Бәхетне юлдан эзләмә, белемнән эзлә.*
*Җиде йортның телен бел, җиде төрле белем бел.*
*Икми иген шытмас, өйрәнми белем йокмас.*
*Акыл – тузмас кием, гыйлем – корымас кое.*
*Дөнья тулы гыйлем, башыңда калганы. – белем.*

*БЕЛЕМЛЕ БУЛАСЫҢ КИЛСӘ, УКЫ:*

*Укусыз белем юк, белемсез көнең юк.*
*Безне адәм иткән – уку.*
*Уку – күңел нуры, укымый калган кеше – адәм хуры.*
*Уку каты булса да, җимеше шатлы.*
*Күп яшәгән ни белер, күп укыган шул белер.*
*Укыган уңар, укымаган туңар.*

*КИТАП СӨЙ:*

*Китап – белем чишмәсе.*
*Китап – галим, телсез мөгаллим.*
*Китапның белмәгәне юк.*
*Китапсыз өй – ишәк абзары.*

*НАДАН КАЛУДАН КУРЫК:*

*Надан кеше – сукыр тавык.*
*Надан кеше – яман кеше.*
*Наданга фикер әйтеп бактың ни – эт муенына энҗе-мәрҗән тактың ни.*
*Галим кеше үлсә дә терек, надан кеше йөрсә дә үлек.*
*Йөз надан бер галимнең тырнагына да тормас.*
*Наян кеше – төлке кеше, надан кеше – көлке кеше.*

Чорының күренекле кешеләре, зыялылары гыйлем эстәүне, белемнәр үзләштерергә кирәклекне тәкрарлап торганнар, замандашларына киңәшләрен биргәннәр, юлын күрсәткәннәр. Күренекле мәгърифәтчебез Ризаэтдин бине Фахретдиннең, мәсәлән,

“Җәвамигуль кәлим шәрхе“ дигән хезмәтендәге (Оренбург, 1916) түбәндәге сүзләре генә дә ни тора: “Кулыңнан килсә, форсат тисә – галим бул, бу эш насиб булмаса, шәкерд вә гыйлем эстәүче бул, бу да мөяссар булмаса, гыйлем мәҗлесләрендә гыйлем тыңла, бу да булмаса, гыйлемне дуст күр... Гыйлемне дуст күрү исә аның әһлене хөрмәт итү, халык арасында аны тарату, белдерү вә үгрәтү , укучыларга һәм дә мәктәп вә мәдрәсәләргә, укытучыларга матди вә мәгънәви ярдәмнәр бирүдән, мөҗәррәт занн яки искедән мирас булып калган көнчелекләр сәбәпле гыйлем әһелләренә дошманлык кылулар вә гайбәтләрне сөйләүләрдән саклану вә гомумән гыйлем юлында булган кешеләр берлә яхшы мөгамәләдә булудан гыйбарәттер" (Риза Фәхретдин. Җәвамигуль кәлим шәрхе // Идел. – 1990. - № 2. Б.44.).

Халкыбыз өчен гасырлар буена хас булган белем-мәгърифәткә омтылыш, кызганычка каршы, соңгы елларда нык кына йомшады. Дистәләгән еллар буена илебездә команда-административ система хакимлек итү сәбәпле, совет экономикасы үзенең табигый юлы белән үсеп китә алмады, һәм кешегә хезмәт хакы түләгәндә аның һөнәри осталыгы, квалификация югарылыгы, белем дәрәҗәсе исәпкә алынмады. Хәзер элеккеге зарарлы идарә итү системасыннан базар мөнәсәбәтләренә күчкәндә инде җитештерү процессында һәм иҗтимагый мөнәсәбәтләрдә тотрыклылык җимерелде, инфляция көчәйде. Белемнернең, интеллектның әһәмияте һәм кыйммәте күпмедер төште, чөнки кайберәүләр өчен алыш-биреш китереп, җиңел юл белән мал җыю мөмкинлеге туды. Ләкин бу авыру иктисад тудырган вакытлыча күренеш. Яңача хуҗалык итү шартларында һәрнәрсә дә үзенең табигый хәленә кайтыр. Югары класслы хезмәт тә, димәк, белемле, хәзерлекле белгечләргә мохтаҗ булыр. Бу – иктисадның тайпылышсыз кануны. Халкыбызның белемгә булган ышанычы югалмас дип ышанасы килә. Бөтентатар “Мәгариф” ассоциациясенең Беренче корылтаенда перспективалы программа буларак кабул ителгән “Татар мәгарифен үстерү концепциясе” “...

гыйлем эстәүгә, белем алуга омтылышны хуплау, гыйлемне изгеләштерү“не алгы планга куеп, өметләрне ныгытып тора. (Татар мәгарифен үстерү концепциясе // Офык. - 1991. - № 8. – Б. 18 .).

## 1.5. ДУСЛЫК БУЛМАГАН ГАИЛӘ — ТАМЫРСЫЗ АГАЧ

Халкыбызның гасырлар төпкеленнән килә торган иң күркәм сыйфатларыннан берсе – ата-анага изге караш, өлкәннәргә олы ихтирам, гаилә иминлеген тәэмин итәргә тырышу, кардәш-ыру белән тыгыз аралашып яшәү, үзара ярдәмләшү. Бу сыйфатларның мөһимлеге халык тарафыннан ассызыкланып, буыннан буынга тапшырылган, шул процесста тирән эчтәлекле мораль-этик нормалар, таләпләр формалашкан: “ата-ананы, өлкәннәрне хөрмәтләү – фарыз“ (фарыз – гарәп теленнән алынган. “бурыч”, “үтәлми калмаска тиешле эш” дигәнне аңлата), “олыларны олылау – фарыз”, “туган-тумачаңны, нәсел-нәсәбеңне белү – фарыз”, “җиде бабаңны белү – фарыз”, “туганнар белән аралашмау – хурлык”. Туганлык бәйләнешләренең йомшара, сабыен балалар йортына тапшырган аналарның, әти-әниләрен картлар йортына илтеп тапшырган ул-кызлар саны арта барган бу көннәрдә халыкның бу юнәлештәге тәҗрибәсен өйрәнү иң актуаль проблемаларның берсенә әверелде. Дөрес, гаиләнең әхлакый нигезе какшауга китерүче җитди социаль сәбәпләр дә булды. Хәбәрдарлык булмау, сүзнең эштән аерылуы, икейөзлелек, социаль гаделсезлек кебек күренешләр яшьләрнең бер өлешенә тискәре йогынты ясады. Хәзерге вакытта хатын-кызларның 95 проценттан артыграгы производствода эшли яки укый. Ярты миллионнан артык хатын-кыз предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар, бер миллионлабы цехлар, участоклар, бүлекләр һ.б. белән җитәкчелек итә. Инженерларның 58 проценты, авыл хуҗалыгы белгечләренең – 45, врачларның – 67, укытучыларның – 73, экономистларның – 87, китапханәчеләрнең 91

проценты хатын-кызлар. Ана булу эш урынында күтәрелүгә киртә булып тора диючеләр дә барын һәм ана вазифаларын уңышлы башкару өчен хатын-кызларга хезмәттә һәм көнкүрештә җитәрлек шартлар булмавын, күп кенә яшьләрнең гаилә тормышына хәзерлексез килүен һәм шуның нәтиҗәсендә күп санлы ятим балаларның ялгыз ана кулында үсүен дә исәпкә алсак, шактый ук мөшкел хәлләр күзаллана. Шуның янына байлык артыннан куып, яки җенси бозыклык белән яшәп, эчкечелеккә бирелеп, балалар тормышын фаҗигагә әверелдергән гаиләләрне, җиде дистә ел дәвамында меңләгән, миллионлаган милләттәшләребезнең диненнән, теленнән, хәтта халкыннан баш тартуын да китереп кушсак...

Ә нәтиҗәләр әнә күз алдында: урамнарда группировкалар, рэкетчылык, җинаятьчелек, әхлаксызлык, рухи бушлык, битарафлык. “Кыйбла”, “иман” төшенчәләреннән һич хәбәре булмаган рәхимсез буын изге кабер ташларын ватып йөри, туганнар каберлекләрен мәсхәрәли, талый, зираттагы язмаларны укымый, андагы сурәтләргә күз салмый. Баласы каберләр туздырып йөргән, бабалары турындагы хәтере үтерелгән гаилә дә, андый гаиләләрдән торган җәмгыять тә бәхетле була алмый.

Югарыда әйтеп киткәннәр халкыбызның бай кыйммәтләр тәгълим-тәрбия тәҗрибәсе барлыгын, яшьләргә үрнәк итеп күрсәтерлек кешеләребез дә, гаиләләр дә күп булуын инкяр итә алмый. Ата-анасының шәхси үрнәгендә өйдә яхшы хезмәт күнекмәләре алган, тырыш, эш сөючән, кешеләргә карата шәфкатьле, миһербанлы һәм ярдәмчел үсмерләребез һәм гаилә традицияларен кадерле ядкарь итеп саклаучы, халыкның гореф-гадәтләренә хөрмәт белән караучы, аларны дәвам итәргә омтылучы яшьләребез да аз түгел безнең. Балаларның “үскәч, әтием кебек төзүче (нефтьче, тракторчы, мәдәният эшлеклесе, машина йөртүче) булам”, “әнием кебек укытучы (тукучы, тегүче, мәдәният хезмәткәре һ.б.) булам”, “әтием юлыннан китеп, агроном булдым", “әнием шикелле нәфис

профессия сайладым” кебек сүзләрнең бүген дә яңгыравы, элек-электән килгән әби-баба, әти-әни һөнәрен дәвам иттерү традицияләренең дәвамчанлыгы турында сөйли. Тик бу традицияне өйрәнү, системага салу һәм пропагандалау кирәк.

Гаилә тәрбиясендә ана иң изге, иң олы шәхесләрдән саналган. Халык педагогикасында ана булу иң югары кыйммәт, кешелек дөньясының дәвам ителүендә табигый ихтыяҗ буларак карала, ана культы күздә тотыла. “Анаң өченүуч төбендә тәбә кыздырсаң да бурычыңны кайтара алмассың”, “Ана авызында ләгьнәт тә фатихалы”, “Көн-төн эшләсәң дә ана хезмәтенә җитмәс”, “Әнкәм йорты – алтын бишек”, “Өйнең яме ана белән”, “Ана – шәфкать диңгезе”. “Әни суккан авыртмый” ... Әнә ничек шәп әйтә афоризмнар! Ана – кеше тормышының ахыргы көненә кадәр ышанычлы терәге. “Суда ага башлагач, бабай да: “Әнием!” дип кычкырган”, – дип, юкка гына ярым җитди, ярым шаярып әйтми халык. Чөнки аналар – кешелекнең төп тоткасы. Ана мәхәббәте – бердәнбер игелекле, тугрылыклы, эчкерсез һәм бернинди таләпсез, гаҗәеп акыллы, иксез-чиксез һәм фидакарь мәхәббәт.

Халыкның ананы идеаллаштыруы, изгеләштерүе безнең әдипләребез, шагыйрьләребез һәм композиторларыбыз иҗат иткән әсәрләрдә гәүдәләнеш тапкан ана образлары белән бик тә аваздаш:

Ә. Еники – “Матурлык", “Кем җырлады?”

Г. Мөхәммәдова – “Сикәлтәле туры юл” (Галимҗан Ибраһимовның күңелендә торган әнисе образы);

Һ. Такташ – “Мәхәббәт тәүбәсе”;

М. Җәлил – “Ана бәйрәме”;

С. Хәким – “Керинделләр эзлим”;

“Әниемнең җылы кочагы” – М. Мазунов сүзләре, Ә. Бакиров музыкасы;

“Әнкәй” – Р. Миңнуллин сүзләре, С. Садыйкова музыкасы;

“Әни кирәк" – Р. Миңнуллин сүзләре, М. Шәмсетдинова музыкасы һ.б.

Үзенең авыз иҗатында халык анага мәхәббәт, анага карата мәрхәмәтле ул һәм кызларын идеаллаштырып чагылдырган: "Үз анасын зурлаган кеше анасын хурламас”. Анага карата рәхимсезлекне иң зур гаеп дип бәяләгән: “Анасына өргән эт бүре базына төшәр”, “Ана сөте белән кермәгән тана сөте белән кермәс”. Кыз баланың холык-гадәтләре әнисеннән бәйле булуга ишарә ителгән: “Әнисенә карап кызын коч”, “Ул ояты – атага, кыз ояты – анага”, “Кыз анага тарта”. Ана каргышына иң үтемле, һичшиксез гамәлгә ашачак каргыш буларак урын бирелгән. Моңа мисал – “Сак-Сок бәете”. “Анаң кабере янында җыларга туры килмәсен!” Халык педагогикасында моннан да кырыс тәрбия алымын очрату кыен.

Гаиләдә ананы изгеләштерү ананың авырлыклар белән, нык җәфаланып дөньяга кеше кадәр кеше тудыруы, иксез-чиксез мәшәкатьләр белән аны аякка бастыруы, бөтен язмышы, кеше буларак формалашуы, олы юлда үз кыйбласын табарлык булып үсүе өчен җаваплылык хисе йөртүе, баласы-йөрәк пәрәсе өчен бертоташтан җан атуы, аның бәхете өчен бөтен авырлыкларга түзәргә әзер торуы, чигенә чыкмас йорт мәшәкатьләрен ерып баруы белән аңлатыла.

Халыкның тормыш-көнкүреш тәҗрибәсендә гаиләдә бала тәрбияләүдә ата роленә дә югары бәя бирелә. Әти кешенең гаиләдә һәм башка урыннарда сабырлыгы, һәр сүзне уйлап, төпле, саллы итеп сөйләшүе, кылган гамәлләренә җавапчыл булуы, кешеләргә, бигрәк тә үзеннән өлкәннәргә итагатьле булуы, иҗтимагый активлыгы, эчкечелеккә тискәре мөнәсәбәте татар гаиләсендә гадәти күренеш булган. Хатын-кыз үзенең нәфислеге, назлылыгы, рухи яктан тиз җәрәхәтләнүчәнлеге, тирәннән кайгырта белүе, зирәклеге һәм матурлыгы белән аерылып торса, ир-ат үзеннән күпне таләп итүе, авырлыкларны үз өстенә алуы белән аерылып торган.

Ата – *беләк, ана – йөрәк.*
*Атаңны башыңда тот, анаңны учыңда тот!*

*Ата юлы балага такыр.*

Халык авыз иҗаты әсәрләреннән күренгәнчә, атаның педагогик йогынтысы һәм вазифалары аның абруе планындарак каралган: ул – гаиләне яклаучы, гаилә намусын саклаучы, туйдыручы, җылытучы, мал табучы, яшәү шартлары булдыручы. Шуның өчен гаиләдә ананы ныграк изгеләштерү традициясе ныгыгандыр. Чөнки ата хезмәте күбрәк җилкә, беләк, гайрәт хезмәте. Мондый хезмәт күз алдыннан читтәрәк, вакыты белән гаиләдән шактый еракта башкарыла. Шул ук вакытта ата – салкын акыл иясе. Ул юкта рәтле тормыш та юк. Халык бу хәлне бик яхшы аңлаган һәм бала-чагага үз белгәнен һәм тәҗрибәсен тапшырып торган:

*Атасы барның бәхете бар.*
*Ата аркасы – кала аркасы.*
*Ата сүзен тыңламаганнарны атауга ыргытканнар, ди.*
*Әти тунын күтәреп кисәң, тап-таман.*
*Ирләр киңәше ил корган.*

Аннары атадагы яхшы сыйфатлар бала, бигрәк тә ир бала өчен алыштыргысыз үрнәк икәнлеген да һәркем исендә тоткан:

*Алты көн ач булсаң да ата гадәтен онытма.*
*Атаң исән чакта һөнәрен өйрән, ул югында куәтен истә тот.*
*Яман атадан яман ул.*
*Ул ояты – атага.*
*Атасы кем – угылы шул.*

Атага хөрмәт күрсәтелергә тиешлек та һәрдаим кисәтелеп торылган:

*Ата өчен улы җан бирсә, улга дан.*

*Эт атасын танымас.*

*Мөгезен кем хур иткәнне болан онытмас, атасын кем хур иткәнне олан онытмас.*

Күп очракта, әлбәттә, хөрмәт ителергә тиешлек мәгънәсе ата-ананың икесенә да кагыла:

*Ата-ана теләге утка-суга батырмас.*
*Ата-ананы тыңлаган адәм булган, тыңламаган – әрәм булган.*
*Ата-анасына игелек күрсәтмәгән, олыгайгач, үзе дә күрмәс.*
*Ачтан үлсәң дә ата-анаңны ташлама.*
*Ата-анасын хурлаган үзен хурлаган булыр.*
*Башсыз өйдә ата торып, ул сөйләр, ана торып, кыз сөйләр.*
*Баладан бәхетең булса, карт көнеңдә яшь итәр.*
*Баладан бәхетең булмаса, иртә яшьтән карт итәр.*
*Мисез бала ата-анасын тыңламас.*

Күп милләт халыклары, бигрәк тә төрки халык, улларын өйләндергәндә яки кызларын кияүгә биргәндә, булачак килен яки кияүнең нәселе абруена, ата-аналарының ниндирәк кеше булуына, аларның мораль-әхлак ягына нык игътибар иткән. “Алма агачыннан ерак төшми”, “Оясында ни булса, очканында шул булыр”, “Анасына карап кызын коч”, дип фикер йөртә халкыбыз. Бу аның бала тәрбияләүдә гаиләгә гаять мөһим бурыч йөкләнүен һәм аның нинди әһәмияткә ия булуын тирәнтен аңлавыннан килә. Чөнки балаларның кешеләрне хөрмәт итүе аларның әти-әниләренә мәхәббәттән башлана. Бу хис тора-бара туган-үскән җиргә, туган якка, туган телгә, үз халкыңның тарихына, барлык хезмәт ияләренә ихтирамга әверелә. Ата-ананың балаларына, үз ата-аналарына (әби-бабайга), кардәш-ыру, туган-тумачаларына, күрше-күләнгә мәхәббәте, хөрмәт һәм ихтирамы нигезенә гомумкешелек идеаллары салынганын безнең халык акылы белән генә түгел, җаны, йөрәге белән тойган,

канына сеңдергән. Шуның өчен дә үз баласын тәрбия итә белмәгән ата-анага карата ризасызлык белдергән:

*Ата-анасы юньсезнең баласы юньсез.*
*Яман атадан – яман ул, яман анадан – яман кыз.*
*Яман бала тудырганчы елан тудырганың артык.*

Яхшы гаиләдә тәрбиясез балалар үсүенә гаҗәпләнгән:

*Кемгә охшап шундый булган соң бу?!*
*Яхшыдан яман туган нәрсә!*

Әбиләр, бабайлар, өлкән яшьтәге кешеләр татар гаиләләрендә аерым бер зур урын биләгәннәр. Алар үз балалары өчен дә, оныклары өчен дә үрнәк саналган. Әби-бабайларның тәҗрибәсе, киңәшләре гаять күп төрле һәм катлаулы тормыш-көнкүреш мәсьәләләрен чишәргә, уңышлы хәл итәргә мөмкинлек биргән. Ил картлары гаиләдә генә түгел, җәмәгатьчелек өчен дә акыл-киңәш иясе булып саналганнар. Моңа мисал йөзеннән дистәләгән әкиятләр китерергә мөмкин.

“Карчык белән аю” әкиятендә, мәсәлән, карчыкның акыллылыгы, зирәклеге, кирәк чакта хәйләкәр дә була белүе һәм шул сыйфатлары нәтиҗәсендә һәлакәттән котылып калуы тасвирлана.

“Аю, бабай, төлке” әкиятендә бабайның кыен хәлләрдә дә сабырлыгы, акылын югалтмавы, хәйләкәрлеге аркасында аюны да, төлкене дә көлкегә калдыруы турында сүз бара.

“Васыять” әкиятендә карт күчерелмә мәгънәдә өч васыять әйтеп калдыра. Әмма картның уллары васыятьләрне туры мәгънәдә аңлыйлар һәм ялгыш эшләр башкаралар. Кыен хәлдән аларны икенче бер карт чыгара.

“Карт белән ялкау егет” әкиятендә карт хәйлә белән егетнең ялкаулыгын бетерә.

“Зирәк карт” әкиятендә 70 яшьлек карт үзенең улына акыллы киңәшләр биреп, аны һәм үзен үлемнән коткарып кала.

Күренгәнчә, болар әкиятләр генә түгел, ә чын мәгънәсендәге һәм гаять көчле тәрбияви йогынтылы педагогик хезмәтләр дә. Тик бу педагог-авторларның исем-фамилияләре генә билгеле түгел. Әмма шунысы куанычлы: нигезенә халыкның бу өлкәдәге тәгълим-тәрбия тәҗрибәсе салынган әдәби әсәрләр дә бездә аз түгел. Нәби Дәүлинең “Хәерле көн, дуслар”, М. Мәһдиевнең “Торналар төшкән җирдә”, “Бәхилләшү”, А. Гыйләҗевның “Өч аршын җир” әсәрләре, М. Фәйзуллинаның “Бабам шинеле”, Ә. Бикчентәеваның “Дәү әнием", М. Мазуновның “Безнең бабай" шигырьләре һ.б.

Кайбер өзекләр китерү дә артык булмас.

*"... Мин кайчакта әбиемнең кулларына карап торам. Мондый куллар тагын кемдә бар? Ул куллар кечкенә генә, йомры гына. Ләкин шул кечкенә генә куллар белән минем әбием үз гомерендә нәрсәләр генә эшләмәгән. Шушы куллар белән ул иң-иң элек, әле җиде яше тулар-тулмас чагында ук, чыбык тотып каз бәбкәләре көткән. Аннан соң шул кулларына себерке алып, иртән, көндез һәм кичен идән себергән. Аннан соң көннәр буе башын тагаракка иеп, керләр юа башлаган, һәм яңа көн туган саен шул кечкенә генә кулларга яңадан-яңа эшләр табыла барган..." (Дәүли Н. Хәерле көн, дуслар. Казан, Тат. кит. Нәш., 1972, 35 б.)*

*“...Бабай урыныннан торып тәрәзә янына килде. Әйтерсең, ул шул тәрәзәдән үзенең узган гомерен күрергә тели иде. Әйтерсең, ул әле бүген генә үзенең картайганын белгән дә, шуңа исе китеп тора кебек. Ул, пенсия язуын кесәсеннән чыгарып, әйләндереп-әйләндереп карады. Белмим, ул шул вакытта нәрсә турында уйлагандыр, ә миңа исә ул үзенең киң калаклы җилкәсе белән, авыр гер тагып куйган кебек зур куллары белән, аз генә кәкрерәк аяклары белән ниндидер зур тауларны үтеп, киң диңгезләр аша узып кайткан юлчыга охшый иде...” (Шунда ук, 41 б.).*

Сабый баланы тәрбия итүдә вакыты белән әби ананы да алыштыра алган. Ә бабайның тәрбияви йогынтысы еш кына атадан активрак та булган. “Дәү әни”, “дәү әти”, “әбекәй", “әбием”, “бабакай”, “бабаем” дип дәшүләр бездә бер дә юктан гадәткә кермәгәннәр. Алар – ата-ана кебек үк кадерле, газиз кешеләр.

Кыска гына итеп әйткәндә, “бала тәрбиясенең иң мөкәммәле – әби-баба тәрбиясе. Элек ул шулай булган да”. (Мәһдиев М. Мәдәни мирасыбыздан бер кисәк // Мәгариф. - 1991. - № 4. Б.53.).

Гомумән, безнең халык өчен, башка төрки, Көнчыгыш илләрендәге халыклардагы кебек үк, өлкән буынны олылау, үткән буыннар хатирәсенә кадерләп карау, аларга хөрмәт күрсәтү, ихтирам итү, сүзләрен тыңларга тиешлек әхлак кагыйдәләре булып саналган:

*Олыларны олыла, үзең дә олаерсың.*
*Олылар сүзен тотмаган орылган да сугылган.*
*Картлар сүзен кар басмас.*
*Олы булсаң, кече бул.*
*Кечегә шәфкать итеп юл бир, олыга хөрмәт итеп юл бир.*
*Олыны олы итмәгән беркайчан да олы була алмас.*
*Картлар кара акылга бай, яшьләр яңа акылга бай.*
*Олы әйткәнне итмәгән – морадына җитмәгән.*
*Дәвасыз дәрт булмас, һәвәссез карт булмас.*
*Бала багучы карчык – өйдә алтын канат.*
*Карт бар өйдә кот бар, карчык бар өйдә орчык бар.*

Гаилә шәҗәрәсен алып бару, нәселнең абруе турында нык кайгырту, гаилә ядкарьләрен кадерләп саклау (әбием төсе, бабам бүләге, әбиемнең әнисеннән калган истәлек һ.б.), зират-каберләргә карата игелекле мөнәсәбәт кебек күркәм сыйфатлар халкыбызнын ана шул өлкән-үлгән буыннарны изге итеп санавыннан килә.

Адәм баласына үзенең җиде бабасын белү фарыз, дигәннәр

борынгылар. Фәкать шул очракта гына кеше туган иленең, туган төбәгенең, туган йортының үткәнен, үз халкының тарихын, аның килеп чыгышын белергә мөмкин. Шуның өчен бүген дә яшьләребезгә үз шәҗәрәләренең тарихын, туган авылының, туган төбәгенең үткәнен белү, өйрәнү – фарыз, үз табигатен, тарихи урыннарын, зиратларын барлап тору, хөрмәт белән саклау – фарыз.

Кардәш-ыру белән якыннан яратып аралашу, күрше-күлән белән узара ярдәмләшеп көн күрү дә халкыбызнын игътибарга лаек. Күрше хакы – Алла хакы. Күрше барда куыш бар.

Иң мөһиме, әлбәттә, гаиләнең үз әгъзалары арасында үзара мөнәсәбәт: дус булмагаи гаилә – тамырсыз агач. Фәрештәсез йортка шайтан тула.

*Уңар йортның баласы*
*Бер-берсенә "батыр" ди,*
*Уңмас йортның баласы*
*Бер-берсенә "кутыр" ди.*

Тәрбияви йогынтының поэтик бер формасы булып хәер-фатиха бирү һәм алу, ата-ана догасы, өлкәннәр әйткән теләкләр торган. Нинди дә булса мөһим, хәлиткеч эш башкарыр, юлга чыгар, өйләнү яки кияүгә чыгу алдыннан әйтелә торган тирән дулкынландыргыч сүзләр тупланган безнең тәрбияви хәзинәбезгә:

- *Мин Сәрияне сөям, әткәй, әнкәй, өйләнергә ризалык бирегезче!*

- *Хәер-фатиха бирсәгез, башка чыгар идек.*

- *Ерак сәфәргә чыгам, бабакаем, әбекәем, изге догада торсагыз иде!*

- *Хәерле сәгатьтә, кызым, укуыңның рәхәтен күр, кешеләргә игелекле бул!*

- *Хәер-фатиха, балалар, бәхетле булыгыз!*

- *Хәерле сәгатьтә булсын! Бәетле яшәгез, ата-анагызны*

*кадерләгез, акыллы, игелекле балалар үстереп, тигез картаегыз!*

*- Йортыгыз – яңа нигезегез котлы булсын! Мул тормышта бәхетле яшәгез. Ата-ананы онытмагыз.*

*- Фәрештәнең “амин” дигән чагына туры килсен!*

Ничаклы әкият-дастаннарның сюжеты ата-бабалар әйтеп калдырган васыятьләргә нигезләнә. Сибгат Хаким бу хакта болай ди: “Васыять әйтү традиция буенча килә, тудырган нигезгә, йортка турылыклы булу... Ә нигез ул – Ил, Ватан, Туган җир”.

## 1.6. КЕШЕ КЕШЕЛЕКЛЕ БУЛСА ГЫНА КЕШЕ

Борынгы грек философы һәм язучысы Плутархның бик гыйбрәтле сүзләре бар: “Үз-үзен аямыйча, зур һәм күркәм эшләр башкарган кеше генә яхшы кеше була ала”. Андый эшләрне исә, билгеле булганча, саф күңелле, кечелекле, инсафлы, шәфкатьле, башкаларга ярдәм итәргә һәм шатлык китерергә һәрвакыт әзер торган шәхесләр генә булдыра ала. Ә андый шәхесләр ничек формалаша? Кайдан килә? Чын кеше булып үссеннәр өчен, улларыбыз һәм кызларыбыз күңелендә нәрсә калдырырга? Ата-ана мәхәббәтенең бала күнелендә сүрелмәс рәхмәт хисләре кабызуына ничек ирешергә? Улында һәм кызында әти-әнисе тәрбияләгән яхшылык бөртекләрен кешеләр һәм халык өчен олы хисләргә әверелдерү өчен нәрсәләр эшләргә кирәк? Баланы кешеләрне анлый һәм күрә белергә ничек өйрәтергә?

Катлаулы, четерекле сораулар болар, һәм аларга төпле җавапны халыкның гасырлар буена тупланган тәгълим-тәрбия тәҗрибәсеннән эзләү дөрес булыр. Элегрәк кешеләрдә кием-салымга табыну хәзерге кебек көчле булмаган. Алар кешелекле, игелекле, итагатьле, тәртипле булуга нык игътибар иткәннәр. Ата-ананың мәгънәле мәхәббәте балада әйләнә-тирә мохитка, кешегә кирәкле һәрнәрсәгә

карата сизгерлек хисе уяткан. Ата-анага, әби-бабага һәм башка гаилә әһелләренә мәхәббәт һәм хөрмәт балада намуслылык, кешелеклелек хисләре тәрбияләгән.

Гади халыкның кешелеклелек сыйфатлары гасырлар дәвамында формалашкан, һәм яңа буынга узган буыннардан васыять, тәҗрибә хәзинәсе, тәҗрибә аша тупланган акыл, вәгазь, югары әхлак һәм гражданлык кодексы буларак тапшырылган.

Туган теленә, туган төбәгенә, үз халкына, теленә мәхәббәт – халыктагы кешелеклелек сыйфатларының иң бөеге. Тормыш-көнкүреш, дөнья хәлләре безнең халыкны “Алтын-көмеш яуган җирдән туган-үскән ил артык”, “Аягы яман түрне болгар, авызы яман илне болгар”, “Дусыннан аерылган җиде көн җылар, иленнән аерылган җиде ел җылар” дигән фикергә китергән. “Береккән ил бозылмас”, “Болгар йорты – Идел йорт, Идел эче – имин йорт” дип оран салырлык дәһшәтле вакыйгаларны башыннан кичергән һәм үзеннән соң килгән буыннарны хәтәр һәлакатләрдән саклауны үзенең бурычы итеп куйган: “Ил аткан таш ерак китә”, “Ил белән этәргәч, тау күчкән”, “Иле иркеннең күне иркен”, “Ил ачуы – яман ачу”, “Ил көче – Идел көче”, “Ташлама илеңне, кан басар күзеңне”, “Үз илең гөлстан, кеше иле – гүрстан”.

Иле, халкы өчен көрәшкә күтәрелгән героик ул һәм кызларын гәүдәләндереп, халык күп санлы әкият, легенда һәм дастаннар иҗат иткән. “Хан кызы Алтынчәч” легендасында чит җир басып алучысы ханнан Алтынчәч исемле кызын таләп итә, юкса бөтен ханлыгын тар-мар итү белән яный. Ләкин Алтынчәч тормышын илбасар белән бәйләүне үзенә хурлык саный. Әтисе һәлак булгач, дошманга каршы сугышка үзе чыга. Алтынчәчнең героик омтылышы “Алпамыш” дигән риваятьтәге Сандугач образы кылган гамәлләргә аваздаш. “Җик Мәргән” риваятендәге Җик Мәргән шулай ук үз кавеменең-ыруының яклаучысы, Туган җиренең иминлеге өчен көрәшче батыр булып гәүдәләнә.

Үз язмышын ил язмышы, туган туфрак дымы, халык язмышы

белән бәйләп карау, ил иминлеге өчен үзеңне корбан итәргә әзерлек, бергәләп, үзара нык берегеп, күмәк көч белән халкың мәнфәгатьләре өчен көрәшкә өндәү, шунда гына максатка ирешергә мөмкинлегенә инандырырга омтылу, киләчәк буыннарның да кешегә, халыкка, илгә карата шәфкатьле, игелекле булып үсүен кайгыртып, тормыш сабакларына йомгак-нәтиҗә ясап калдыру – халкыбызның чын мәгънәсендәге гыйбрәтле рухи хәзинәләре. Кешенең ни дәрәҗәдә шәфкатьле икәнлеге аның көндәлек тормышында, кылган эш-гамәлләрендә, итагатьле, игьтибарлы, ярдәмчел булуында чагыла. Бу яклап та халыкның тәгълим-тәрбия тәҗрибәсе тулы бер методик система тудырган.

Үзеңне эгоистик теләкләрдән тыярга өйрән:

*Тарга тар дөнья, киңгә киң дөнья.*
*Талымлы дуңгызны ашатуы кыен.*

Тормыш ыгы-зыгысында үз йөзеңне, кешелек горурлыгыңны югалтма:

*Илдә илле төрле кеше булыр.*
*Кеше авызына карама, кеше табагын ялама.*

Нәфесеңнең колы булудан саклан:

*Кеше кулындагыга ымсынган үз кулындагыны ычкындырган.*
*Нәфесеңә хуҗа бул.*
*Нәфесне ничек өйрәтсәң, шуны куар.*
*Нәфес ни теләми – холык җибәрми.*
*Этнең акылсызы коймакка нәфесен сузар.*
*Этнең янында сөяк ятмас.*
*Һәр кешенең үз нәфесенә көче җитсә, дәрәҗәдән коры калмас*

*андый кеше.*

Якыннарың, хезмәттәшләрең, илең, халкың алдында үзеңне бурычлы дип хис ит:

*Асыл кеше алтын дип үлмәс, халкым дип үләр.*
*Кеше кешегә бурычлы.*
*Яман өйгә сыймас, өйдән чыкса, илгә сыймас.*

Кеше хезмәтенә, бигрәк тә азык-телеккә карата сакчыл бул:

*Икмәк – ил тоткасы.*
*Ризык – тормыш тоткасы.*
*Күктә кояш, җирдә икмәк – мәңгелек.*
*Җирсез-йортсыз ил булмас, ашсыз-сусыз көн булмас.*

Кешеләрнең дусты бул:

*Яхшы холык дошманыңны дус итә.*
*Дусыннан аерылган җиде ел җылар.*
*Үзенә ихтыярсыз – дусына игътибарсыз.*
*Үз-үзеңә каты бул, дустыңа йомшак бул.*
*Дусның кадерен дус белер.*
*Көлмә дустыңнан, үтәр башыңнан.*

Игелекле бул:

*Сикергәнне аяма, егылганны ая.*
*Миһербанлык йөрәктән, миһербансызлык беләктән.*
*Чын яхшының ачуы булса да үпкәсе булмас.*
*Зәһәр кеше тиз картая.*

Кеше хәтерен сакла:

*Җылы сүз – җан азыгы, яман сүз – баш казыгы.*
*Авыздан чыккан салкын сүз йөрәккә үтеп, боз сала.*

Хайваннарга, кош-кортларга мәрхәмәтле бул:

*Хайваннарны җәберләгән рәхәт күрмәс.*
*Яралы кошка таш атмыйлар.*
*Рәхимсез атын кыйнар.*
*Мөгрәп килгән сыерның мөгезен сугып сындырма.*

Кешеләргә ачу саклама:

*Иске ачу истән чыккан.*
*Көчсезнең ачуы көчле.*
*Тешләмә, тешең бетәр.*
*Таракан дулап мич башын җимерә алмый.*

Халык педагогикасында балаларны тәрбиясез, начар кешеләр йогынтысыннан саклау мәсьәләләренә дә зур урын бирелә:

*Син бүрене аясаң, бүре сине талар.*
*Күп исле гөлләр арасында бер иссез гөл исле булган,*
*Күп иссез гөлләр арасында бер исле гөл иссез булган.*
*Битенә ыштыр каплаган ояла белмәс.*
*Вөҗдансыз кеше үзәксез агач кебек, үзлегеннәи аварга тора.*
*Гарьсез кеше чебен кебек: ишектән кусаң, тәрәзәдән керә.*
*Яхшы кеше белән юлдаш булсаң, җитәрсең син морадка.*
*Яман белән юлдаш булсаң, калырсың син оятка.*
*Төпсез көймәгә утырма, юньсез кешего иярмә.*
*Яман чир тиз йога, яман гадәт тиз йога, -*

ди халык яшьләрне кисәтеп. Әнә шундый начар кешеләрдән ерак йөрергә, аралашмаска өнди.

Безнең халыкның кешелеклелеген, миһербанлылыгын гәүдәләндерүче күркәм сыйфатларның берсе – кунакчыллык, һәм бу туган-тумачаларга, таныш-белешләргә карата гына түгел, һәр кешегә, һәр юлаучыга карата да күренә. К.Ф. Фукс кунакчыллыкны татарларның иң матур гадәте дип саный. Аларның гел ят кешеләргә дә сый-хөрмәт күрсәтергә омтылуын дәлилләп, үз башыннан үткәннәрне тасвирлап китә. Мәсәлән, галимнең бер сәяхәте вакытында арбаларының тәгәрмәче ватыла. Көч-хәл белән ерак түгел генә бер татар авылына барып җитәләр. Кучер тәгәрмәч төзәткән арада Карл Федорович кызы белән бер йорт янындагы агач күләгесенә барып басалар. “Йорт хуҗасы, безне күргәч үк, яныбызга килде, – дип яза Фукс. – Кем икәнлегебезне сораштырып та тормыйча, ул безне өенә чакырды, чәй белән сыйлады. Ә бит кызу июль көненең иң кыздырган вакыты – сәгать икеләр тирәсе иде”. (Фуке К. Ф. Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях. Казань, Тип. Казанского имп. ун-та, 1844, с. 36).

Чыннан да кунакчыл булу бездә үзенә бер бурыч, намус эше булып, ә кунак сөймәү начар гадәт булып саналган. Кунакчыллыкка карата да, кеше сөймәс булуга карата да, хуҗаның һәм кунакның үз-үзен тоту рәвешенә кагылышлы да күп төрле мәзәкләр, экиятләр, мәкаль һәм әйтемнәр аша өлкәннәр балаларына бу юнәлештә дә тәгьлим-тәрбиясен гамәлгә ашырып торган. Шундый күркәмлекне, кешеләр арасындагы үзара әйбәт мөгамәләне күреп үскән балалар бәлага тарганнарга һәрвакыт ярдәм кулы сузалар, кеше кайгысын, шатлыгын уртаклаша беләләр, туган ягы, иле тормышында бара торган вакыйгаларга актив мөнәсәбәттә торалар. “Телисеңме, теләмисеңме, син барыбер җәмгыятьтән тыш яши алмыйсың... Без барыбыз да, аякларыбыз, кулларыбыз, күзләребез кебек, бер-беребезгә ярдәм итү өчен яратылганнар", – дигән Маркс.

## 1.7. КЕШЕ ТАШТАН КАТЫ, ГӨЛДӘЙ НӘФИС

Элекке заманны никадәр генә хурласак та, халыкның матурлык сөюе, үзенең рухи байлыгына зур хәзинә дип каравы, аны кадерләп саклавы, үстерә һәр төрле формаларда буыннан буынга тапшыра баруы һәм гүзәллек традицияләре тудыруы һәркайсыбызда милли горурлык хисләре уята. Һәр табылган-ачылган әйбергә, күренешкә, җисеменә туры китереп, яңадан-яңа сүзләр тапкан безнең халык. Зирәк акыл, җорлык, һәрнәрсәнең төбенә төшенү бер үк сүзгә ялтырап-җемелдәп торган яңадан-яңа мәгънәләр салган, һәр сүзнең кадерен белеп, урынында һәм килешле кулланып, чыңлап-җырлап торган туган телен тудырган. Ничек җитте шулай сөйләшкәнне яратмаган, матур, төгәл сөйләм таләп иткән, сөйләм этикетына, ягъни үз милләтенең арасында дөрес сөйләү кагыйдәләренә нигез салган. Әдәпле сөйләү кагыйдәләре сабый вакыттан ук үзләштерелә киленгән:

*- Үзеңә яхшылык иткән кешегә чын күңелдән ягымлы итеп рәхмәт әйт.*

*- Зурлар сүзенә урынсыз кысылу әдәпсезлек.*

*- Киреле-морылы сөйләшмә, адәм рәтле телең юкмы әллә?!*

*- Бу сүз алай әйтелми, болай әйтелә.*

*- Федя түгел син, Фәрит. Үз исемеңне бозып әйтүгә юл кую үзеңне кимсетүгә юл кую бит ул.*

*- Алай кычкырып сөйләшмә, яныңда чукраклар юк бит.*

*- Кеше сөйләгәнне тыңлый бел! Үзеңне дә тыңлый торган булырлар.*

*- Күп сөйләшмә, кеше күңелен кайтарырсың. Беркемнең дә синең белән дус buласы килмәс, һ.б.*

Баштарак бу күрсәтмәләр сүз уңаенда гына бирелсә дә, тора-

бара бала колагына калыплашкан нормалар да ирештерелә:

*Күп бел, аз сөйлә.*
*Теле кычыткан сүз бозар, кулы кычыткан эш бозар.*
*Телеңә килгәнне сөйләмә, кирәкне сөйлә.*
*Сөйли белмәгән теленә батар.*
*Телең ни әйткәнне колагың ишетсен.*
*Сөйләсәң, урынлы сөйлә.*
*Һәр сүзнең җае бар.*
*Белдекле бер әйтер, бер әйтсә дә, бергәйле әйтер.*
*Кыскалыкта осталык.*

Өлкәннәрнең үз сөйләме, телгә саклыгы, сөйләү-сөйләшү рәвеше, балаларга сөйләгән әкиятләре, көйләгән җырлары, бәетләре, җырлары, мөнәҗәтләре, китап сүзләре, гаҗәеп шигъри мәкаль һәм әйтемнәре, табышмаклары, җаенә туры китереп кенә сөйләгән мәзәкләре – болар бар да яшьләр өчен туган телебездәге матурлык үрнәкләре.

Шуларга кешегә якынлыкны, кеше яратуны, нәниләрне назлауны, өлкәннәрне зурлауны белдерә торган эмоциональ-экспрессив сүзләрдән файдалану үзенчәлеген кушыйк: акыллым, чибәрем, гөлкәем, иркәм, канатым, сандугачым, җаным, үскәнем, дустым, туганкай, якташым, кордаш, туган, туган туташ, чибәр җиңги, ак бабай, ак түтәй...

Халыкның матурлык даирәсе күп планлы, киң мәйданлы. Буй-сын зифалыгы, гәүдәнең ничек тотылышы, йөреш-хәрәкәтләрдәге гармония аңа барыбер булмаган. Яшь киленнең көянтә-чиләк күтәреп кайтуларын күзәтүләр, аның эш-хәрәкәтләре матурлыгына бәя бирү, кияү балакайның өлкәннәр сүзенә килешле керешеп китүе, сабырлыгы, кулыннан төшкән хезмәт җимешенең файдасын гына түгел, төгәллегенә, матурлыгына игътибары яңа кардәш-ыруларның күз уңында тотылган.

Баланың әдәплелек кануннарын үзләштерүе, кешеләр арасында үзен инсафлы тотуы, гомумән, кешеләр арасында матур мөнәсәбәтләр урнаштыруга хәзерлеге халкыбыз эстетикасында зур урын алып торган. Кешеләр белән сөйләшкәндә ягымлы тавыш, нык ачуың килгәндә дә кешегә тавышыңны күтәрмәү, күрешкәндә килешле итеп баш ию, кул бирү, хәл-әхвәл сораша белү, урынлы-урынсыз акыл сату һәм кимчелекләрне күрсәтүдән сак булу, өлкәннәр, осталар эшенә игьтибарлы булып, зур кечелек тә күрсәтеп, мактый белү – хәзерге көндә активлаштырырга мохтаҗ, һәр җирдә һәркемне күркәм итеп күрсәтә торган гадәтләр алар. Аларга ия булган кеше үзенең яки дусларының шәхси мөнәсабәтләренә генә кагылган нәрсәләр турында сөйләшмәс, чит кешеләрнең сөйләшүенә колак салмас, кеше хатларын укымас, кеше әйберләрендә актарынмас, ябык ишек ярыклары аша тикшеренмәс, үзенә ошамаган кеше белән сөйләшергә туры килгәндә дә, аңа үзенең тискәре мөнәсәбәтен сиздермәс, тирә-юнендәге кешеләрнең кәефен җибәрмәскә тырышыр. Кыска гына итеп әйткәндә, “әдәп төбе – матур гадәт”, “җан азыгы – тәмле сүз, якты йөз”, “ипле, нәзакәтле кеше – матур кеше”, “күркәмлек – холыкта”, “чәчәкнең матурлыгы берни түгел, хуш исе булмаса”, “адәм бар – адәмнәрнең нәкышыдыр, адәм бар – хайваннар аннан яхшыдыр”, “килбәте нинди, күлмәге шундый”...

Күренеп тора, кешедәге тышкы матурлыкны, күзгә күренеп торган матур гадәтләрне халык эчке матурлык, аның әхлак сыйфатлары хезмәт сөюе белән тыгыз бәйләнештә, аларның үзара гармоник килешүендә карый. Баласын да буш ялтыравыклардан саклау чараларын күрә: “Һәр ялтыраган алтын түгел”, “Чибәрлеккә чибәр, күрсәң гайрәтең чигәр"...

“Кешенең һәрнәрсәсе матур булсын” дигән фикердә нык торып, безнең халык тышкы матурлыкны арткы планга куймый, һич та аны өстәмә сыйфат итеп кенә карамый. Озатуын акылына карап озатсалар да, бездә кешене каршы алу рәвеше аның киеменә карап

билгеләнә. Җырларда, әкият, дастаннарда, борынгы һәм хәзерге поэзия, проза һәм драма үрнәкләрендә геройларның йөз-сыннарын сокланып, шәрехләп тасвирлау фикерне куәтләп тора. Кызларның йөзен тулган ай, пешкән кура җиләге, гөлләр, якты кояш белән чагыштыра халык, егетләрнең коеп куйган кургашындай, коеп куйгандай нык, төз булуын ярата. Баласының “пәри алыштырган нәрсә”, “битенә катык сөртсәң, көчек яламаслык” булуын һич тә теләми. Энҗе төшләр, кыйгач кашлар, тез тиңентен чем-кара чәчләр, тал чыбыктай, ак каендай зифа буйлар мактала халык авыз иҗатында. Дөрес, тышкы матурлык эстетик идеал түгел анысы: “Матурлык морад түгел, ямьсезлек оят түгел”, “Матурлык туйда кирәк, акыл көн дә кирәк”, “Матурлыкны табакка салмыйлар”, “Матур матур түгел, яраткан матур”, “Матурлык дәрья кичтерми, акыл дәрья кичтерә”...

Гомер-гомергә бездә – “күркәм кием – тән зиннәте”. “Гомумән, татар мөселмәннар вә аларның хатыннары яраталар бигрәк ачыграк, матуррак булганны”, – дип яза Каюм Насыйри милли кием-салымнарыбызга_карата. Буыннан буынга камилләшә барган татар осталары чиккән калфаклар, кәләпүшләр, камчат бүрекләр, гаҗәеп нәфис эшләнгән чулпы-муенсалар, алка-йөзекләр, сәдәп-каптырмалар, савыт-саба дөнья базарларында күз явын алып торган, иң затлы товарлардан саналган. Иген иккән, мал асраган халкыбыз дөньяга “болгари” һәм “сафьян” дигән гаҗәеп матур һәм нәфис күн бүләк иткән. Күнне ефәк белән чигеп, күңелнең иң нечкә кылларын да тибрәндерердәй читек-кәвеш иҗат иткән. Әйе, иҗат иткән, “җитештергән”, “теккән" түгел, иҗат иткән. Кәҗә мамыгыннан йөзек аша үтәрлек шәл бәйләгән – үзе җыр, сангать. Өстәвенә җылы, йомшак, баш-муенга ипле ятып тора. Ә “Казан солгесе – сынлы сәнгатьтә үрнәк, җырда ләззәт, сәхнә сәнгатендә классика”. (Әхтәмова Ф. Камиллеккә омтылыш // Казан утлары. - 1992. - № 1. Б.124.). Мондый рухи хәзинәне булдыру өчен зур зәвык, төс-яктылыкларның үзара йогынты ясау үзенчәлекләрен дә тоярга,

белергә кирәк. Чөнки төсләр яктылык яки караңгылык тудырырга, а кешедә тынычлану яки ярсу халәтләре булдырырга, ләззәтләнү яки тискәре хисләр уятырга мөмкин. Аннары "җылы" (кызыл, кызгылт-сары), "салкын" (зәңгәр, зәңгәрсу), "авыр" (караңгы төсләр), "җиңел" (ачык) дип йөртелгән төсләр бар. Бер үк төс, башка төсләр янында булганда, төрле очракта төрлечә хисләр уянуга сәбәп була ала. Тегүче – чигүчеләребез чигешнең кайсы урыннарында җеп төсләрен ничек кулланырга икәнен зиһененнән бигрәк, җаны, йөрәге һәм, әлбәттә, матурлыкка сизгер күз нурлары белән тойган. Тәгълим-тәрбия отыры байый, нәфисләнә барып, атадан улга, абыйдан энегә, анадан кызга, ападан сеңелгә күчә торган.

Киләчәктә кияүгә чыгарга тиешле кыз балага бик иртә үз бирнәсен үзе хәзерләргә тиешлек анда яшьтән ук ихтыяр көчен генә түгел, аның нәфислек хисләрен дә үстергән, сабый вакытыннан алып буй үсеп җиткәнче (һәм аннан соң да) матурлык белән аралашып яшәргә уңай шартлар тудырган.

Кабер ташларындагы бизәкләр, агачтан ясалган бизәкләр (тәрәзә борыслары, өй-сарай түбәләре һәм кыеклары, ишек-капкалар, кәрнизләр, террасалар, мәчет-манаралар, сандык, өстәл-урындык, кош оялары һ.б.), таш корылмалар, балчыктан, бакыр, алтын-көмештән, якут ташлардан ясалган әйберләр халкыбызнын элек-электән камил эстетик зәвыклы һәм уңган икәнлегенә дәлил булып торалар. Кол Галинен "Кыйссаи Йосыф"ында Йосыф һәм Зөләйха салдырган сарайлар күренеше, аларның эче һәм тышындагы күп төрле бизәкләрнең сокланып һәм тәфсилләп тасвирлануы да сынлы, нәкыш һәм башка төр сәнгатьләрнең бездә борынгы заманнарда ук югары сыйфатлы булуы турында сөйли. Әйбернең матур, бизәкләрнең нәфис булуы өстенә оста-рәссамнәр практик физикадан да хәбәрдар булган дияргә нигез бар, чөнки аларга материалларның төзелешен, ныклыгын, тыгызлыгын, җылы һәм тавыш үткәрүчәнлеген, температура үзгәртү сыйфатын, су сеңдерү, төс һәм яктылык бирү үзенчәлекләрен дә бик яхшы исәпкә алырга

кирәк булган.

Безнең халыкта йөрү-хәрәкәтләрнең матурлыгын, зифа буйларны, җитез-җиңел атлауларны һәм килешле йөрүләрне ярату аның биюгә һәвәслегендә чагыла. Тәпи йөри башлау белән баланы “Әпипә“, “Бас әле, Өммегөлсем”, “Бие, бие, Хәйрулла” көйләренә биетә башлыйлар, тыпырдап торган нәни аякларны күкләргә чөеп мактыйлар. Аннары бала үзе дә, такмаклар әйтә-әйтә, бии башлый. Үсә төшкәч, җыр-такмаклар урамга чыга. Яратканнары – “Кәрия-Зәкәрия“, “Чума үрдәк, чума каз”, “Уфа-Чиләбе”. Буй җиткәч, чишмә буйларындагы, аланлыклардагы кичке уеннар биюне сәнгать дәрәҗәсенә диярлек күтәрә. Уен-көлке, җыр-бию белән шаулап-гөрләп торган аулак өйләр, каз өмәләре, Нәүрүз, Сабан туйлары, Җыен үзеңне башкалар алдында сынатмау, кешеләрдә кире хисләр тудырмау, матурлыкта, җитезлектә, дуслыкта сынатмау өчен көрәш мәйданына әверелә. “Сигезле”, “Дүртле”, “Өчле”, “Алтылы”, “Чүпләмле”, “Марш” – яшьләрнең яраткан биюләре. Җырлап биюләр дә шулар белән аралаша: “Алмагачлары”, “Көймә генә килә генә”, “Шәл бәйләдем” һ.б.

Шунда бию осталары аерылып чыга. Алар үзләренең җиңеллекләре, бию барышында ук төрле хәрәкәтләр уйлап чыгарулары, татар халык биюләрендәге фигураларны күп белүләре һәм аларны төгәл, җиңел, килешле башкарулары белән соклапдыралар.

Болар бит иҗади музыкаль сәләт, ритмик тоем һәм фикер үсешенә киң җирлек бирәләр һәм ирек, хезмәт сөючән, оптимист рухлы халыкта сәламәт музыкаль халәт, кәеф тудыралар.

Әлегрәк ислам дине, дин әһелләре музыкага каршы көрәш алып барган дип, ялган пропаганда алып барылды. Әйтерсең, безнең халык җырларын, туй йолаларын, шаулап-гөрләп торган кичке уеннарны, төгәл һәм гади борынгы йола көйләрен, уен-бию такмакларын, бездә киң таралган бәет-мөнәҗәтләрне башка милләт халыклары тудырган да, Октябрь революциясеннән соң безгә бүләк

итеп биргән. Солтан Габәши, Салих Сәйдәшев кебек композиторлар кайдан килде икән?!

*Солтан Габәши* (1891-1942), халкыбызның беренче профессиональ композиторы, – мулла баласы. Әтисе Хәсәнгата мулла матур тавышлы, музыкага һәвәс кеше була. Ул курайда, соңрак фортепианода оста уйнаган, бу шөгылен балаларына өйрәткән. Авырып киткәч, табиблар аңа, күңелен тынычландыру өчен, музыка тыңларга, музыка белән шөгыльләнергә киңәш итәләр. Мөфти Солтановның улы Арслангали Хәсангата муллага немец гармуны бүләк итә, һәм бүләк иясе аны бик тиз үзләштерә. (Гобайдуллин Х. “Кичке азан“ны кем язган?// Идел. – 1989. - № 5.- Б. 37-38.).

Солтан Габәши үзе дә революциягә кадәр ук профессиональ композитор дәрәҗәсендә югары музыкаль хәзерлекле була: Уфада күренекле музыкант Нина Соколовадан пианино дәресләре ала һәм концертларда татар-башкорт көйләрен пианинода башкара. 1908 нче елларда Уфада Исмәгыйль Терегулов җитәкчелегендәге кыллы оркестр концертларында катнаша. Казанга килгәч, әледән-әле “Шәрык” кичәләрендә чыгышлар ясый, Аитовлар мәктәбендә хор дәресләре алып бара. Иң мөһиме, әлбәттә, – көйләр, җырлар иҗат итә. “Вальс“, “Полька“, “Марш“ кебек көйләр иҗат итеп, әлегәчә чит һәм ят булып тоелган Европа музыкасындагы жанрларны, алымнарны милли күзлектән үткәреп, аларны мәдәниятебезнең бер өлешенә әверелдерергә зур өлеш карта. Аның Октябрь революциясенә кадәргә үсеш юлының югары ноктасы Гаяз Исхакыйның “Зөләйха” исемле драмасына махсус музыкасы. С. Габәшинең рухи кабилияте дә, белем мөмкинлекләре да композиторның татар һәм, гомумән, Ислам мәдәниятен яхшы белүе һәм яратуы, кадимнән килгән милли музыкаль традицияләребезне ихтирам итүе, үстерергә һәм дәвам итәргә омтылуы белен аңлатыла. Ул вакыттагы музыкаль атмосферага күз йому да дөреслеккә хилафлык китерү булыр иде. Нота язмалары белән яхшы таныш булган җырчылар, музыкантлар шактый күп була. Гата Исхакый,

Гыйлаҗ Сәйфуллин, Госман Садыйков, Мансур Солтанов кебек зыялыларның милли музыкаль басмалары дөнья күра. Әдәби-музыкаль кичәләр уздырыла .Театр коллективлары (“Сайяр”, “Нур” һ.б.) сәхнәдә музыкаль драма һәм комедияләр куялар. (Макаров Г. Солтан Габәши // Идел. - 1989. - № 5. -Б. 54-55.). Дин тыйган дисәк, мулла баласының мул җимешле музыкаль иҗат эшчәнлеген, революциягә кадәр ук талантлы сәнгать көчләренең булуын ничек аңлатыйк соң?!

Безда Ислам дине мәкамнәрс мең елга якын яшәвенә карамастан, халык моңнарында гарәп музыкасының да һәм, гомумән, гасырлар буена дәвам иткән һәм әдәбиятыбызга, фольклорыбызга шактый йогынты ясаган Шәрыкның да тәэсире сизелми. Уртаклык, нигездә, текстта, шигырь төзелешендә. Димәк, халык үзенең моңнарын, үзенә генә хас интонация-ритмнарын гасырлар буена саклаган, камилләштергән табигатенә чит-ят нәрсәләрне кабул итмәгән. Монда үзеннән-үзе күңелгә Тукай сүзләре килә: “Халык җырлары – безнең бабаларымыз тарафыннан калдырылган иң кадерле вә иң бәһале бер мирастыр... Мәгъмур Болгар шәһәрләре, Болгар авыллары, бер дә булмаган төсле, кырылдылар да беттеләр, эзләре дә калмады. Әмма менә бу кыйммәтле мирас дидкемсез халык шигырьләрен туплар да атмады, уклар да кадамады... Алар һаман да халык күңелендә... калдылар, алар сәламәт әле, алар яңгырый әле... Чын халык телен, чын халык рухын безгә тик халык җырларыннан гына табып була”.

Рәссамнардан да мисал булсын.

*Шакирҗан Таһири* (1858-1918) – татарлардан беренче рәсем мөгаллиме, туган авылы Ачасырда (Зеленодольски районы) башлангыч белем алганнан соң “Мәрҗани” мәдрәсәстндә укый, Татар укытучылар мәктәбен тәмамлый һәм укытучы булып эшли, дәреслекләр, “Рәсемле әлифба” төзи. Шул ук вакытта Казан реальное училище рәссаме Пашковскийдан дәресләр ала. 1883 нчс елда, татарлардан беренче буларак, Петербургтагы император художество

академиясенә имтиханнар тапшыра, дипломлы рәссам булуга ирешә. Талантын балалар өчен берсеннән-берсе камил рәсемле алифбалар төзүгә буйсындыра.

Татар халкы – гаять шигъри, музыкаль, рәссам, югары күңел хәрәкәтләрен тиз кабул итүчс, табигать матурлыкларына, кешеләрнең үзара, тормыш һәм табигать белән күркәм мөнәсәбәтләренә, чынбарлыктагы хәл-әхвәлләргә, моң-авазларга карата гаҗәеп сизгер халык. Бүгенгебездәге шау-шу, тимергә-тимер бәрелгән тавыш, төрле төстәге утларның бер сүнеп, бер кабынуы, оятсыз хәрәкәтләр исә яшьләребезгә, аларның психикасына яман тәэсир ясый, башларын аңгырайта. Гайре табигый халәт геннары инде онытылган борынгы кыргый кеше хәленә якынайта.

Без – үзенең мөстәкыйль дәүләте булган, бай тарихлы һәм мәдәниятле халык. Бабаларыбызның нинди уен коралларында уйнавы әнә борынгы легендаларда, риваять һәм дастаннарда чагыла. Болар: курай, гөслә, скрипка, кубыз, саз, төрле гармуннар һ.б. Яшьләребезгә аларны, гомумән, матурлык традицияләребезне кайтару, аларны заманча төс-аһәңнәргә баету – хәзерге көндә сәнгать бурычы гына түгел, социаль-педагогик проблема да ул. Чөнки телебезнең моңнардан аерыла баруы, күңелебезнең һәм күзебезнең матурлыкка сукырая баруы, гүзәллек традицияләребезнең югала язуы рухсызлыкка, дорфалыкка, миһербансызлыкка китерә.

# 2 БҮЛЕК
# АЙ БУЛМАСА, ЙОЛДЫЗ БАР
# (ТАБИГАТЬ ФӘННӘРЕН УКЫТУ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ)

## 2.1. ИДЕЛ СУЫ ИЛЛЕ БАТМАН
## (математика дәресләрендә халык авыз иҗаты әсәрләре)

Яшьләрдә үз халкының тарихына, рухи хәзинәләренә карата хөрмәт, алар белән горурлану хисләре тәрбияләү бурычларын уңышлы хәл итүдә мәктәптә математика өйрәнү дәресләрендә халык авыз иҗаты әсәрләреннән файдалану үз өлешен кертә ала.

Мәсәлән, 5 нче сыйныфта математика өйрәнү натураль саннар белән танышудан башлана, һәм аның берәмлекләр төркемен тикшергәндә берничә мәкаль һәм әйтемне мисал итеп китереп булыр иде.

— Бер елда ике яз булмый.

— Бер көн артка калсаң, биш канда да куып җитә алмассың.

— Тимерчедә пычак – унике кочак.

— Кырык ел яңгыр яуса да, мәрмәр ташка су үтмәс.

— Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз.

— Булган мең төрле эш башкарган, ялкау көнен бушка аткарган.

Табышмаклардан файдалану яңа фәнни төшенчәләр белән танышу кебек җитди дәресне бермә-бер җаңландырып җибәрер иде.

— Бер чынаяк эчендә ике төрле сөт. (*Йомырка*.)

— Бер анада биш бала. (*Кул һәм бармаклар*.)

— Бер төп борчак, унике кузак шулар эчендә өч йөз алтмыш биш борчак. (*Ел, айлар, тәүлекләр*.)

— Үзе бер, күзе мең. (*Уймак*.)

Арифметик табышмак балаларның гамәлләр башкаруын да таләп итәчәк:

– Кырда кырык багана,
Баганалар саен кырыгар бощра,
Бощра саен кырыгар ат,
Барысы ничә ат? (*Алтмыш дурт мең ат.*)

Билгеле булганча, халык авыз иҗатында санамышлар дигән бик кызыклы жанр бар. Балалар, алардан файдаланып, күңелле итеп качышлы уйныйлар. Түбәндәге сорау-табышмактан файдаланып, тәнәфестә мәктәп ишеге алдында «Качышлы», я булмаса, «Куып тотышлы» уен оештырырга була. Бу — дәреснең үзенә бертөрле дәвамы булачак. Уенны алып баручы:

— Берәү, икәү, өчәү, дүртәү, бишәү, алтау, җидәү, сигез, тугыз, ун, унбер! Шуларниләр — санап бир.

Укучылардан берсе:
– Беренчесе — борау,
Икенчесе — игәү,
Бишенчесе — өчаяк,
Дүртенчесе — дүречмак,
Бишенчссе — бишек,
Алтынчысы — ашык,
Җиденчесе — җидегән,
Сигезенчесе — сиртмә,
Тугызынчысы — тукмак,
Унынчысы — уймак,
Унберенчесе — йомак. Куып тот әле, мин бит йомгак. (Соңгы сүзне әйткәч, бала бер иптәшенә сугып ала һәм йөгереп китә. Иптәше аны куып тотарга тиеш.)

Әкиятләрдә кулланыла торган саннар — шулай ук отышлы мисал: өч ул, өч кыз, өч сорау, җиде егет, җиде төн уртасы, өч юл чаты һ .б. «Ак бүре» әкиятендә тылсымчы җитмеш төрле һөнәр белә, җитмеш төрле рәвешкә керә ала. Бусы инде тема буенча мисал гына

түгел, үзтәрбия өчен үрнәк тә.

Халык мәзәкләре узләренең тапкыр мәгънәле, җор телле, гыйбрәтле, шул ук вакытта күңелле эчтәлеге белән аерылып тора. Шуңа күрә да алар уку, сөйләү, теманы ныгытуы белән генә чикләнеп калмый, укучылар сөйләмен тапкыр үрнәкләр белән да баета. Менә «Тугыз агай» мәзәге.

Тугыз агай, туган авылларын ташлап, ерак җирләргә эш эзләргә чыгып китәләр. Агыйдел аша чыккач, бер-берсен барламакчы булып (барысы да исән-саумы, янәсе), санарга керешәләр. Берсе саный — сигез чыга, икенчесе саный — тагын сигез. Аптырашкач, аякларыннан чабаталарын салалар да тезеп куялар һәм аларны саныйлар. «Барыбыз да исән-сау икән!» – дип сөенешәләр һәм юлларын дәвам итәләр.

«Хуҗа Насретдин кыскычны йөз сумга сатмакчы булган» мәзәгендә берәмлекләргә да, дистәләргә дә, йөзләргә да мисаллар бар: йөз сум, бер кеше, биш аршин, ун аршин.

Моннан соң килә торган үлчәм берәмлекләрен өйрәнү дәресләрендә (мм, см, м, км; г, кг, т) хәзерге озынлык, мәйдан, күләм, авырлык үлчәү берәмлекләре белән беррәттән укучыларга татар халкының борынгыдан ук кулланып килгән үлчәү берәмлекләре турында да мәгълүматлар бирелә: колач, сажин, аршин, карыш, бер кул буе (кул озынлыгында), терсәк буе (бармак очларыннан алып терсәккә кадәр булган озынлык), кул яссуы (кул йөзе киңлеге), бармак иллесе (бармак киңлеге). Ерак аралар озынлыгын билгеләү өчен да халыкның үз төшенчәләре бар: чакрым, чумкас. фарсах (5 чакрым). Борынгы болгар бабаларыбыздан безгә көннәр, айлар белән исәпләнә торган юл озынлыклары калган: көнлек юл (бер көне якынча 35 км га тигез), айлык юл. Атньң бер көнлек юлы – 40–50 км.

Мондый үлчәү берәмлекләренә халык авыз иҗаты әсәрләрендә мисаллар җитәрлек. «Иңе ничә аршин булсын?» мәзәгендә бер ата улын базарга 10 аршин озынлыктагы дилбегә сатып алырга җибәрә. Егет, 10–15 чакрым юл уткәч, кире әйләнеп кайта.

– Дилбегәнең озынлыгы 10 аршин диден диюең, иңе күпме булсын соң? – дип сорый ул әтисеннән.

Ата улының акылсызлыгына хәйран калган һәм әйткән:

– Иңе синең акылың кадәр булсын инде, – дигән.

«Ак бүре» әкиятендә тылсымчы әнисен эзләп йөргән егет юлны бик кызыклы итеп өйрәтә: «Минем урманымнан өч көн, өч төн киткәннән соң, дию патшасының җиренә барып чыгарсыз. Ул дию җиреннән өч көн, өч төн барганнан соң бер алтмыш колач юанлыгы алтын тирәккә очрарсыз...». «Турай-батыр» әкиятендә батыр һәм аның юлдашлары каршына бер кәрлә килеп чыга: «Үзе бер карыш, сакалы – биш карыш» икән. «Таз – патша кияве» әкиятендәге юрга ат киңлеге ун сажин булган елганың аргы ягына бер сикерүдә чыга ала икән.

Мәсьәләне балаларга табышмак рәвешендәрәк итеп тәкъдим итсәң да була:

– Йөз аршинлык баганага таракан менә, көн буена утыз аршин өскә күтәрелә, әммә төн буена егерме аршин аска төшә. Бу таракан багананың башына ничә көндә менеп җитәр? (Сигез көндә: башта җиде көн һәм җиде төндә җитмеш аршин юл ута. Сигезенче көнне калган утыз аршинны күтәрелә да багана башына менеп җитә.)

Дәреслек мәсьәләләреннән балаларның кайчагында күңеле кайтып бетә. Менә укытучы аларга элекке санау-үлчәү берәмлекләрен бүгенге кулланышта булганнарына әйләндерергә киңәш итә. Шулай итеп, мәсьәләләр гади түгел, әкият мәсьәләләренә әйләнеп китә, һәм аларны балалар рәхәтләнеп чишәләр. Әлбәттә, табышмак та урынлы булачак: – Үзе бер карыш, койрыгы унбер карыш. (Инә белән җеп.)

Мәйдан үлчәү ысуллары өйрәнелгәндә балаларга тәкъдим итәргә халкыбыз тормышында киң кулланыш тапкан төшенчәләр байтак: җир буе (4800 кв. колач яки 2 дисәтинә, шул ук 80х60 сажин), ярты җир, чирек җир (җир буеның дүрттән бер өлеше), почык (җир буеның сигездән бер өлеше). Өлешләр булган үлчәмнәрдән

файдаланып, гади вакланмалар, аларны кушу, алу ысуллары белән танышу дәресләрендә балаларга әкиятләр укырга, үзләренә әкият мәсьәләләр иҗат итәргә кушарга мөмкин. Мәсәлән:

– Бер колач (сажин) 2,13 метрга тигез. 60 колачлы имән агачының аркылы озынлыгы күпме булыр?

– Җир буе 4800 кв. колач булса, җир буе ничә квадрат метрдан тора соң?

– Бер квадрат сажинда ничә квадрат метр бар?

– Без беләбез: 1 аршин 1/3 сажин дигән сүз. «Иңе ничә аршин булсын?» мәзәгендә ата улына ничә метр озынлыктагы дилбегә сатып алырга кушкан икән?

Күләм үлчәү берәмлекләрен өйрәнү дәресендә халкыбыз ничәмә-ничә еллар кулланган берәмлекләрне белү бер да артык булмас иде, ни дисәң да, алар – рухи мирасыбыз, халык тормышының бер сәхифәсе. «Бер чиләк сөт, су» дигәндә, анда 12 литр күләмендәге су, сөт барлыгын һәркем белгән, гәрчә 12 литр сүзе кулланылмаса да. Чиләк үзе вакланмаларда да кулланыла алган: бер чирек (1/4 чиләк = 3 л), бер әчмуха (1 /8 чиләк = 2/3 л).

Татарда «Идел суы илле батман» дигән мәкаль бар. Батман – авырлык үлчәү берәмлеге ул. 4 пудаука, ягъни 64 кг – батманнын авырлыгы. Ә бер потта – 16 кг. Татар тормышында, бигрәк тщ авыл җирендә борынгы заманнардан килгән авырлык үлчәү берәмлекләре әле бүген да кулланыла: кандар – 41 кг, почык – ике подаука, ягъни 32 кг; кадак – 410 г. Монда да коры саннарны фольклор үрнәкләре белән җаңландырып җибәрергә мөмкинлекләр киң:

– Үзендә батманы, кешедә почыгы.

– Батман алсаң, сайлап ал,
Эчен-тышын барлап ал.

Шуларга өстәп, укучыларга «Өч кадаклы мәче» мәзәген сөйләп җибәрәсең:

– Хуҗа, базардан өч кадак ит алып кайткан да, хатынына бәлеш пешерергә кушкан.

Бәлеш өлгергәч, хатыны ирен көтәсе урында, дус-ишләрен чакырып кунак иткән. Алар бәлешне, бер кисәген дә калдырмыйча, ашап бетергәннәр.

Кич белән, Хуҗа кайткач, хатыны аның алдына суда пешкән ярма шулпасы китереп куйган. Хуҗа, аптырап:

– Ә бәлеш кайда соң? – дип сораган. Хатыны:

– Әй, Хуҗа, бер бәхетсезлек булды бит әле. Чоланга мәче кергән дә итнен бер кисәген дә калдырмыйча ашап бетергән, – дигән.

Хуҗа өстәл артындагы үлчәүне тартып чыгарган да мәчене утырткан. Мәченең авырлыгы нәкъ өч кадак булган. Хуҗа аптыраган: «Әгәр дә бу өч кадак аның ашаган ите булса, аның үз авырлыгы кайда? Әгәр дә бу авырлык мәченең үз авырлыгы булса, ул вакыт мәче ашаган итнең авырлыгы кайда соң?» – дигән.

Күренгәнчә, халкыбыз таланты турында авыз иҗаты әсәрләре кайда да урынлы, гыйбрәтле. Аларның төгәл фәннәргә багышланган дәресләрдә кулланылуы бик отышлы. Әгәр әйтик, туган тел, әдәбият дәресләрендә алардагы эчке мәгънә, мәгънә күчеше, метафоралар, образлылык игътибар үзәгенә алынса, математика, физика һәм башка табигать фәннәрен үзләштерү барышында укучылар халык авыз иҗаты әсәрләренең рациональ ягын, аларда тормыш-көнкүреш тәҗрибәсе тупланганлыгын, аларның акыл эшчәнлеге, хезмәт, эзләнүләр нәтиҗәсе икәнлеген төшенәләр.

## 2.2. ҖЫРЛЫ-БИЮЛЕ ФИЗИКА

Халкыбызның рухи традицияләрен яңартуга, тәҗрибә күрсәткәнчә, башка уку предметлары белән беррәттән, халык авыз иҗатына бернинди да катнашы юк кебек тоелган физика курсы да өлеш кертә ала.

Әйтик, укучылар физикадан иң беренче дәрестә утыралар.

– Укытучы мавыктыргыч итеп “Серле ат турында әкият”не сөйли[2]: Бер заман патша янына өч акыл иясе килә. Шуларның берсе патшага сәгать саен, канатларын кага-кага, кычкырып җибәрә торган алтын тәвә кошын бүләк итә. Икенчесе бакыр торба алып килгән. Әгәр ул торбаны шәһәр капкасына элеп куйсаң, караклар кырынганда, гаҗәеп тавышлар чыгара икән. Өченче акыл иясе патшага кара агачтан һәм фил сөягеннән ясалган ат бүләк иткән. Ис китәрлек ат икән бу: әгәр аның уң яктагы җилкәсендә урнашкан шөрепне борып җибәрсәң, атка һава тула һәм очып китә икән. Сул ягындагы шөрепне борсаң инде, ат, һавадан бушанып, җиргә төшкән.

– Акыл ияләренең патшага барган бүләкләре кайсы яклары белән кызыклы? Сез аларның кайсына өстенлек бирер идегез, ягъни кайсы аларның патшага, аңа гына түгел халыкка, әйтик, үзебезгә кирәгрәк?.. Җәмгыять тарихында бүләкләрнең кайсы төрләре ни рәвешләрдә очрый? (Тәвә кошы – чаң кагу, сәгать, таймер; бакыр торба – боргы, кыңгырау, электр чыбыгы аша, сигнализация; оча торган ат – җәймә, дирижабль, самолет, космик корабль һ. б.)

– Күрәсез,– ди укытучы, – борынгы заманнардан ук халык табигать күренешләрен күзәтеп, стихияле рәвештә үз нәтиҗәсен ясаган һәм тормышын шуңа җайлап алып барган. Тормыш-көнкүрешне җитешле итеп алып бару өчен, табигать киңлекләрен техника белән бәйләп караган. Зирәк акыл, табигый сәләт аның

[2] Кара: Тысяча и одна ночь: Арабские сказки (Пересказ с арабского М. Салье). – М.: Детская литература. - 1981.- С. 159–163.

киләчәген чамалауга китергән. Болар да халык авыз иҗатында чагылган. Халык тәҗрибәсе, халык акылы билгеләгән күренешләр, хыяллар нигезендә, аерым талантлы шәхесләр ачышлары ярдәмендә, барысы бергә тупланып, фәннәр, шул исәптә физика фәне да – ягъни табигать турындагы фән дә барлыкка килгән. Күп кенә физик күренешләр исә машиналарга – техникага нигезләнә...

– Я, беренче бүлектә нинди физик күренешләр бар? (*Тавыш, канатлар хәрәкәте.*) Икенчесендә? (*Тавыш, авазлар. Техника – – җиз торба.*) Өченче бүлектә? (*Һавада йөзү белән идарә итү, һавада хәрәкәт.*)

Алга таба укытучы бу күренешләрнең билгеле закончалыклары барлыгы, болардан башка да гаять күп физик һәм техник күренешләр барлыгы, аларның 7 нче сыйныфтан алып, мәктәпне тәмамлаганчы өйрәнеләчәге, берничә ел эчендә күп кенә күренекле галимнәрнең ачышлары, аларның кызыклы да, гыйбрәтле дә тормыш юлы белән танышачагы турында сөйләп ала.

Шушы ук дәрестә «Күренмәс чикмән» әкиятеннән өзек тә китерү ярап куярга мөмкин.

– Бер егет сихерче картка аның атын карарга ялланган, имеш. Эше бик тә җайлы булып чыккан: төймәгә бер баса – печән малкайга үзе килә, икенче тапкыр баса – солы сибелә башлый. Тагын баса – су килә, башак әзерләнә... Әкият кенә диярсең! Анда авыл хуҗалыгын автоматлаштыру комплексы тулысы белән гәүдәләнә.

Кайсы гына халык әкиятләрендә очучы келәмнәр, җәймәләр, ашъяулыклар юк икән. Әлеге өй кирәк-яраклары, халык хыялында күз ачып йомганчы зур аралар үтә, сәгате-минуты белән кирәкле урынга китереп куя. «Башмак» әкиятенә кертелгән яшь егеткә кадерле мирас булып гаҗәеп башмаклар калган икән: үзләреннән-үзләре юлга чыгалар, җитмәсә, күңелле көй көйләп баралар. Ул башмакларны кигән кеше, көн-төн барса да, һич та армый икән. Егет алардан зур файда күрә: кайгыга баткан патшаның күңелен күтәрә, эчкерле рәхимсез вәзирне патшалыктан кудыра, патша кызына

өйләнә... Башмаклар хәзерге музыкалар яңгыратып юлдан җәһәт-җиңел элдергән автомобильдән бер да ким түгел.

Механик хәрәкәтләр, бер урыннан икенче урынга күчеш күренешләрен өйрәнгәндә, мәсәлән, укучыларга әдәбият дәресендә өйрәнгән «Таңбатыр» әкиятен искә төшерергә һәм, аңа нигезләнеп, мәсьәлә төзергә тәкъдим ителә. Җәяү кешенең уртача йөреш тизлеге сәгатенә 5 км, а җайдакныкы – 9 км дип, һәм бер тәүлектә 24 сәгать дип исәпләгәндә, Таңбатыр, алтын сарайга җиткәнче, ничә километр юл уза? Яки: Танбатырга җир астында ничә тәүлек булырга туры килә?

Ә инде «Потенциаль һәм кинетик энергия» темасын үткәндә «Патша кияве Таз» әкиятен искә төшерү урынлы булыр. Әкият эчтәлегеннән күренгәнчә, патша кызына өйләнергә теләге булганнар, үз атларына атланып, 10 метр биеклетәге тәрәзә янында утырып торган патша кызына кадәр сикерергә тиеш булганнар...

Мәсьәлә чишү өчен бик кулай мисал бу: атның авырлыгы 500 кг, а егет авырлыгы 70 кг дип исәпләгәндә, кыз янына җитәрлек итеп сикергән ат нинди хезмәт – эш башкара?

Архимед көче, җисемнәрнең йөзүе күренешләрен өйрәнү дәресен укытучы әкият сораулары белән башлап җибәрүне кирәк таба: бер карт улына бер үк төсле итеп юынылган ике бүрәнәне күрсәтеп, шуларның кайсы агачның төп киселгәнен белергә куша. Егет, белә алмыйча, аптырап тора («Зирәк карт»).

– Я, егеткә ярдәмгә килик... Ничек белә алсын икән?.. Әкиятне кемнең укыганы бар?.. Карт егеткә нинди киңәш бирә? Ә ни өчен суга ташларга куша? Нәтиҗә нинди? (Агачның башы ягыннан кисеп алынган бүрәнә су өстенә тулаем калкып чыга. Ә икенче бүрәнәнең очы гына суга бата). Ни өчен шулай килеп чыккан икән?..

Укытучы бу сорауларга дөрес җавапларны бүгенге дәрестә табачакларын әйтә һәм материалны үзләштерү башлана.

Укучыларның «Зирәк карт» әкиятен белүләре 8 нче сыйныфта «Яктылык күренешләре. Яктылыкның чагылуы. Чагылыш

законнары» темасын үткәндә дә ярап куя. Анда, билгеле булганча, бер патша елга төбендә затлы таш күргән кебек була. Әмма, елга төбенә әллә никадәр чумып карасалар да, затлы таш табылмый. Зирәк карт улына ташны шунда гына үсеп утырган агачтагы кош оясыннан эзләргә куша. Чыннан да, таш кош оясыннан табыла. Ни өчен соң аны патша елга төбендә күрә? Башкалар да, һич икеләнмичә, патша сүзенә ышаналар, гомерләрен куркыныч астына куеп, суга сикерәләр?!

Югарыда мисаллар дәресне әкият сораулары, әкият эчтәлегеннән чыгып куелган биремнәр белән башлауга китерелә. Әкиятләргә нигезләнеп, яңа материалны ныгыту өчен дә мөмкинлекләр киң. Менә «Җылылык тапшырылу» күренешен укучылар зиһенгә алдылар. Материал төплерәк узләштерелсен өчен, укытучы «Алтын каурый» әкиятен укырга (өйдә укылган булса, бигрәк яхшы), әкияттән җылылык тапшырылу күренешләрен билгеләргә, нәтиҗәнең сәбәбен аңлатырга куша. (Тимер, тугрылыклы таеның киңәшен тотып, каен агачы астыннан табылган үлән белән тәнен ышкый, һәм шуңа ул, пешмичә, кайнап торган сөттән исән-сау чыга: үлән белән ышкыгач, тән җылылык үткәрүче элпә белән каплана, әнә шул элпә пешүдән саклый).

«Парга әйләнү һәм конденсация» темасын үткәндә бирем түбәндәгечә тәкъдим ителә ала: «Шайтан һәм аның кызы турында әкият» тән парга әйләнү күренешенә нигезләнгән өзекне аерып алырга, исемләргә, әкиятнең тормышчан (чынлык) нигезен аңлатырга. (Егет белән кыз үзләре урынына, алдавыч итеп, ике көлтә калдыралар да качалар. Эзәрлекләүчеләр бу урынга килеп чыгалар да, егет белән кызның сөйләшкәнен ишетеп, менә тоттык, дип, туктап калалар. Сөйләшү тукталгач кына, үзләренең алданганнарын сизәләр: көлтәгә төкереп киткән егет белән кызның төкерекләре сөйләшкән икән. Төкерек кипкәч, сөйләшү тукталган).

Халык авыз иҗатыннан бию, җыр белән бәйле жанрлардан файдалану да дәресләрнең үзенчәлекле, кабатланмас һәм нәтиҗәле

булуына китерә. Әйтик, дәресләрнең берсендә «Механик хәрәкәт» (7 нче сыйныф) темасы аңлатылган. Дәрес тәмамлануга берничә минут калгач, укытучы мәшһүр физик Я. И. Френкельнең уенынчының бергә кушып әйткән түбәндәге сүзләрен укый: «Бию нәрсә ул? Бию – гәүдә хәрәкәтенең бер төре. Ә бит хәрәкәт – механик күренеш. Шуның өчен дә биюләр механика тарафыннан өйрәнелергә тиеш»[3].

– Укучылар,– ди укытучы, аптырагандай булып, – бию сәнгате белән физиклар шөгыльләнергә тиеш була бит. Сез моңа ничек карыйсыз?

Укучыларның төрлечә әйткән фикерләрен тыңлагач, укытучы иң оста биючегә конкурс игълан итә. Биюнең шарты – физик күрсәтмәләр нигезендә татар халык биюе башкарылырга тиеш. Күрсәтмәләрне укытучы әйтеп тора: әйләнә буйлап хәрәкәт, күчәр тирәсендә хәрәкәт, туры хәрәкәт, тигез хәрәкәт, тигезсез хәрәкәт, әкренәйтелгән хәрәкәт, инерция буенча хәрәкәт. Бию, димәк, инерция күренеше белән тәмамланырга тиеш. Конкурста катнашучылар такта янына чыга. Бию көе яңгырый. Алга таба укытучы хәрәкәт төрләрен әйтеп тора, биючеләр аларны, көйгә басып, башкаралар. Ялгышучылар читкәрәк чыга тора. Иң ахырга калган укучы – җиңүче. Бию өлешен звонок булугарак калдырып, конкурс өлешен тәнәфес вакытында дәвам итәргә була.

Укытучының йомгак сүзе биюнең бик катлаулы сәнгать төре булуы, аның физик төшенчәләр белән генә әйтеп биреп булмый торган гаҗәеп күп төрле нәфис элементлардан торуы һәм шуның белән кешедә зур ләззәтләнү тудыру, халыкның биюне яратуы, аны рәхәтләнеп каравы һәм талантлы итеп, җиңел һәм җилпенеп башкаруы турында. Укучыларга татар халык биюләре җыентыгы күрсәтелә Гай Таһиров, Татар биюләре. – Казан; Тат. кит. нәшр., 1960), игътибар белән һәм яратып милли киемнәр тасвирлана. Әңгәмәнең соңгы өлешен тәрбия сәгатендә, я булмаса түгәрәк утырышында дәвам итәргә мөмкин.

---

[3] Физики продолжают шутить: Сб. статей.– М.: Мир, 1968. – С.282..

Менә физика кабинетында грамъязмадан бишек җыры яңгырый. Дәрескә керергә әле звонок булып җитмәсә дә, укучылар, аптырашып, урыннарына утыралар. Дәрескә звонок.... Балалар, тып-тын калып, бишек җырын тыңлыйлар. Көй темам. Класска мөрәҗәгать:

– Нишләп бик тынып калдыгыз әле болай?! Нинди җыр бу?.. Гадәттә аны кем җырлый?.. Ни өчен җырлый? Ни сәбәптән бишек көе дулкынында бала изрәп йокыга китә?.. Моңлы булган өчен дисезме? Моңлы көйме соң бу? Моңлы-зарлы хис-кичерешләр сиземләнәме соң? Озын көй булганга дисезме? «Карурман» көе яңгырап торганда изрәпләр йоклап булырмы икән?!

Укытучы әнә шундый әңгәмәдән табигать (һәм кешелек) дөньясында тигез тибеп-агып торган авазлар барлыгы турында сөйләп китә, кош сайрауларына, агач-яфраклар шыбырдавына, җилләр, агым сулар китергән хәбәр-өннәргә игътибарлы булырга өнди, бишек җырларында, гадәттә әнә шул табигый-сихри авазларның, ананың йөрәк җылысы белән өретелеп, талгын тибрәлеп, сабыйга тынычлык индерүен аңлата, бүгенге дәрестән әнә шул серле күренешләрне, аваз дулкыннарын, аваз тибрәнешләрен, югарылык һәм түбәнлек сәбәпләрен өйрәнә башлауларын әйтеп куя.

Күп очракта әкият яки җырларны укучыларның өйдә укуы, а дәрестә – кыска гына итеп, мисал гына китерүе мөмкин. Әйтик, «Каты җисемнәрнең механик үзенчәлекләре» темасы үтелә, ди. Балалар җавабы мондый:

а) Камыр батыр, агач күсәкне кире кагып, тимер күсәк тотып юлга чыга. Чөнки тимер күсәк, агач күсәктән аермалы буларак, сынмый да, бөгелми дә;

б) Камыр батырны һәм аның дусларын хан ялчылары чуен мунчага ябып куялар да, коры утын ягып, аны кыздыра башлыйлар. Әмма батырлар исән-имин мунчадан чыгалар. Чөнки берсенең бүреге серле була: баш түбәсенә кисә, җил-давыл чыга, кашларына кадәр төшерсә, тирә-юнь бозга каплана икән. Ул бүреген кашларына

кадәр төшерә һәм үзен да, иптәшләрен да коткара. – Җылыту көчле булганда, металл кыза, түбән температура кызган металлны да суыта ала;

в) Таңбатыр үзенең ике туганы белән Дию урлап киткән патша кызларын эзләп китә. Юлда азыклары бетә. Шунда Таңбатыр, әнисе биргән энәне утта кыздырып, кармак ясый, балык тота. Ачлык булмый кала.– Кыздырган металл сыгылучан булып китә, энәдән кармак ясау мөмкинлеге туа.

г) Көндәлек тормышта кулланыла торган күп кенә материаллар халык җырларында чагылыш тапкан:

Каен каты, каен каты,
Каеннар аударалмыйм,
Кая барсам, кайгым бара,
Кайгымны калдыралмыйм.
Тимерле арба, төзек юл,
Барыр җирем ерак җир;
Михнәт чигеп маллар таба
Безнең кебек фәкыйрь ир.
Алтын алка авыр тарта,
Алты мыскалдан арта;
Кайда тусаң, кайда үссәң
Җаныңны шуңа тарта.

Дүртьюллыкларны физиканың башка темаларына да табып була. «Вакыт үлчәмнәре» темасына, мәсәлән:

Стенада сәгать суга
Унны да, тугызны да;
Пешкән алмага охшатам,
Дуслар, барыгызны да.

«Бөтендөнья тартуы» темасын үткәндә, гадәттә, Исаак Ньютонга агачтан алма өзелеп төшүе һәм моның галимгә Җирнең тарту көчен ачуга ярдәм итүе турындагы легенданы китерәләр. Ә бит

бу күренеш халык җырларында да уелып калган: *

Йөгереп кенә кердем, ай, бакчага,
Өзелеп тә төште бер алма;
Яшь йөрәккәйләрем ут тик яна,
Сабырлык та бирсен бер алла.

Авырлык көче йогынтысын җиңү өчен, хезмәт итәргә, әйтик, үргә менгәндә, көч куярга кирәклеген түбәндәге җыр теркәп куя:

Менәр идем, тау биек,
Төшәр идем, такырлык;
Яшь башыма хәсрәт авыр,
Ходай бирсен сабырлык.

Бу дүртьюллыкта ышкылу көчен и сап к а алу да бар, шуның өчен балалар алдына сорау куярга була: ни өчен тигез урдан төшүе, кытыршы ур белән чагыштырганда, читенрәк?

Хәзерге юл йөрү чаралары башка инде:

Автомобиль тауга менә,
Автомобиль көчле ул;
Бакчада бер чәчәгем бар,
Өзмим, синең төсле ул.

8 нче сыйныфта үтелә торган «Электр күренешләре» темасына җырларның саны иксез-чиксез:

Электр лампаларына
Сүнмәс утлар кабынган;
Исемнәрең йөрәгемдә
Ялкын булып кабынган.

Электрлар якты яна
Казан вокзалларында;

Бер җибәрми тотар идем
Сине күз алларымда.
Электр үтүге белән
Үтүклим керләремне;
Сине уйлап, ямансулап
Үткәрәм көннәремне.

Дәресләрдә, темасына җайлап, табышмаклар чишү, мәкаль һәм әйтемнәр табу, канатлы сүзләр китерү укучыларга физикадагы байтак тәгълимат халыкның үткен күзәтүе, зирәклеге, бай тормыш тәҗрибәсе аша тупланганлыгын ачып салыр иде. Ә бит бу жанрдагы фольклор әсәрләренең саны иксез-чиксез, һәм аларны күпләп китерергә була.

Мәсәлән, 8 нче сыйныфта «Җылылык күренешләре» темасына:
Бер өй эчендә
Нәкъ илле егет
Тигез үскәннәр,
Үлчәгән кебек.
Бүрекләр башка
Бик нык береккән.
Һәрбер егет салса бүреген,
Ашын, да пешә, җылына өең.
*(Шырпы кабындагы шырпылар.)*

Гармуннар кебек сырлы ул,
Мич шикелле җылы ул.
(*Җылыту батареясе.*)

«Электр» бүлегеннән «Электр тогы» темасына:
Абыйсы булмаса – апасы да юк,
Апасы булмаса – абыйсы да юк,
Икесе бергә – була яшен, ут. (*Электр токы.*)

Нечкә-нечкә баулардан
Бик күп атлар чабыша.
*(Электр чыбыклары буенча электр агымы.)*

«Атом төзелеше» темасына:
Күрер күзгә күренми,
Капшыйм дисәң, беленми;
Тузан хәтле үзе юк,
Гайрәтенең чиге юк,
Куәтенең тиңе юк.
*(Атом энергиясе.)*

«Электромагнит күренешләре» темасына:
Җаны юк, каны юк,
Үзе тимерне тарта. (*Магнит*.)

Үзе монда утыра,
Сүзен тегендә тутыра. (*Телефон*.)
Сөйләп бирә тел белән,
Сүзе китә юл белән,
Юлы агач башында. (*Телефон*.).

«Җисемнәрнең йөзүе», «Судноларның йөзүе» темасына:
Сукыр дөя суда йөзә. (*Көймә*.)
Энә бар, эзе юк. (*Көймә*.)

Үзен сорасаң, ил түгел,
Утырган җире җир түгел. (*Пароход*.)

Әнә бара арып, күкрәгенә җил кагып,
Тимер аның йөрәге, диңгез көрәге. (*Кораб*.)

Йорты агачтыр, аты тимердер,
Су өстендә хезмәте. (*Пароход*.)

Балык түгел – суда йөзә,
Туктаусыз төтен бөркә,
Эченә кереп утырсаң,
Су буйлап алып китә. (*Пароход*.)

9 нчы сыйныфта «Механик дулкыннар. Тавыш» бүлегенә:
Попугай түгел, Җаны юк,
Әйткән сүзне кабатлый. (*Магнитофон*.)

Кечкенә генә өй, эче тулы көй. (*Радиоалгыч*.)
Үзе көйли, үзе җырлый,
Ә үзенең теле юк. (*Радиоалгыч*.)

Телләре бар– сөйләми,
Көйләре бар – көйләмәсәләр, көйләми. (*Гармун*.)

Эче буп-буш, тавышы дөньяга сыймый. (*Барабан*.)
Аягын-башын кистем,
Корсагын тиштем,
Эченә өрдем,
Моңайганын ишеттем. (*Курай*.)

10 нчы сыйныфта «Төрле тирәлекләрдә электр тогы» бүлегеннән «Мөстәкыйль бушануның төрләре» темасына:
Ялт-йолт итә,
Җиде чакрым җир китә.
Җем-җем итәр, җемелдәп китәр.
Угын атар, үзе качар.
Ялт итәр дә, йолт итәр;

Тигән җирен ут итәр. (*Яшен*.)

10 нче сыйныфта «Оптика» бүлегеннән «Геометрик оптика» темасына:

Ак ашъяулык таптык,
Эченә бактык,
Бер сәгатьтә кышын да таптык,
Язын да таптык. (*Экран*.)

«Яктылык дулкыннары» темасына:

Өй түбәсендә – чаңгы юлы. (*Салават күпере*.)
Аллы-гөлле яулыгымны читән аша ыргыттым.
(*Салават күпере*.)
Сыр, сыр сыры бар, алты төрле нуры бар,
Җиде кат күккә юлы бар. (*Салават күпере*.)

«Электромагнитик дулкыннар» бүлегеннән «Радиоэлемтә» темасына:

Агач ди аты, тимер ди заты,
Эчендә бар ди хаты. (*Телеграмма*.)
Бер пыяла эчендә мең кеше. (*Телевизор*.)
Бер кцзгегщ дөнья сыйган. (*Телевизор*.)
һ. б.

Физика дәресләрендә мәкаль һәм әйтемнәрдән файдалану балалар алдында кешеләрнең элек-электән үзләрен әйләндереп алган материаль чынбарлыктагы әйбер, күренешләрне үзара бәйләнештә, үсештә һәм үзгәрештә каравын, үз тәҗрибәсен кыска, образлы итеп мәкаль һәм әйтемнәрдә белдереп, өстәвенә аңа зирәк һәм акыллы итеп подтекст (киңәш бирү, өйрәтү, кисәтү, яшәү кагыйдәләре чыгару һ. б.) салу талантын ачып бирер иде. Мәсәлән, 7 нче сыйныфта физикадан беренче дәресләрдә ук («Кереш» бүлегендә),

әйтик, «Исемсез, җисемсез нәрсә булмас», «Заман үтми, гомер үтә» кебегрәк мәкальләр китерү халыкның стихияле материализмына, физика һәм башка фәннәрне өйрәнмәгән очракта да табигатьтәге һәм җәмгыять тормышындагы) закончалыкларны үзенең тормыш тәҗрибәсе аша танып белү сәләте барлыгына дәлил булыр иде. 7 нче сыйныфта «Парга әйләнү һәм конденсация» темасын үткәндә, мәсәлән, «Кайда диңгез, шунда яңгыр», «Инерция» – «Таудан тәгәрәгән таш чокырда гына тукталыр», «Ышкылу көче»н өйрәнгәндә «Ышкымыйча асылташ та ялтырамый» мәкальләрен; 8 нче сыйныфта «Матдәләрнең агрегат халәте» темасын өйрәнгәндә «Ком су тотмый», «Комнан аркан ишмиләр», «Кырык ел яңгыр яуса да, мәрмәр ташка су үтмәс» кебек мәкаль һәм әйтемнәр да шул фикерне раслый.

Кайсы гына теманы алсаң да, материаллар җитәрлек.

9 нчы сыйныф. Тарту көче:

Айга сикермә, егылып төшәрсең.

Авыр таш, кузгалтсаң, җиңеләя.

Коега таш ташлау җиңел, алуы авыр.

10 нчы сыйныф. Металл:

Бер алтын гына картаймый. (Физик, химик үзенчәлек.)

11 нче сыйныф. Яктылык таралуы:

Йолдызны күз бик күрә дә, кул җитми һ. б., һ. б.

Физика дәресләрендә мәкаль һәм әйтемнәрдән файдалануда Мамадыш районы Урта Кирмән мәктәбе укытучысы Г. Шарипова тәҗрибәсе кызыклы. Менә 32 ел инде ул халык мәкаль һәм әйтемнәрен бөртекләп җыеп, программадагы темаларга җайлап туплаган да алардан дәрес материалларын ныгытканда да, контроль эшләрдә да, КВНда һәм кичәләр үткәргәндә да файдалана[4].

Мәсәлән,

[4] Шарипова Г. Физиканың да үз аршины (Дәреслорда мәкальлор hast әйтемнор) // Мәгариф.– 1992. –№ 4.- Б.34–35.

**Басым һәм басым keче:**

Чәнечкеле үләнгә кош кунмый.

Без капчыкта ятмый.

Коралы үтмәснең, эше бетмәс,

Тапканы тамагына җитмәс.

Тырышкан табар, ташка кадак кагар.

Күмәк көч булса, киез казык җиргә керер.

Черек тактага кадак тиз керә.

Егыласы җиремә ник салам җәймәдем икән?

Түбәң зур булса – кар күбрәк ятар.

Тыныч су ишкәк сындыра.

Иелгән агачны җил сындыра алмый.

Үткен дага тизрәк кыршыла.

Зур җилкәнне киерергә көчле җил кирәк.

Арыслан да чебеннән саклана.

Чүкечнең авыр икәнен бер сандал гына белә.

Энә кергән урынга аның күзе дә керә.

Чөйне чөй белән чыгаралар.

**Архимед законы:**

Чүпне суга атсаң да, өскә калкып чыгачак.

Үрдәк баласы су белән тумас борын таныш була.

Балыкны йөзәргә өйрәтмиләр.

Суга батырырбыз дип, чуртанны куркытканнар.

Суга батканда саламга ябышкан.

Суга чумган таш кебек...

Эре балык тирәндә йөзә.

Матрослары күп булганда, зур кораб суга баткан.

Алтынны су күтәрмәс.

**«Акүстика» бүлеге:**

Буш мичкә каты дөберди.

Тулы чәйнек тын тора, ярым тулысы шаулый
Чыңлатмыйча чәшке ватылмый.
Ялгыз карганың тавышы ишетелми.
Ярканатның көндез курмәвенә кояш гаепле түгел.
Җил исмәсә, камыш шауламый.
Күк кайда күкрәсә, яшен шунда суга.
Кыңгырауны куенда яшереп йөртеп булмый.
Казанга ничек кычкырсаң, ул шулай җавап бирер.

**Механик хәрәкәт**:

Җайдак алып киткәнне җәяүле кайтара алмас!
Су ташны да шомарта. Акмаган су үзән сала алмый.
Эз калдырмыйча юл йөреп булмый.
Юл ераклыгы тизлеккә бәйле.
Хәрәкәттә – бәрәкәт.
Олау аттан уза алмый.
Су тегермәнне да вата.
Йөргән таш шомарыр, яткан таш мүкләнер.
Күккә төкерсәң, битеңә төшәр.
Иске арыктан су тизрәк ага.
Эшле тимер тутыкмый.
Иркен кием тиз тузмый.

**Яктылык:**

Кеше кешегә иярә, кешегә күләгә иярә.
Агач хәтта үзен кисүчеләргә дә күләгә бирә.
Кояш барда йолдыз күренми.
Таң атса, чулпан калкыр.
Кәкренең шәүләсе да кәкре.
Озын тирәк күләгәсе тирәк төбенә төшми.
Итәк белән айны каплап булмый.
Кеше пыяла түгел – эчендәгесе күренми.

Яктылыкның кадере караңгыда беленә.
Ничек кенә карасаң да, күзгедә йөрәк күренми.
Яктылык күләгәсез булмый.

**Матдәнең агрегат хәле үзгәрү:**

Утлы эш утсыз эшләнми.
Дуслар ишәйсә – дошман калтырый.
Ялкын көчәйсә, корыч та эри.
Күп кыздырсаң, таш та ярыла.
Кипкән балчык ташка ябышмый.
Ничек кенә каралтсаң да, алтынга кара йокмас.
Юеш аяктан җирдә эз кала.
Тимерне кызуында сук!
Озак торган камыр да ката.
Кипкән җирдә орлык шытмый.
Чык кояш белән карата алмый.
Салкын кыш тун ярата.
Мичнең кадере кыш җиткәч.
Мич башында шалкан пешми.

**Энергия әверелеше:**

Кар яуганда салкын булмый, кар киткәндә суыта.
Кешене тун җылытмый, эш җылыта.
Су булмаган җирдә боз да юк.
Эшләгән тегермәннең суы туңмый.
Тупка карты тупның җавабы бар.
Как ре җәядән туры ук.

**Авырлык үзәге:**

һәр көпчәкнең үз күчәре була.
Биек кибән тиз ава.
Манараның нигезе – очыннан ныграк була.

Биек имәннең, тамыры тиран.

Беренче таш кыек ятса, стена авыш була.

Божраның очы булмый.

Нигезсез йорт тиз ишелә.

**Каты җисемнәр (Гук законы):**

Нык бәйләнгән себеркене сындыруы бик авыр.

Артык тартсаң, җәя дә сына.

Имән тактага зирек кадак какма.

Дуганы акрын бөгәләр.

Корыч сынар, бөгелмәс.

Чыбык тоткан җирдән сынмый.

Агач киссәң – озын кис: кисә-кисә кыскарыр.

Тимер киссәң – кыска кис: суга-суга озынаер.

**Диффузия:**

Кискән икмәк кире ябышмас.

Ит үзеннән үзе исләнә.

Озак торса, бал да әчи.

Кабыгын буяп куйсаң да, йомырка чери.

Балта белән су кисмиләр.

Кунакка барыр алдыннан суган ашап куймыйлар.

Алтын тутыкмый.

**Үлчәү берәмлекләре:**

Бизмән җансыз булса да, ышандыра.

Һәркемнең үз аршины була.

Кисәге булса, исәбе була.

Азның чиген белмәгән, күпнең чиген белмәс.

Сынык бөтен булмас.

Тавык белән ят, әтәч белән тор.

**Тоташкан савытлар:**

Су чокырда җыела.

Су суны таба, су чокырны таба.

**Инерция:**

Җиңел таш тизрәк тәгәри.

Йөгермәгән сөртенмәс. Һ. б.

Физика дәресләрен әнә шулай фольклор элементлары белән «бизәп» җибәрү укыту процессын укучыларга белем бирү ягыннан гына түгел, аларның рухи дөньяларын да баетуы белән максатка ярашлы итә.

Безгә калса, дәресләрдә «өй физикасы» бишминутлыклары күренә башлау да игътибарга лаеклы. Алар белемнәрне көндәлек тормыш шартларында чагылдыралар, абстракт кебек тоелган төшенчәләргә конкретлык кертәләр, шулай ук төрле дәрестә алган белемнәрне ничектер бер ноктага теркиләр. Әйтик, дәрес башланыр алдыннан укучыларга сабынга физик характеристика бирергә кушыла: формасыз (аморф) җисем, сабын күбеге әйбер өстендәге май һәм башка төр тапларны җебетә, тарката; сабынны яки сабын күбеген (суын) суга салгач, суның өслек тартылышы коэффициенты кими.

Яки менә укучыларга полиэтилен пакетка төрелгән ак күмәч күрсәтелә: күзәнәкле каты җисем; тыгыз һәм шул ук вакытта сыгылмалы була ала, андагы сыеклык парга әйләнгәч, искерә, күмәч искермәсен өчен, ул полиэтилен капчыкка төрелгән; капчыкта (пакетта) парта әйләнү һәм конденсация процесслары бара!

Яки төш порошогы һәм щетка: щетканың кыллары (йоны, ворсы) сыгылмалы, бөгелү деформациясенә бирелә; щетканың сабы – каты җисем; өслек тартылышы һәм җебү (юешләнү) нәтиҗәсендә порошок щеткага яхшы ябыша; тешләрне чистартканда ышкылу көче зур роль уйный.

Бишминутлыкларны сынамышларга да нигезләргә мөмкин. Мәсәлән, «Чык төшеп, күктә болыт күренмәсә, көн аяз булыр» сынамышы нәрсә белән үзен аклый? Яки «Салават күпере чыкса, көн аяза». Салават күпере чыгу белән һава торышы арасында нинди бәйләнеш бар? «Җәй кышка карап йөри, җәй килешен кыш сынар» – сынамышта халык эшчәнлегенең кайсы төре чагыла? (Игенчелек) һ. б. Сынамышлар да, күренгәнчә, физик күренешләр шул ук вакытта алар халыкның тормыш-көнкүреше, күзәтүчәнлеге һәм тиешле, зирәк нәтиҗәләр ясау осталыгы турында сөйли.

Халык авыз иҗатының яңадан-яңа якларын ачуда, рухи хәзинәләребезне укучылар күңеленә якын итеп кабул иттерүдә класстан тыш, Дәрестән тыш вакытның мөмкинлекләре киңрәк, әлбәттә. Мисал өчен мәктәптә да еш уздырыла торган сабан туен китерик. Аның программасына кергән уеннар укучыларга таныш булуын, бик тә теләп катнашуларын истә тотып, физика укытучысы аны белемнәрне ныгыту максатында уздырырга карар кыла. Укытучылар, ата-аналар белән да киңәшеп алгач, озакламый физикларның Сабан туе булачагы хәбәр ителә, коридорга (залга) зур итеп белдерү эленә. Белдерүгә шул хакта да язылган: Сабан туена махсус билеты, ягъни укучының физик икәнлегенә таныклыгы булган укучылар гына чакырылачак. Билет – таныклык булып, физика — өлкәсенә караган, аерым физик күренешләрне чагылдырган табышмак, мәкаль һәм әйтем, рәсем, ясалган предмет (модель), башваткыч, шарада, кроссворд санала ала. Бәйрәм көнне боларның һәммәсеннән файдаланыла: күргәзмә хәзерләнә, викторина сораулыгына кертелә, җиңүчеләргә бүләк итеп тапшырыла һ. б.

Физикларның Сабан туе программасы, әйтик, түбәндәгеләрдән тора.

«Чабышучы егетләр» ярышында берничә ир бала билгеле бер араны йөгереп үтәргә, әмма тиз чабу өстәвенә юлда очраган күренекле физикларның портретларын җыя барып, һәрберсенең

исемен дөрес итеп әйтергә, төп ачышын кыскача аңлатырга тиеш.

Мәсәлән:

Людвиг Больцман – Австрия физигы, молекуляр-кинетик теориягә нигез салучы.

Вильгельм Рентген – немец физигы, кыска дулкынлы элсктромагнитик нурланышны – рентген нурларын ача.

Игорь Васильевич Курчатов – рус физигы, илебездә атом-төш энергиясен булдыру эшләренә җитәкчелек итә һ. б.

Укучыларның хәзерлек дәрәҗәсенә карап, биремнәр катлаулырак та булырга мөмкин: яшәгән чорын, фәнни ачышының елын әйтергә һ. б.

Үз бурычын төгәл дә, дөрес тә, җитез дә башкарган укучы мәктәпнең иң җитез физигы дип игълан ителә.

«Бүрәнәдә капчыклар белән салышу» вакытында икс укучы бер-берсен егып төшерергә омтыла. Әмма бүрәнә өстендә калган «батыр» иптәшенең егылу сәбәбен дә, ягъни физиканың тотрыклы тотрыксыз тигезләнеш принцибын да аңлатырга тиеш. Шунсыз ул җиңүче булып исәпләнә алмый.

«Бау тартыш» уенында кайсы милләт халкы гына яратып катнашмый микән. «Физиклар» мондый сорауга җавап бирергә тиеш: физика законнары буенча (Ньютоннын өченче законы) бау ягыннан ике командага да тигез зурлыктагы көчләр тәэсир итә, ләкин алар туры сызык буенча капма-каршы яктагы көчләр белән тәэсир итәләр. Шулай да ни өчен соң бер команда бауны үзенә таба ныграк тартуга ирешә һәм җиңүче булып исәпләнә?

«Көрәш» белем сынашу рәвешендә бара. Ике укучы алга чыга да «көч сынаша» башлый: беренче укучы икенчесенә физикадан сорау бирә, а икенчесе 30 секунд эчендә җавап бирергә тиеш. аннары икенче укучы беренче укучыга сорау бирә, беренче укучы җавап бирә... Уенның шарты: җавап тапмаган укучының сорау бирергә хакы юк. Димәк, җиңүче булу өчен иң күп санда сорау һәм җавап булу таләп ителә.

Әнә шулай гадәттәге сабан туе бәйрәмнәренең күп кенә өлешләрен «физиклаштырырга» һәм күңелле генә мәктәп бәйрәме уздырырга, а инде фольклор материалларыннан файдаланып, дәресләрне һәм класстан тыш эшләрне, халыкча, зирәклектә, үткенлектә, җорлыкта ярыш рухы белән өретергә мөмкин.

Укытучы үзе өйрәнгән һәр чыганакны әнә шулай эшкәртеп, системага салып, үзенең иҗат лабораториясенә әверелдерә, сый фатлы һәм нәтиҗәле итеп укыту осталыгына ирешә.

## 2.3. ҺАВАЛАРДА ЙОЛДЫЗ
**(астрономия дәресләрендә халык авыз иҗаты материаллары)**

Астрономия фәне үзенең беренче яралгыларын ук халыкның, тормыш-көнкүреш ихтыяҗларыннан чыгып, күк йөзеннән, кояш, ай, йолдызларны өйрәнү, күзәтү нәтиҗәсендә туган тәҗрибәсеннән ала. Игенен иккән, малын асраган, кортчылык, белән шөгыльләнгән, җиләк-җимеш җыеп һәм үстереп көн иткән, үлән-чәчәкләрне дәва чарасына әверелдергән әби-бабаларыбызга кояшның кайчан һәм ничек чыгуы һәм батуы, айның калку һәм сүнүе, йолдызларның ничек җемелдәве, йолдыз-болытларның ни рәвешле алмашынып торуы кирәкле мәгълүматларны биреп торган. Аннары дөнья гизәргә сәүдә итәргә һәвас халкыбыз, йолдызларга карап, юлын салган, кирәкле кала, базарларга вакытында барып җитә алган.

Тупланган тәҗрибә, чын мәгънәсендәге аң-белем, сынамышлар, мәкаль һәм әйтемнәр, табышмаклар, әкият, легенда, риваятьләр, җырлар булып, халык күңелендә уела килгән. Астрономия дәресләрендә балаларны алар белән таныштыру – тормыш, заман таләбе: буыннан-буынга җыелып, сакланып, баеп һәм камилләшкәннән-камилләшә барып, күчеп килгән бу кадерле нигъмәтләрне яшьләргә тапшыру – фарыз. Буыннар чылбырының бу юнәлештә дә өзелмәве – фарыз.

Чыннан да, вакыты-вакыты белән күңелгә: «Халкыбыз алла күк җисемнәренә генә карап иҗат иткән инде?!» – дигән фикер килә. Ай-йолдыз да, җил-яңгырлар да аның рухына егәр, күңеленә моң, зиһененә иҗат кече, күзләренә үткенлек биргән шул. Шуңа күрә да мәктәптә өйрәнелә торган астрономия курсының һәр бүлегенә фольклор жанрларының теләсе кайсыннан үрнәкләр иксез-чиксез, һәм шуны беренче дәрестән башлап ел ахырына кадәр күзәтә барырга мөмкинлекләр гаять киң.

Конкрет мисалларга күчик.

«Астрономия предметы» дигән темага иң беренче кереш дәрестә мөгаллим укучыларга астрономиянең күк җисемнәренең хасиятен һәм хосусиятен өйрәнүче фән икәнлеген, бу фәннең чишмә башы халыкның тормыш-көнкүреш, иҗтимагый тормышка җайлашу һәм анда үз урынын анык билгеләү тәҗрибәсеннән, вакыт һәм пространствода ориентлашу ихтыяҗларыннан туган мәгълүматлар икәнлеген төшендерә.

– Безнең терки бабаларыбыз, – ди мөгаллим, – гомер-гомергә талантлы сәүдәгәр булган, илләр гизәргә, дөнья күрергә яраткан. «Йөргән таш шомара, яткан таш мүкләнә» кагыйдәсеннән чыгып, үзе өчен кирәкле ачышлар ясаган, компассыз-нисез да, карталарсыз да, ай-йолдызларга, кояш йөрешенә карап, чүлләр, далалар аша юлын салган. Күргән-белгән, тапкан-өйрәнгән, сизелгән һәм тоелганнардан нәтиҗәләр, матур яңгырашлы, тиран мәгънәле, үткен итеп әйтелгән мәкаль һәм әйтемнәр, эндәшүләр, табышмаклар, риваятьләр, мәзәкләр һ. б. булып формалашып, халык арасында таралганнар, буыннан-буынга тапшырылганнар...

Алга таба укучылар табышмаклар әйтешәләр:

– Табак тулы җиз төймә, кулым сузып алалмыйм (*Күк, йолдызлар.*)

– Вак кынадыр үзләре, ялтырыйдыр күзләре. (*Йолдызлар.*)

– Бер көтүче мең сарык көтә. (*Ай һәм йолдызлар.*)

– Төнлә баксам – күк тулган,
Иртән баксам – юк булган. (*Ай-йолдызлы күк йөзе*.)

Дәрестә мәкаль һәм әйтемнәр китерелә:
– Җыен йолдыз җыелса да, яктылыгы айдай юк.
– Ай белән кояш берәр генә була.
– Кояш бик зур да, аны капларга бик кечкенә болыт та җитә.
– Җидегән йолдызның койрыгы таңга сузылыр.

Ай-йолдызлар белән бәйле сынамышлар әйтелә һәм аларның халыкның күк җисемнәрен күзәтү, өйрәнү, тикшерү һәм кирәкле сөземтәсен чыгару нәтиҗәсе икәнлеге ассызыклап үтелә:
– Йолдыз атылса, җил булыр.
– Йолдыз тирәсендә кара алка булса, яңгыр булыр.
– Йолдызлар куе күренсә, аяз булыр.

Дәрес соңына таба укучылар кояш һәм ай-йолдызлар образ итеп алынган җырлар сайлыйлар, туплыйлар:

Һавада йолдыз ничәдер,
Ничә генә баксаң, күчәдер;
Ничә генә айлар, ничә еллар
Гомерләрем заигъ кичәдер.

Һаваларда йолдыз иләк-иләк,
Җидегән йолдыз бик сирәк;
Ачыла дөньяны көтәр өчен
Арысландай батыр ир кирәк.

Айлар калыкмас инде,
Йолдызлар батмас инде;
Үтте чәчкә вакытларым,

Әйләнеп кайтмас инде.

Ай белән кояш бер генә,
Йолдыз сиксән мең генә;
Кавышырбыз дип йөргән идек,
Кавышып булмый тиз генә.

Нәтиҗә: Яшәвенең күп өлешен борынгыдан ук табигать белән турыдан-туры бәйләнештә үткәргән татар халкы табигать матурлыгына, аның көчләренә, күренешләренә. хәрәкәтләренә, буяу-төсмерләренә карата сизгер булган, алар белән кызыксынган, тирәнтен аңлаган, аның күренеш-хәрәкәтләрен җырларына матурлык, сагыну, сагышлану, ярату, соклану образлары буларак кертеп, үзенең хис-кичерешләрен, теләк-омтылышларын, бәя-аңлатмаларын белдергән, үзенең табигать дөньясының аерылмас бер әгъзасы икәнлеген чагылдырган. җырның төзелешенә кара: беренче өлешендә аның табигать, аның ай-йолдызлары, шулар фонында – хис-кичерешләр. Чыны белән «табигать һәм кеше» – бергә гомергә.

Кереш буенча «Астрономик күзәтүләр һәм телескоп» дигән темага икенче дәрестә, билгеле булганча, укучылар астрономиянең фәнни тикшеренү методлары белән танышалар, телескопның төзелешен тикшерәләр. Гыйльми һәм гамәли астрономик күзәтүләрнең үзенчәлекләрен билгеләгәндә, укучыларга берничә фольклор үрнәкләре һәм, шулардан чыгып, нәтиҗәләр ясарга тәкъдим ителә:

Табышмаклар: Кич булганда күренер, таң булдымы – күмелер. (*Йолдыз.*) Бары төнлә генә нәрсәне күреп була? (*Йолдызны.*)

Мәкальләр һәм әйтемнәр: Ай яктыртканда йолдыз күренми. Кич караңгы булган саен йолдыз яктырак була. Йолдызны күз бик күрә  дә, кул җитми.

Кыска җырлар:

Ай булмагач, төн караңгы,
Бар яктылык айда икән;
Ай яктысында серләшкән
Минутлар кайда икән.

Иргә торып тышка чыксам,
Таралыша йолдызлар;
Таралышкан йолдызлар күк
Таралышырбыз дуслар.

Нәтиҗә: Халык авыз иҗаты әсәрләреннән дә күренгәнчә, төп күк җисемнәрен, андагы хәрәкәт, үзгәреш, үзенчәлекләрне болытсыз көннәрне, күбрәк төнлә, еш кына иртә таңда күзәтү һәм өйрәнү максатка ярашлы.

Эшендә бер төрле төзеклек һәм система булсын өчен, мөгаллим халык авыз иҗаты әсәрләре тупланган төрле җыентыклардан алдан ук программа темаларына туры китереп сайлап куя, аннары, укулар башлангач, Дәрестән-дәрескә аларны укучылар зиһененә һәм күңеленә ирештерү чараларын күрә .

Мәсәлән, «Астрономиянең гамәли нигезләре» бүлеген өйрәнү өчен программада 5 дәрес каралган. Аның аерым темаларына багышланган дәресләргә кирәкле фольклор үрнәкләрен түбәндәгечә итеп билгеләп куярга мөмкин булыр иде.

## 2.4. “АСТРОНОМИЯНЕҢ ГАМӘЛИ НИГЕЗЛӘРЕ” КУРСЫ ӨЧЕН ГАМӘЛИ ДӘРЕС ЭШКӘРТМӘЛӘРЕ

### 2.4.1. Беренче дәрес. Йолдызлыклар. Йолдыз картасы. Күк координатлары

1. Мөгаллим сөйләме һәм аңлатмалары. Йолдызларны төркемнәргә бүлгәләү халыкларга моннан меңнәрчә еллар элек үк хас булган. Җидегән йолдыз, Бизмән, Көянтә йолдызлар – татарларда бик борынгыдан билгеле йолдызлыклар. Шуның өчен да аларның халык авыз иҗатында чагылыш табуы – табигый хәл.

2. Җидегән йолдыз койрыгы
Борыла микән таңнарга;
Җырлый белеп җырламыймын,
Җырлыйм йөрәк янганга.

Җидегән йолдыз җиде әйләнә
Җиде төн уртасында;
Җидегән йолдыз нурлары бар
Ике бит уртасында.

3. Биш кыз бер көянтә күтәргән, –
Төн буе су ташый. (Көянтә йолдыз.)
Алты кыз һәр төн саен
Көянтәләп су китерә,
Унбер егет бергә җыелып,
Читтән күзләп, төн кичерә.
(Өлкән һәм Көянтә йолдызлар.)
Казыкка бәйләнгән ике атым дулый,
Дуласа да, бер тирәдән китә алмый.
(Тимерказык, Акбүзат, Күкбүзат йолдызлар.)

4. Акбүзат – йолдыз, Күкбүзат – йолдыз, Тимерказык – бер ялгыз.

5. Берсе ак, икенчесе күк ике атны тимер казыкка бәйләп куйганнар, имеш. Шул казык тирәсеннән китә алмыйча утлап йөргәндә аларны җиде карак (Җидегән йолдыз) урлап китәргә ниятләгән. Караклар Акбүзат һәм Күкбүзат артыннан әй чабалар, әй чабалар икән... Әле хәзер да куып җитә алганнары юк икән. Җирдә калган тимер казык күккә ашкан һәм йолдызларга әверелгән, һаман шул чабышны, тын да алмыйча, кымшанмыйча, күзәтә икән – ахыры ни белән бетәсен беләсе килә икән, имеш.

6. Мөгаллим сөйләме һәм аңлатмалары.

Тимерказык, ягъни Котып йолдызы хәрәкәт итми һәм һәрвакыт Төньяк Котып ягын күрсәтә. Шуңа күрә да ул бик борынгы заманнардан бирле юл-сәфәр йөрүчеләр өчен ышанычлы табигый ориентир булып хезмәт иткән һәм итә.

Акбүзат һәм Күкбүзат – Тимерказык (Казык) йолдызы тирәли әйләнүче йолдызлардан. Аларның исемнәре дә җисемнәренә туры килеп тора. Беренчесе шактый якты булып яна, а икенчесе, аның белән чагыштырганда, тонык булып күренә.

Айга карап адашсаң, атыңны Тимерказыкка тотып бәйлә.

Җидегән йолдыз җиде өйләнә, Тимерказык – урынында.

7. Мәзәк-мәсьәлә чишү.

Мәҗлестә имамнан берәү сорады:

– Хәзрәт, бу араларда Җидегән йолдыз, нигәдер, арткарак кала. Сәбәбе нәрсәдә икән?

Мөгаллим укучылардан сорый:

– Хәзрәт нәрсә дип җавап бирде икән?

Укучылар Җидегән йолдызның башка йолдызларга караганда галәм күчәренә якын торуы һәм шуңа күрә аның әйләнеше дә, башка йолдызлар белән чагыштырганда, әкренрәк булуы, күрер күзгә хәтта

сизелмәве турында сөйлиләр.

Ахырдан мөгаллим, көлеп, хәзрәт биргән җавапны да укып күрсәтә:

– Күп заманнардан бирле әйләнә торгач, арыгандыр, бәлки...

### 2.4.2. Икенче дәрес. Эклиптика. Кояш һәм Айның күктәге хәрәкәте

1. Проблемалы сорау: Бу әкият нигезенә нинди астрономик күренеш салынган?

Ай белән Кояш

Борын-борын заманда Кояш белән Ай Җир йөзен бер урында гына торып, бергә-бергә яктыртырга карар кылганнар. Барча кош-корт, җәнлекләр моңа риза булган. Ярканат кына каршы төшкән:

– Кояш белән Ай бер җирдә генә торсалар, – дигән ул, – җил бер генә яктан исәр, агачлар кәкре булып үсәрләр, игеннәр дә кояш төшкән җирдә генә өлгерер.

Бу фикергә барысы да кушылган. Ай белән Кояшка икесенә дә бер җирдә генә тормаска, әйләнеп йөрергә кушканнар.

Сорау: Ничек, нәрсә тирәсендә әйләнергә кушканнар сон? һәм бу боерык ничек гамәлгә ашкан дип фараз итик?

2. Ай һәм Кояшка халык элек-электән игътибар иткән, күзәткән, кызыксынган, үзенең авыз иҗатына иң сөекле образ итеп алган:

а) Кая барсаң да, бер Кояш.

Ай белән Кояш берәр генә була.

Ай яктысы ни хәтле генә якты булса да, кояшныкына җитми.

Кояш нурны йолдызлардан алмый.

б) Бер атасы, бер анасы, ничә йөз мең баласы. (Ай, Кояш һәм йолдызлар.) Апасы энәсенә кунакка бара, энәсе апасыннан кача. (Ай белән Кояш.) Ике аккош куыша, берсен берсе узыша, – җитә алмый. (Ай, Кояш.) Ул булса, көн була, ул булмаса, ни була? (Төн.)

в) Ай белән Кояш бер генә,
Йолдызын санамадым;
Зифа буена сокланып,
Акылын сынамадым.

Кызарып кына чыккан кояшка
Каршы гына барма, пешәрсең;
Җан сөйгән ярыңны ятлар алса,
Сикереп, янган утка төшәрсең.

г) Кеше тормышында зур роль уйнаганга, халык Кояш барлыгын хатта шаян сөйләмнәрендә – мәзәкләрендә да онытмый.

Кеше кояшы

Әүвәл заманда, имеш, бер малай ураза тоткан. Кояш баеганын түземсезлек белән көтә икән. Менә бервакыт, Кояш офыкка авышкач, өйгә йөгереп кергән да: – Әни, авызны ачыйк инде! – дигән.

– Кояш баемаган әле, улым.

– Нигә баемасын? Безнең Кояш алла кайчан урман артына төшеп китте инде. Баемаган Кояш безнеке түгел, башка кешеләрнеке ул, ашарга бир! – дигән.

Ай файдалыракмы, Кояшмы?

Хуҗа Насретдиннан:

– Синәеңчә, Кояш файдалыракмы, Аймы? – дип сораганнар.

Хуҗа:

– Ай,– дип җавап биргән.

– Ни өчен? – дип сорагач, Хуҗа:

– Чөнки Кояш болай да якты вакытта, көндез яктырта, ә Ай

төнлә, караңгы вакытта яктырта, – дип җавап биргән.

3. Ерактагы кояш җылы була, якын килсәң, пешерә. Үзара татулыклары чамалы булган туган-тумачаның бер-берсеннән еракрак яшәве хәерле. Шул чагында алар арасындагы мөнәсәбәтләр җылырак, якынрак була!.. Шул турыда бу кадәр ирония катыш әйтелә торган бу гыйбарә үзенең туры мәгънәсендә – табигать күзәтүе буларак та игътибарга лаеклы. Фәнни исәпләүләр күрсәткәнчә, безнең киңлекләрдә Җир 22 июнь көнне Кояштан җылылыкны һәм яктылыкны 22 декабрьдәгегә Караганда 600 мәртәбә күбрәк ала икән. Ә бит 22 июнь – ул җәйге кояш торгынлыгы көне, кояшның күк гөмбәзендә иң югарыга күтәрелә торган вакыты. Шулай булгач, чыннан да, «ерактагы кояш җылы, якты» дип әйтергә нигез бар.

Кояш аязып чыкса, шул көнне һәм аннан соңгы көнне аяз булыр.

Кояш баеганда томан я болыт булса, иртәгә аяз булыр. Баеткан урын ачык булмаса – яңгыр булуга.

Кояш бик еракта булып күренсә, салкын булыр.

### 2.4.3. Өченче дәрес. Ай хәрәкәте. Кояш һәм Ай тотылу

1. Ай тулса, йолдызлар сыегая.

Айның йөзе тулы булып күп тормас.

Ай бер тулышканнан сон кире кайтыр.

Ай кимендә артыр, тулысында кайтыр.

Ай, тулгач, кителе.

Яшь ай кимүдән курыкмас.

Яна ай, тотылса да, тоелмый калыр.

Ай якты да, җылытмый.

Бер күктә ике ай булмас.

Кояш югында ай да яктырта.

2. Төнлә калка, көндез ята.
Өй түбәсендә ярты ипи.
Лапас өстендә бөтен икмәк. Үзе урак, үзе тешсез.
Ярты телем ипи, бөтен дөньяга җиткән.
Барлык табышмакларның да җавабы – Ай.
3. Ай тулганда бөтен була,
Кимегәндә кителә;
Икебез ике илләрдә
Аерым гомер ителә.

Ай туганда якты була,
Тулы була батканда;
И, дускаем, бик сагынам
Кичке кояш батканда.

Ай түгәрәк, ай түгәрәк.
Ай түгәрәк шикелле.
Артларыннан карап калам –
Ак күбәләк шикелле.

4. Юкка исләре киткән.

Хуҗа Насретдин чит бер шәһәргә барган булган. Урамда кешеләрнең җыелып, яңа туган айга карап торуларын күргән. Хуҗа болар яныннан килеп:

– Безнең шәһәрдә арба көпчәге кадәр ай күрсәләр дә, бер дә исләре китми, а сезнең җеп кебек айны күреп тә исегез киткән, – дигән.

5. Мәзәктән дә күренгәнчә, кешеләр элек-электән үк күк җисемнәре, алардагы үзгәрешләр белән, яңа ай тулу, кояш һәм ай тотылу белән кызыксынганнар. Моннан үзләренә отыш та алганнар. Ай тууның үзенчәлегенә карап, киләчәк көннәргә, ай буена һава

хәлен дә билгели алганнар.

Яңа ай белән җил булса, бөтен ай буена җил булыр.

Яна айның очлары нәзек күренсә, салкын булыр.

Яңа айның югары башы җәелебрәк, түбән башы урак кебек бөгелебрәк торса, кыш көне айның унбишенә кадәр көннәр салкын булыр.

Җәй көне булса, унбишенә кадәр җил булыр.

Әгәр югары башы бөгелеп, түбән башы җәелеп торса, унбишенә чаклы салкын һәм җил булыр, унбишеннән соң юеш, былчырак булыр.

Әгәр яңа ай бик ачык ялтырап күренсә, салкын булыр.

Әгәр яңа ай кечкенә күренсә, ай буена ачык һава булыр.

Әгәр яңа ай саргылт булып, калын күренсә, бөтен ай юеш булыр.

Ай караңгы булып торса – һава юеш, җепшек булыр.

Әгәр ай ачык булып, ялтырап торса, коры булыр.

Ай тирәсендә кызыллык алка кебек булып, тиз бетеп китсә, аяз булыр.

Ай тулы вакытта саф һәм якты булып, ялтырап торса, һава яхшы булыр.

### 2.4.4. Дүртенче дәрес. Вакыт һәм календарь

1. Мөгаллим сөйләме һәм аңлатмалары.

а) Халык астрономиясендә бик та гади вакыт үлчәмнәрен очратырга мөмкин: Декабрьдә көн озынлыгы чыпчык борыны чаклы, январьда – карга адымы кадәр, февральдә ат башы зурлыгында. Январьның ундүртенә көн бер ипи пешерерлек вакытка озыная.

б) Идел Болгарында күп төрле календарьлар системасы кулланылган. Аларның барысы да хуҗалык итү шартларына, табигать дөньясына бәйле конкрет эчтәлекле һәм төзелешле булган.

Хайван календаре киң кулланылган. Анда көн һәм ай исемнәре бер-бер артлы, билгеле бер тәртип белән килгән, а еллар 12 еллык циклдан торган, аның эчендәге еллар хайван исемнәре белән билдерелгәннәр: тавык елы, үгез елы, һ. б.

в) IX–X гасырларда Идел Болгарына Ислам дине белән бергә Һижри календаре үтеп керә. Бу – Һиҗрәттән, ягъни Мөхәммәт пәйгамбәрнең Мәккәдән Мәдинәгә күчеп киткән көненнән башлап йөртелә торган ел исәбе.

г) Кыр эшләренең төгәл көннәрен һәм шартларын белү ихтыяҗы ел фасылларына бәйле календарь тууына китергән, һәм ай-кояш календаре туган. .

д) XVIII гасырда Петр I нең махсус указы белән яна календарь Россиягә кертелә, татарларда ул XIX гасырның икенче яртысында гына киң кулланыла башлый.

2. Хайван календаре кабул ителүгә кагылышлы риваять. «Ел башы» киләсе булгач, кайсы хайван аны иң алдан күрсә, ел башына шул хайван исемен бирмикче булганнар, имеш. Дөя үзенең муены озынлыкка ышанып, иң алдан күрә м, дип торганда, бер тычкан йөгереп килеп, аның өркәченең өстенә менгән дә Ел башын алдан күреп алган. Шуннан 12 еллык циклның, ягъни ел әйләнәсенең башы да тычканнан исәпләнә башланган, имеш. Башка елларга башка хайваннар төркеме бирелгән: Тычкан, Сыер, Барыс, Куян, Дау, Елан, Елкы, Куй, Мичен, Тавык, Эт, Дуңгыз.

Икенче бер риваять (Кашгаридан): Бер хан ауга һәм үз кешеләренә киекләрне бер дәрьяга таба куарга боера. Су аша иң алдан тычкан, аннары бер-бер артлы сыер, барыс, куян, крокодил, ат, сарык, маймыл, тавык, эт, дуңгыз кичеп чыгалар. 12 еллык календарьга кергән еллар шушы исемнәр белән аталып йөртел башлаган, ди.

3. Кыш бавыры бик озын.

Көз килеше җәеннән билгеле.

Кыш туңсаң, җәй җылынырсың.

Җәйгә чыккан җан үлмәс.

Бер елда ике яз булмый.

Җәйгә чыксаң, кышны уйла, кышка керсәң, җәйне уйла.

Апрель туса, яз була.

Апрель кергәч, эт биеклеге кар ява.

Сентябрьдә син да бер да, мин да бер, апрель аптырата.

Февральдә сыер мөгезен сындырырлык суыклар була.

Январьның көне кыска, февральнең ае кыска.

Айлар да тигез түгел: берсе озын, икенчесе кыска.

4. Ай яктысы якты була
Айның унбише җиткәч;
Сагынсаң да, күрешеп булмый,
Ерак илләргә киткәч.

Айның унбишләре җитсә,
Зөһрә йолдызы бул мае;
Гомергә бергә булсак та;
Күреп, күзләрем туймас.

**Искәрмә:** Татарларда «ай» сүзе ике мәгънәгә ия: Ай – күк җисеме, ай – ай исеме (апрель, май). Айның беренче унбиш көнен «яңа ай», икенче яртысын «иске ай» дип йөрткәннәр. Җырда ана шул кулланылыш үз чагылышын тапкан.

Апрель җитсә. яз җитәр,
Язлар җитсә, кар китәр;
Бу дөньялар үтәр-китәр,
Татулыкка ни җитәр.

Апрель җитсә, яз җитәр,
Яз үтәр да көз җитәр;
Ашау-эчү көн да була,
Татулыкка ни җитәр.

Айлар аяз булса иде,
Еллар имин булса иде;
Ел урынына ел туар –
Гомер озын булса иде.

Үтә еллар, үтә көннәр,
Үтә алтын минутлар;
Үткәч, кире кайтмый икән
Минут түгел секундлар.

5. Кара сыер килде, бөтен дөньяны җиңде; ак сыер килде, бөтенлесен дә күтәрде. (Көн һәм төн.) Ак сыер торып китте, кара сыер ятып калды. (Кыш һәм җәй.)

### 2.4.5. Бишенче дәрес. Үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау

Бишенче дәрестә бүлек буенча йомгаклау, белемнәрне ныгыту, системага салу эшләре алып барыла. Дәресне алдагы дәресләрдә китерелгән фольклор әсәрләреннән, тарихи фактлардан файдаланып, КВН яки башка төрле ярышлар формасында да үткәрергә мөмкин.

Бу кулланмада дәресләр өчен күп санлы фольклор әсәрләре тәкъдим ителү «Дәресләрдә гел халык авыз иҗаты әсәрләре генә кулланылырга тиеш икән» дигән фикер калдырмаска тиеш. Нәрсәдән ничек файдалану – укытучы эше. Монда үткәрергә теләгән фикер – астрономия укыту аша балалар күңелен халкыбыз тәҗрибәсенә, акылына, зирәклегенә якынайту. Шул күзлектән Караганда, дәрес чикләре фольклорны гына түгел, татар халкының тарихына, мәдәниятенә, гомумән, рухи хәзинәләренә кагылышлы материалларны да бик иркен сыйдыра ала. Мәсәлән, югарыда

дүртенче дәрес буларак «Вакыт һәм календарь» дәресенә Кояш һиҗрәсе буенча ай исемнәрен һәм аларда көннәр санын күрсәткән таблицадан файдалану максатка ярашлы.

| Тәртип саны | Зодиак йолдызлыгыз исеме | Гарәпчә йолдызлык исемнәренең татарча әйтөлеше | Зодиак йолдызлыгыз-ның татарча әйтелеше | Европа календаренә туры килү вакыты |
|---|---|---|---|---|
| I | Овен | Хәмал | Кузы | 20.03–19.04 |
| II | Телең | Сәвер | Үгез | 20.04–20.05 |
| III | Близнецы | Җәүзә | Игезәкләр | 21.05–20.06 |
| IV | Рак | Сәрәтән | Кысла | 21.06–22.07 |
| V | Лев | Әсәд | Арыслан | 23.07–22.08 |
| VI | Дева | Сөнбелә | Сөнбелә чәчле кыз | 23.08– 22.09 |
| VII | Весы | Мизан | Бизмән | 23.09-22.10 |
| VIII | Скорпион | Гакрәб | Чаян | 23.10–21.11 |
| IX | Стрелең | Кавәс | Укчы, җәя | 22.11–20.12 |
| X | Козерог | Җәди | Кәксә (Кәҗә) бәрәне, ылак | 21.12–19.01 |
| XI | Водолей | Делу | Сукояр, чиләк | 20.01– 17.02 |
| XII | Рыбы | Хут | Балыклар | 18.02–19.03 |

Мондый таблица буенча күзәтүләрдән соң инде байтак кына халык мәкале һәм әйтемнәренең, санамышларының «серен» ачу авыр булмаячак:

Кавәс тумый кыш булмый, Җәузә тумый җәй булмый.

Сәвердә сулар сәер була.

Сәвердәге явым – савып торган савым.

Сөнбелә туса, су суыныр.

Хут туды – ут туды.

Хут көне – ут көне. •

Хутта ут итә, Хәмәлдә әмәлеңне корыта.

Хәмәл туды – хәл булды.

Хәмәлдә хәл китә.

Төрки халыкларның, шул исәптә татарларның, болгарларның бөтен галәм турында күзаллауларын яктырткан хезмәтләр белән укучыларны таныштырып тору да мөһим чара. «Күк җисемнәренең хәрәкәте» темасын үткәндә, мәсәлән, укучыларны XIX йөздә Казан татарларында киң кулланылган «Мигъраҗнамә» исемле китап белән таныштыру («Күккә ашу турында китап») халкыбыз тормышының бер сәхифәсен ачу булыр иде: Күккә табыну. Галәм, күк җисемнәре хакында фәнни дөрес мәгълүматлар бирергә омтылучылар да аз булмаган: Мөхәммәтфатыйх Заһитов, Салихҗан Баруди һ. б. Болар да укучыларыбызга мәгълүм булсын иде.

Сүзлек өстендә эшләр дә дәресләрдә үз урынын алырга хаклы. Югыйсә күк җисемнәренең күбесен укучыларыбыз, дәреслеләрдә һәм башка чыганакларда бирелгәнчә, русча, аурупача терминнар белән атап йөртәләр.

Венера – Чулпан, Зөһра йолдыз;

Меркурий – Кече Чулпан;

Марс – Кызыл йолдыз;

Юпитер – Мөштәри;

Большая Медведица – Олы Җидегән;

Малая Медведица – Кече Җидегән;

Сириус – Ачык йолдыз;

Стожары – Өлкәр, Иләк йолдыз;

Млечный путь – Киек Каз юлы.

Сүзлек эшләрен җанландыруда, әлбәттә инде, фольклор әсәрләре ярдәмгә килә:

Чулпан Айдан яктырак.

Чулпан калыкты, Ай батты.

Ай янында Чулпан йолдыз чакырым ярым арасы.

Таң, так ата, Чулпан калка,

Чулпан таңны уята;

Егет, йөрмә син төн ката,

Төнлә мәхәббәт арта.

Ә Зөһра йолдыз турында нинди легендалар гына юк, күпме җырларда ул матурлык символы булып тирбәлә...

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: уку-укыту процессы астрономиядән да дәресләр белән генә чикләнми. Дәресләрнең дәвамы һәм еш кына башлангычы булган класстан тыш эшләр да бар. Аларда кирәкле материаллардан иңләбрәк та, кызыклырак та итеп файдаланырга була. Астрономиядән оештырылган класстан тыш эшләргә да бу турыдан-туры кагыла. Алар барышында да халык авыз иҗаты үрнәкләрен, халык уеннарын, тормыш- көнкүреш тәҗрибәсен чагылдырган этник факторлар кертеп җибәрү кичәләрнең, КВНнарның җанлылыгын бермә-бер арттырыр иде. Мәсәлән, элек-электән безнең яшьләр «Ал кирәк, гөл кирәк» уенында яратып катнашкан. Уйнаучылар, ике төркемгә бүленеп, бер-берсенә йөз белән басып, кара-каршы тезелешәләр һәм нык кына итеп кулга-кул тотынышалар (җитәкләшәләр). Төркемдәге һәркемгә чәчәк (я буяу төсе) исеме бирелә: сөмбел, төнбоек, нәркис, канәфер, күгәрчен күзе, лилия һ. б. Уенны төркемнәрнең берсе түбәндәге сүзләрне әйтеп башлый:

– Ал кирәк, гөл кирәк, безгә матур гөл кирәк.

Карты яктагы төркем до хор белән:

– Ал бирем, гөл бирәм, сезгә нинди гел кирәк?

– Безгә энҗе чәчәк кирәк!

Икенче төркемдәге «энҗе чәчәк» исеме бирелгән укучы карты яктагы төркемгә йөгерә һәм ул бер урында аларның кул чылбырын өзәргә тиеш була. Максатына ирешсә, кулын ычкындырган баланы үз төркеменә алып китә һәм уенны яңадан аның төркеме башлап| җибәрә. Ә инде өзә алмаса, үзе шул төркемдә кала һәм уенны ул калган төркем башлап җибәрә: «Ал кирәк, гел кирәк...». Нәкъ менә

шушы уен мотивларына яңачарак итеп «астрономия» уен оештырырга мөмкин. Бу юлы уенда катнашучыларга йолдыз исемнәре бирелә: Мөштәри, Кызыл йолдыз, Җидегән йолдыз, Чүмеч, Бизмән, Көянтә, Чулпан, Өлкәр, Акбүзат. Зөһрә. Киек каз юлы, Игезәкләр, Укчы, Сукояр һ. б. Уенның тәртибе югарыда аңлатылганча. Сүзләр генә башкача әйтелә:

– Ай кирәк, Кояш кирәк, тагы бер йолдыз кирәк!

– Ай бар, Кояш бар, соң нинди йолдыз кирәк?!

– Безгә Зөһрә йолдыз кирәк!

Яки:

– Безгә җитез Акбүзат кирәк!

Уенның исемен «Ай кирәк, Кояш кирәк!», я булмаса «Йолдыз кирәк» дип атарга мөмкин.

Бәйрәмнең бер өлешендә җырчылар ярышы күңелле генә узар иде. Укучылар ике төркемгә бүленеп басалар. Мөгаллим яки укучылардан бер алып баручы бер көй исемен әйтүгә, мәсәлән, «Сарман» диюгә, төркемнәр «Сарман» көенә текстына ай-кояш һәм йолдыз кергән халык җыры башкарырга тиеш була. «Рамай!» диюгә, җырның көе тагын алышына, әмма сүзләре да башка, яңа җыр булырга тиеш. Шулай биш-алты көйгә җырлангач («Минзәлә», «Авыл көе» һ. б.), нәтиҗә ясала: кайсы төркем күбрәк тиешле көйгә кирәкле сүзләр белән ялгышмыйча җырлар башкара алган. Ә җырларның саны иксез-чиксез:

Апрель җитсә, яз җитәр,
Язлар җитсә, кар бетәр;
Бу гомерләр утар-китәр,
Татулыкка ни җитәр.

Кызарып кояш чыкмыйча
Уйсу җирдә су кипми;
Көлемсерәп карауларың

Күз алларымнан китми.

Кызарып кояш чыкканда
Алсулана җир өсте;
Синең йөзең иртә таңда
Яктырткан кояш төсле.

Иртә торып тышка чыксам,
Таралыша йолдызлар;
Таралышкан йолдызлар күк
Таралышырбыз, дуслар.
һ. б.

Викторина сораулары арасында асылташлар сихәтенә кагылышлылыларын да кертү зыян итмәс иде:

– Кайсы зодиак тамгасына нинди асылташ туры килә? Сукоярга?

(Зәңгәрсу зәңгәр якут).

Укучыга? ( Зәңгәрле-яшелле фирәзә).

Игезәкләр өчен? (Берилл) һ. б.

Шунда ук укучыларның бу ташларның дәвалау үзенчәлеген да әйтеп баруы мөһим. Диңгез энҗесе, мәсәлән, бума зәхмәтеннән, акыл саташканнан, хатын-кыз авыруларыннан саклый. Кызыл һәм зәңгәр якут кан басымын төшерә, паралич, колак авыртуларыннан, акыл саташуыннан саклый. Шушы биремнәргә бәйләп, мөгаллим кайбер өстәмә мәгълүматлар хәбәр итеп ала. Безнең әби-бабаларыбыз асылташларга бизәнү әйберләре итеп кенә карамаган, ә бәлки аларның сихәтлек үзенчәлегенә да нык игътибар иткәннәр, кайсы асылташның нәрсәдән саклавын бик та яхшы белгәннәр. Болгар һәм татар хатын-кызлары диңгез энҗесе белән бастырып чигелгән ак калфак кигәннәр. Камзуллардагы гаять нечкә зәвык белән сайлап тезелгән ташлар, аларның тәэсирен белеп, ювелир

төгәллек белән урнаштырылганнар, һәм алардан организм ярдәм ала алган. Күренә ки, болар милли киемнәр, милли йола гына түгел, алар нигезендә тирән белем ята. Мондый мәгълүматларны С. Шарипованың «Идел» журналының 10 санында басылган «Асылташлар сихәте» дигән күләмле мәкаләсеннән күпләп табарга мөмкин..

Халкыбызның рухи хәзинәләре белән җаңландырылган дәресләр һәм класстан тыш эшләр укучыларда материалга карата кызыксыну уята, аның аңлы үзләштерелүен тәэмин итә, мәктәптә уку-укыту процессының халыкчан итеп оештырылуына китерә.

# ЙОМГАК

Халык педагогикасы – мәңгелек хәзинә. Анда халыкның күпгасырлык яшәеш тәҗрибәсе тупланган. Шуңа да төрле чорларда яшәүчеләр гомер итү, яшь буынны тәрбияләү мәсьәләсендә, беренче чиратта, нәкъ менә халык педагогикасында тупланган рухи мираска мөрәҗәгать иткәннәр. Әлеге бай тәҗрибә фәнни һәм әдәби китапларга үтеп кергән. Дөньякүләм барган глобальләшү шартларында рухи кыйммәтләрнең үзгәрүе күзәтелә. Бу исә гаиләдә бала тәрбияләү кебек гаять әһәмиятле мәсьәләгә дә тискәре йогынты ясый. Белгәнебезчә, гаилә ул өч буынның бергәләшеп яшәвен тәэмин иткән: әби-бабай, әти-әни һәм балалар. Бу бәйләнеш гаилә ныклыгын гына тәэмин итмичә, буыннарның үзара тыгыз бәйләнешенә һәм өлкәннәр тәҗрибәсен яшьрәк буынга тапшыруда да терәк-таяныч булган. Кызганыч ки, бүгенге көндә өч буынның бергә яшәү рәвеше сирәк очрый. Тынычрак, рәхәтрәк яшәү максатында, әби-бабай белән оныклар аерым яши, шул рәвешле өлкәннәрдә тупланган акыл, тәҗрибә яшьләргә килеп җитми. Нәтиҗәдә яшь буын бик кирәкле булган тәҗрибәне әби-бабайдан түгел, сирәгрәк китаплардан, күбрәк телевизор экраннарыннан, дус-иптәшләреннән ала. Ә ул, белгәнебезчә, төрле булып, еш кына ярамаган яисә кирәкмәгән үрнәкләрнең үтеп керүенә, таралуына да китерә. Шундый шартларда яшь буынны гаиләдә, балалар бакчасында, мәктәпләрдә тәрбияләүдә җитди кыенлыклар килеп чыга. Монда мөһим урынны ата-ананың әлеге мәсьәләне бөтен тирәнлегендә аңлавы, бәяләве алып тора. Шул очракта максатчан рәвештә төрле юнәлештә эш алып бару мөмкинлеге туа. Аның берсе – әби-бабай белән аралашу, бергә эш-гамәл кылу белән бәйле. Аерым яшәгән очракта да, алар белән еш очрашуга ирешү ата-ананың бурыч-вазифасы булып кала. Икенчесе – өйдә балалар белән халык педагогикасы үрнәкләренә даими мөрәҗәгать итү белән бәйле. Әлеге хезмәттә бу эшнең кирәклеге,

аның нигезләре, оештыру мөмкинлекләре һәм формалары күрсәтеп үтелде. Өченчесе – балалар бакчасындагы һәм мәктәптәге тәрбия процессында актив катнашу. Ата-ана тәрбияче һәм укытучының беренче ярдәмчесе булырга тиеш. Бергәләп башкарылган күмәк эш төрләре (бәйрәмнәр, кичәләр, уеннар һ.б.), беренче чиратта, бала өчен кирәк. Бала халык педагогикасы үрнәкләре белән танышып кына калмый, бәлки күмәк эшкә, уенга, бер-береңә ярдәмләшеп яшәргә өйрәнә. Шул рәвешле халык тәҗрибәсе әкренләп балага күчә, ул тормышка өйрәнә бара.

Әлеге хезмәт катлаулы тәрбия процессында сезгә ярдәмче булыр дигән теләктә калабыз.

## ФАЙДАЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ

**1 бүлек**

*Апушев П.* Син әле үс һәм укы күп, шунда аңларсың барын: Г. Тукайның шигырь педагогикасы // Мәгариф. – 1991.– № 4.

Балалар фольклоры һәм җырлы-сүзле йөз төрле уен. (Җыеп төзүче һәм аңлатма мәкаләләр бирүче Н. Исәнбәт. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1964.

*Баттал Ф.* Тормыш сабаклары // Мәгариф. – 1991. – № 10, 11, 12.

*Батчаева Х.* Акыл диңгездән тирән // Мәгариф. – 1991. - № 3.

*Батчаева Х.* Безнең халык шулай тәрбияли // Мәгариф. – 1990. – № 7.

*Баягоз Н.* Халык педагогикасында табигать // Мәгариф, 1991. - №4.

*Беркутов В.* Халык календарьләре тарихыннан // Совет мәктәбе. – 1967. – № 9.

*Беркутов В. М.* Бизмәннәрдә вакыт. – Казан: Татар. кит. нашр., 1992.

*Бурхинов Д. М., Данилов Д. А., Намсараев С. Д.* Народная педагогика и современная национальная школа. – Улан-Уде: Бэмы, 1993.

*Волков Г. Н.* Этнопедагогика. – Чебоксары, Чувашкнигоиздат, 1974.

*Волков Г. Н.* Педагогика жизни. Мир детства. Царство мудрости. – Чебоксары: Чувашкнигоиздат, 1989.

*Госманов М.* Тәрбия максаты – кешелеклелек // Мәгариф. – 1990. – №3.

*Давлетшин К. Д.* Волжская Булгария: духовная культура. Домонгольский период. X – нач. XIII вв. – Казань: Татар. кн. изд., 1990.

*Зәйнуллин Р.* Халык моңы картаймый // Идел. – 1989. – № 5.

*Зәкиев Ш.* Иман, кыйбла, тәрбияләү турында уйланулар //

Мәгариф. – 1990. – № 9,10.

*Измайлов А. Э.* Народная педагогика: Педагогические воззрения народов Средней Азии, Казахстана. – М.: Педагогика, 1991.

*Исәнбәт Н.* Ни өчен ни булган яки Утыз ялган: әкиятләр. – Казан: Таткнигоиздат, 1956.

*Исмәгыйлова С. Г., Исмәгыйлова Ф. М.* Тәрбия хәзинәләре. – Яр Чаллы, 1992.

*Исмәгыйлова Ф.* Үткән юлларда // Мәгариф. – 1991. – № 2.

*Исмәгыйлова Ф.* «Җырлы-биюле» физика // Мәгариф. – 1993. – № 9.

*Ключарев А.* Татар халык җырлары. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986.

*Мәхмутов Х. Ш.* Ел тәүлеге – 12 ай: Халык календаре битләреннән. – Казан: Татар. кит., нәшр., 1991.

*Нигматов З. Г.* Гуманизм: педагогика и школа.— Казань: Татар. кн. изд-во, 1988.

*Низамов Р.* Халык педагогикасы нинди ул? // Татарстан. – 1993. – № 9.

*Сункишева И.* Халык педагогикасының кайбер алымнарыннан файдалану // Мәгариф. – 1989. – № 1.

*Татар халкының* җырлы-биюле уеннары (Тезүче И. Надиров) – Казан: Татар. кит. нәшр., 1964.

*Татар халык җырлары* (Тезүче И. Надиров) – Казан: Татар. кит. нәшр., 1965.

*Татар халык иҗаты*. Кыска җырлар. (Тезүче, кереш мәкалә авторы һәм искәрмәләр әзерләүче И. Надиров). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1976.

*Татар халык иҗаты*. Табышмаклар. (Тезүче, кереш мәкалә авторы һәм искәрмәләр әзерләүче И. Надиров). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1977.

*Татар халык иҗаты*. Мәзәкләр. (Төзүче, кереш мәкалә язучы

һәм искәрмәләр хәзерләүче Х. Ш. Мәхмүтов). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1979.

*Татар халык иҗаты*. Мәкальләр һәм әйтемнәр. (Тезүче. кереш мәкалә язучы һәм искәрмәләр хәзерләүче И. Надиров).– Казан: Татар. кит. нәшр., 1987.

*Татар халык әкиятләре*. (Тезүче, мәкалә авторы һәм искәрмәләр әзерләүче Л. Җамәлетдинов) – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989.

*Ханбиков Я. И.* История педагогики татарского народа. – Казань: КГПИ. – 1975.

*Җәгъфәрова Р.* Шигърият чишмәләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1991.


***2 бүлек***

*Авзалов Р.* Төп физик хәрәкәтләр яки дөрес йөрүнең хикмәте // Мәгариф. – 1991. – № 12.

*Апушев П.* Син әле үс һәм укы күп, шунда аңларсың барын: Тукайның шигъри педагогикасы // Мәгариф. – 1991. – № 4.

*Балалар* фольклоры һәм җырлы-сүзле йөз төрле уен / Җыеп төзүче һәм аңлатма мәкаләләр бирүче Н. Исәнбәт. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984.

*Баттал Ф.* Тормыш сабаклары // Мәгариф. – 1991. – № 10, 11, 12.

*Батчаева Х.* Акыл диңгездән тирән // Мәгариф. – 1991. – № 3.

*Батчаева Х.* Безнең халык шулай тәрбияли // Мәгариф. – 1990. – №7.

*Баягоз Н.* Халык педагогикасында табигать // Мәгариф. – 1991. – № 4.

*Богусловская И.* Кешелеклелек – әхлак нигезе // Мәгариф. – 1991 – № 3.

*Бәширов З.* Шәһре Болгар мәчетләре // Мирас. – 1992. – № 1.

*Валидов Дж.* Очерк истории образованности и литературы

татар. – Казань: Издательство «Иман», 1998.

*Волков Г. Н.* Этнопедагогика. – Чебоксары: Чувкнигоиздат, 1974.

*Габделхәева Ф.* Дуслык белән көчле без // Мәгариф. – 1991. – № 3.

*Гобәйдуллин Х.* “Кичке азан”ны кем язган? // Идел. – 1989. – № 5.

*Госманов М.* Тәрбия максаты – кешелеклелек // Мәгариф. – 1990. – № 2.

*Гыйләҗев А.* Эзләремне эзләдем // Идел. – 1991. – № 10, 11.

*Гәрәева З.* Гүзәллеккә омтылыш // Мәгариф. – 1991. – № 5.

*Дәүли Н.* Хәерле көн, дуслар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1972.

*Зәйдуллин Р.* Халык моңы картаймый // Идел. – 1989. – № 5.

*Зәкиева Ш.* Иман, рухи кыйбла тәрбияләү турында уйланулар // Мәгариф. – 1990. – № 10.

*Ибраһимов Ф.* Татарлардан беренче рәсем мөгаллиме // Мәгариф. – 1991. – № 12.

*Известия о хазарах, буртасах, болгарах, мадьярах, славянах и руссах* Абу-Али Ахмеда бен Омар Ибн-Даста, неизвестного доселе арабского писателя начала X века, по рукописи Британского музея в первый раз издал, перевел и объяснил Д.А. Хвольсон, профессор С.-Петербургского университета: Напечатано по случаю пятидесятилетнего юбилея С.-Петербургского университета. – Санкт-Петербург: Типография Императорской Академии наук. 1869.

*Измайлов А. Э.* Народная педагогика: Педагогические воззрения народов Средней Азии и Казахстана. – М.: Педагогика, 1991.

*Илдарханов И.* Көрәш кагыйдәләреннән // Мәгариф. – 1990. – № 5.

*Исмагилова С. Г.* Школьные учебники – духовная ценность народа // Советская тюркология. – 1990. – № 3.

*Исмәгыйлова Ф.* Үткән юлларда // Мәгариф. – 1991. – № 12.

*Иҗбулатова М.* Гасырлар аша килгән мәгърифәт нуры // Совет мәктәбе. – 1985. – № 4.

*Карнеги Д.* Дуслаша белү һәм кешеләргә йогынты ясау серләре // Мәгариф. – 1991. – №№ 1, 2, 3, 4.

*Кәримуллин Ә.* Укый-яза белгәнбезме? // Социалистик Татарстан. – 1988. – 20 июль.

*Макаров Г.* Солтан Габәши // Идел. – 1989. – № 5.

*Максудова З.* Иж-Буби мәдрәсәсе // Идел.– 1991. – № 5.

*Мартынина Р.* Үз-үзеңне әдәпле тоту культурасы тәрбияләү // Совет мәктәбе. – 1984. – № 6.

*Мең дә бер мәзәк* / Җыючы һәм әдәби эшкәртүче Г. Бәширов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1963.

*Мостафин Р.* “Артта калган надан халык” һәм башка идеологик штамплар турында // Татарстан.– 1991. – № 7.

*Мәхмутов А.* Беренче Татар хатын-кызлар гимназиясе // Совет мәктәбе. – 1986. – № 10.

*Мәхмутов Х. Ш.* Ел тәүләге – 12 ай / Халык календаре битләреннән. Казан: Татар. кит. нәшр., 1991.

*Мәхмутов Х.* Халыкның үзеннән: Г. Ибраһимов иҗаты // Совет мәктәбе. – 1987. – № 3.

*Мәһдиев М.* Мәдәни мирасыбыздан бер кисәк // Мәгариф. – 1991. – № 4.

*Мөселман* халыкларында дини бәйрәмнәр // Мәгариф. – 1991. – № 2.

*Мөхәммәтҗанов Р.* Ел фасылларына бәйле йолалар һәм җырлар // Казан утлары. – 1992. – № 1.

*Насыйри К.* Сайланма әсәрләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1956.

*Нафигов Р.* И. Формирование и развитие передовой общественной мысли. – Казань: Татаркнигоиздат, 1964.

*Нигъмәтҗанов М.* Безнең моңнар // Совет мәктәбе. – 1982. – № 2.

*Поварисов С.* Шигъри телдәге күркәм гадәтләр // Мәгариф. –

1990. – № 7.

*Раимова С.И.* К вопросу о татарском детском музыкальном фольклоре // Вопросы истории, теории музыки и музыкального воспитания: сб. науч. тр. / Казан, гос. пед. ин-т. Казань, 1972.

*Ризаэддин бине Фәхреддин*. Ислам дине – нинди дин? // Мирас. – 1991. – № 1; 1992. – №№ 1, 2, 3, 4.

*Савельечева Л.* Хезмәт һәм әхлак // Мәгариф. – 1991. – № 10.

*Саттаров Г.* Татарларда хөрмәтләп-иркәләп, әйтү-эндәшү сүзләре // Совет мәктәбе. – 1984. – № 3.

*Сиражҗиева И.* Уйныйбыз да, җырлыйбыз да // Мәгариф. – 1992. – № 1.

*Сибгатуллина А.* Кандалый иҗатында хатын-кыз бәхете мәсьәләләре // Совет мәктәбе. – 1990. – № 7.

*Сироткин Л., Сироткина О*. Әтиләр авторитеты // Совет мәктәбе. – 1987. – № 3.

*Сункишева И.* Халык педагогикасының кайбер алымнарын файдалану // Мәгариф. – 1989. – № 1.

*Татар балалар* поэзиясе антологиясе / Төзүчеләр: Н. Исәнбәт, Г'. Рәхим һ.б.. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980.

*Татар халкының* җырлы-биюле уеннары / Төзүче И. Надиров. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1964.

*Тукай Г.* Ана мәктәпләре. Әсәрләр, биш томда, 4 т., 35-44 бб.

*Тукай Г.* Халык әдәбияты. Әсәрләр, биш томда, 4 т., 163-186 бб.

*Уразман Р.* Бәйрәмнәр нигә кирәк // Мәгариф. – 1991. – № 3.

*Уразман Р. Яз* бәйрәме – Сабантуй // Мәгариф. – 1991, № 1.

*Урманчеев Ф. И.* Дастаннарга лаек замана. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990.

*Ушинский, К. Д.* Избранные педагогические сочинения : в 2 т. Т. 1. Вопросы воспитания. – М. : Учпедгиз, 1953.

*Фукс К. Ф.* Казанские татары, в статистическом и этнографическом отношениях. – Казань: Тип. Казанского имп. ун-та, 1844.

*Фәррәхова Р.* Туган ил ул бер генә // Мәгариф. – 1991. – № 9.

*Фәхреддин Р.* "Җәвамигуль-кәлим" шәрхе / Ризаэддин бине Фәхреддин; Шуралар Җөмһүрияте Аурупа бүлеге һәм Сибирия мөселманнарының Диния нәзарәте. — Казан : Татар. кит. нәшр., 1989.

*Халим А.* Книга печали, или записки аборигена. – Вильнюс : Мокслас, 1991.

*Ханбиков Я., Попова Ә.* Гаилә тәрбиясенең кайбер проблемалары // Совет мәктәбе. – 1988. – № 11.

*Хаҗиева Л.* Уеннарның тәрбияви роле // Совет мәктәбе.– 1984. – № 4.

*Хәбибуллина 3.* Инсафлының теле саф // Мәгариф. – 1991.– № 3.

*Хәким С.* Поэмалар. – Казан: Татар. кит, нәшр. – 1977.

*Чекменева Т.* Казан укытучылар семинариясе // Совет мәктәбе. – 1984. – № 9.

*Шагаев Р.* Татар сөлгесе – күңел көзгесе // Мәгариф. – 1991.– № 8.

*Шагаев Р.* Икмәк турында әңгәмә // Совет мәктәбе. – 1988. – № 6.

*Ягъфәров Р.* Шигърият чишмәләре. – Казан: Татар, кит. нәшр., 1991.

*Әхияров К.* Бурычлылык хисе // Мәгариф. – 1991. – № 6.

*Әхмәдуллии Ш.* Тарих үзе шаһит // Татарстан. – 1991. – № 3.

*Әхмәтҗанов М.* Уен ул тәрбияче дә // Совет мәктәбе. – 1984. – № 1.

*Әхмәдиев Ш.* Олуг татар бәйрәме // Мәгариф. – 1991. – № 7.

*Әхмәтова Ф.* Камиллеккә омтылу // Казан утлары. – 1992. – № 1.

*Үтәбай-Кәрими Р.* Тарихыбыз һәм мәдәниятебездә // Мәгариф. – 1990.– № 10.

*Үтәбай-Кәрими Р.* Коръән турында. “Мәгариф”, 1991, № 2.

# ЭЧТӘЛЕК


Кереш. Милләт зыялылары тәрбияләү юлында 3

1 бүлек. Халык педагогикасы: әңгәмәләр

1.1. Буыннар, заманалар чылбыры өзелмәсә, киләчәккә өметләр бар 15

1.2. Алтыдагы – алтмышка 26

1.3. Көн – эшләргә, төн – йокларга! 40

1.4. Жирнең нуры – кояш, кеше нуры – гыйлем 46

1.5. Дуслык булмаган гаилә – тамырсыз агач 60

1.6. Кеше кешелекле булса гына кеше 70

1.7. Кеше таштан каты, гөлдәй нәфис 76

2 бүлек. Ай булмаса, йолдыз бар (табигать фәннәрен укыту мәсьәләләре)

2.1. Идел суы илле батман (математика дәресләрендә халык авыз иҗаты әсәрләре) 85

2.2. Җырлы-биюле физика 91

2.3. Һаваларда йолдыз (астрономия дәресләрендә халык авыз иҗаты материаллары) 111

2.4. “Астрономиянең гамәли нигезләре” курсы өчен дәрес эшкәртмәләре 116

2.4.1. Беренче дәрес. Йолдызлыклар. Йолдыз картасы координатлары 116

2.4.2. Икенче дәрес. Эклиптика. Кояш һәм Айның күктәге хәрәкәте 118

2.4.3. Өченче дәрес. Ай хәрәкәте. Кояш һәм Ай тотылу 120

2.4.4. Дүртенче дәрес. Вакыт һәм календарь 122

2.4.5. Бишенче дәрес. Үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау. 125

Йомгак 132

Файдаланылган әдәбият 134